Безнен МИРАС

06
июнь 2014

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Казан Сабан туе. 23 июнь, 2012 ел.
Р.Кадыйров фотосы

Сабан туе – халык туе,
Сабан туе – хезмәт туе!

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең мирас 12 +
06(29)
июнь 2014

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

24

ЭЧТӘЛЕК



14 САБАН ТУЕ БИЗӘКЛӘРЕ. *Мөхәммәт Мәһдиев*

80 МИНЗӘЛӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ. *Әхтәм Зарипов*

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

3 Безнең мирас — бары безнеке!

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

4 Миллият рухы бәйрәме. *Ленар Гобәйдуллин*
14 Сабан туе бизәкләре. *Мөхәммәт Мәһдиев*
22 Көрәшче Мәрҗани
23 «Сөлгеләр тотыла, һәр авыл...». *Мөдәррис Әгъләм*
24 Дөнья иңли Сабантуйлар. *Атлас Гафиятов*

ТАРИХИ МИРАС

26 Яңа төрек дәүләте уңчылары. *Йосыф Акчура*
30 Иске Рәҗәп авылы зиратының кабер ташлары. *Җамил Мөхәммәтшин*
35 «Нократка бардык без...». *Айдар Гайнетдинов*
37 Нократ бәете
41 Археографик көндәлек. *Миркасыйм Госманов*
44 Гамьле сәфәр хатирәсе. *Гомәр Даутов*

ҖИҢҮ — 70!

46 Бер рәсем тарихы. *Эльвира Ихсанова*
48 Җәләлетдин эти. *Мостай Кәрим*

ӘДӘБИ МИРАС

60 Кутадгу билик (Котайткыч белем). *Йосыф Баласагуни*
64 Йөрәк каны белән язылган. *Әнвәр Шәрипов*
69 Үткәннән хатлар
73 Тукай энциклопедиясе. *Гали Арсланов*
74 Киткән кебек тә түгел... *Сәмига Сәүбанова*
79 Шигырьләр. *Рәшит Әхмәтҗанов*

СӘНГАТИ МИРАС

80 Минзәләм мизгелләре. *Әхтәм Зарипов*
90 «Идел» бит ул... «Идел» бит ул!

Баш мөхәррир —
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Марат Закир
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миннәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус Заһидуллин
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор —
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Техник хезмәткәр —
Данил Салихов
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

98 **Әткәм-әнкәм, балам-онытым теле...** *Рөстәм Акъегет*
100 **Тел ил белән икән.** *Сибгат Хәким*
103 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК

106 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның июнь ае.** *Ленар Гобәйдуллин*
111 **«Шура» журналыннан — мәзәкләр.** *Рәйсә Шәрәфиева*

ШАЯН МИРАС

112 **«Тынгысыз каләм» битләреннән...**

ДИНИ МИРАС

118 **Ислам диненең бинасы.** *Ризаэддин бине Фәхреддин*

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы. Июнь**

Заказ №А-1562. **Тираж** — 1500 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 4.06.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.
Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда З.Бәширов, Л.Гобәйдуллин төшергән, «Татарстан яшьләре» газетасының һәм авторларның архивыннан алынган фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском языке)

Тышлыкның 1 нче битендә — «Лачын», 2002. Киндер, майлы буяу.
Б.Гыйльванов рәсеме

БЕЗНЕҢ МИРАС – БАРЫ БЕЗНЕКЕ!

Син галимме, әллә мөгалимме?!
Язучымы, әллә яучымы?
Эшчеме син, әллә көрәшчеме?
Бораулаучы, әллә аучымы?..

Итекчеме, әллә җитәкчеме?
Бер баймы син, әллә сукбаймы?..
Шәҗәрәңне, бәлки, белмисеңдер,
Беләсеңдер мәгәр Тукайны!

Зур шәһәрдә гомер итәсеңдер...
Авылдадыр, бәлки, яшәвең...
Кем булсаң да, кан кардәшем, диеп,
Туганым, дип сиңа дәшәмен!

Кан кардәшем минем, туганкаем!
Милләттәшем, газиз татарым!
Татар иле — синең Ватаның ул,
Татар иле — минем Ватаным!

Минеке дә, синеке дә... Димәк...
Ул — безнеке! Барыбызныкы!
Татар иле — безнең мирас бит ул!
Безнең мирас — бары безнеке!

2 июнь, 2014 ел



МИЛЛИЯТ РУХЫ БӘЙРӘМЕ

Ленар Гобәйдуллин

Татар халкының милли үзаңын, гореф-гадәтләрен, җыр-биюләрен, хуҗалык итү, көнкүреш-яшәү рәвешен төрле яктан чагылдырган милли бәйрәм бар. Ул – Сабан туе. Тормыш, яшәеш даими рәвештә үзгәрә барган саен, Сабан туе бәйрәмен уздыру традициясе дә заман белән бергә үзгәргән, шул ук вакытта аның төп сыйфатлары сакланып, буыннан-буынга тапшырылган. Шунысын да искәртергә кирәк: узган гасырның 20-30 елларына кадәр Сабан туе хәзерге кебек июнь башында түгел, ә кар эреп бетеп, җирләр кипкәч, чәчүгә чыгар алдыннан авыл халкы килешеп билгеләгән көнне уздырылган.

Ф.Әминов «Сабантуй». Киндер, майлы буяу

XX йөз башы татар вакытлы матбугатына язучы авторлар да, ел саен диярлек, Сабан туе уздырылган көннәрдә әлеге милли бәйрәм турында үзләренең мәкаләләрен, ә әдипләр исә хикәяләрен язган. Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган мәкаләләр циклында берничә момент аеруча күзгә ташлана. Аның беренчесе – Сабан туенда хатын-кызларның турыдан-туры катнашмавы. Мәкаләләрдән күренгәнчә, Сабан туе мәйданына егетләр бер урамнан, ә кызлар икенче урамнан барган. Кызларның үзләре генә, аерым

җирдә төрле уеннар уйнаулары, читтән ат чабышын тамаша кылулары турында языла. Бер авылда дәрәҗәле, бай гаиләдән булган кызларның, хатыннарның мәчет манарасына менеп, ат чабышын күзәтүләре аеруча кызыклы. Көрәш башлангач, гадәттә, хатын-кызлар кайтып киткән һәм кичке уенга әзерләнгән. Икенчесе — Сабан туенда дин әһелләре катнашу-катнашмау мәсьәләсе. Монысы исә, төрле төбәктә төрлечә булып, муллаларның дөньяга, гореф-гадәтләргә карашына һәм авылдагы авторитетына бәйле булган. Аларның кайберләре Сабан туен мәҗүсилек калдыгы, бозык эшләр, әдәпсезлекләргә сәбәпче бәйрәм, дип аны үткәрергә аяк терәп каршы булса, бу турыда газетага мәкаләләр язса, икенчеләре, киресенчә, әлеге милли бәйрәмне тәртипле, күркәм итеп уздыруны кайгыртып, хәтта оештыруны үзләре башлап йөргән. Өченчесе — Сабантуйларда хәмер эчү мәсьәләсе. Этнографлар татар авылларында исерткеч эчемлекләрдән әче бал, буза[1], кәрчемә[2] ясалуы, аларга колмак[3] салмаулары һәм җылы урынга куеп әчетүләре турында яза[4]. Сабан туендагы исереклеккә килгәндә, төрле чыганак төрлечә мәгълүмат бирә: кайберләрендә бөтенләй исерекләр булмаган, ә кайберләрендә берән-сәрән күренгәләгән. Ә кайбер мәкаләләргә ышансаң, аракы эчеп кенә сыйлашып ятканнар, диярсең. Сабан туенда мөселманнар арасында эчкечелекне күтәргән мәкаләләр аеруча 1914 елдагы вакытлы матбугат сәхифәләрендә күп очрый. Бу шул елда Россиядә барлык төр алкоголь продукцияне җитештерү һәм сатуны тыю турындагы «коры закон» чыгу белән бәйле. Безгә калса, авыл халкын Сабан туенда күпләп эчүе турындагы мәкаләләрне, милли бәйрәмне уздыруга әүвәлдән каршы булган дин әһелләре берникадәр күпертеп, эчкечелек таралуны сылтау итеп, әлеге бәйрәмне бетертү нияте белән язган булса кирәктер. Шунысы бәхәссез, татар халкы элек-электән Сабан туена исерек килгән кешегә адәм актыгы дип караган, аны уеннарга һәм хәтта кайбер җирләрдә Сабан туена да кертмәгәннәр. Дүртенчедән — Сабан туе ул татарның үзенә күрә бер кием модасын күрсәтү мәйданы да булган, аеруча яшьләр заманның иң соңгы модасында киенергә тырышкан. Бишенчедән — XX гасыр башында ук Сабан туе татар халкының башка милләт вәкилләре катнашында узган милли бәйрәме булган. Аеруча руслар бу бәйрәмгә колга башына эленгән кызыл сөлгене күреп яки махсус чакыртылып, кунак булып килгән, бәйрәм иткәннәр, уен тамашаларда катнашкан, хәтта татар егетләре белән бил дә алышкан.

Шунысы үзенчәлекле, татар вакытлы матбугатында Сабантуй турындагы язмалар, әлеге милли бәйрәм күренешләрен «эчтән» ача, ягъни мәкаләләр читтән күзәтүче тарафыннан түгел, ә шул вакыйгаларның эчендә кайнаучы кешеләр тарафыннан языла. Төп идея дә — «миллият рухы аңкып торучы», «милләтнең рухын күтәрәчәк җаны һаман бар икәнен белдерүче», туган-тумачаны, дус-ишне һәм, гомумән, татар халкын берләштергә торган әлеге милли бәйрәмне сакларга кирәклеге — җиңел аңлашыла.

[1] Буза — ясмыктан ясалган өй сырасы.
[2] Кәрчемә — озак тору аркасында бик нык әчегән катык.
[3] Колмак — тут агачлары семьялыгыннан үрмәле үсемлек, кайбер культуралы төрләре сыра ясау өчен файдаланыла.
[4] Татары / Отв.ред. Р.К.Уразманова, С.В.Чешко. — М., 2001. — С.386.

САБАН ТУЕН КАРШЫЛАУ

Авылларда Сабан туе зурлар өчен елына бер мәртәбә күңел ачу урыны булса, балалар өчен ул Сабантуйлары әллә нидән дә кадерле бәйрәмдер. Өй башыннан тамган беренче тамчы берлә авыл баласы Сабан туе тугрысында уйлый башлый. Авыл баласы Сабан туен әллә ничә атна элек каршылый. Менә карлар эреп, урамнарда җирләр ачылу берлә авыл балалары, яланаяк чабышып, ат-ат уйный башлыйлар һәм шул вакытта ук берсе — Гыймади агайның былтыр Сабан туенда узган, баш килгән аты, берсе Салих бабайның бу ел Сабан туена җибәрергә хәзерли торган кола аты булып узышалар. Кырлар ачылу берлә чирәм өсләрендә йөртергә чыгарылган, бу ел Сабан туена җибәреләчәк атларны карарга балалар бер дә кичекми җыелалар. Бу хәбәрне алар әллә кайдан ишетергә дә, җыелырга да, иптәшләре берлә сөйләшергә дә өлгерәләр. Алар, бер атна элек, тирә-як авыллардагы Сабан туе җәдвәлен [уздыру графигын] бик яхшы белеп хәбәр бирәләр: фәлән авылда дүшәмбе, аннан соң теге авылда чәршәмбе, күрше авылда пәнҗешәмбе, ә җомга көн үзләрендә Сабан туе булачакны беләләр. Алар һәркемнән элек, күрше авылга елга аркылы күпер булмаганлыктан, кайдан әйләнеп барырга мөмкин идеген беләләр. Бу хосуста үзара төрле маршрутлар (бару юллары) коралар. Бу балаларның һәркаюсы үз авылларындагы Сабан туена, әлбәттә, чыга. Күбесе күрше авылларга да баралар. Сабан туе көнне авылда, иртә кояш чыкканнан башлап, ат чаптыру башланганга кадәр, бөтен авыл атка менгән бала-чага берлә гөр килә, чаптырышалар, уйныйлар, сөлге җыючылар алдыннан йөриләр… Һәр бала Сабан туе өчен бөтен кыш буе әзерләнә. Бер тиен, бер тиенләп акча җыя. Бу акча Сабан туенда перәннек, конфет алырга кирәк. Балалар өчен Сабан туе иң зур күңел ачу, иң зур уен-көлке көне санала.

Җәлил Әбелхан.

Кояш. — 1913. — №92. — 10 апрель

САБАН ТУЕ

Сабан туе — авыл халкы өчен иң зур бәйрәм, иң зур күңел ачу. Кыш буе кар астында, бәрән-сарык вә бозаулар белән бергә, бер үк җирдә, сасы һавада көн үткәргән авыл халкы яз башында карлар эреп, кырлар арчылып, бераз кибү берлә сабанга төшкәнче, Сабан туе ясап, авыл читендә, кырда, ачык һавада селкенә, барлык күгәргәннәрен киптерә. Бу Сабан туе көнне кышның ачы бураннарын, бер генә кат тәрәзәле өйдә төрле җирдән искән-өргән салкын җилләрнең ләззәтләрен, такта чәй, кара икмәк вә бәрәңге ашап үткәргән озын кышкы төннәрнең һәммәсен дә, һәммәсен дә авыл кешесе бу көн, Сабан туенда оныта. Үткән көннәрнең һәммә кайгылары, һәммә мәшәкатьләре, һәммә авырлыклары бу көн югала. Ул — бу көн шат. Татарлар тормышындагы бу милли бәйрәмнең бәһасен, әһәмиятен сөйләп вә язып кына бетерерлек түгел. Сабан туе — татарларга гына хас махсус бер милли бәйрәм. Бу бәйрәмнән ул гына тиешенчә файдалана ала. Ул гына юк кына күңел ачуны да зур иттереп эшли ала. Сабан туенда тирә-як авыллардан килгән никадәр рус вә чувашлар булса да, алар безнекеләр төсле ләззәтләнә алмыйлар. Аларга ни эшләсәләр дә килешми кебек. Аларның йөрешләре дә, торышлары да, күз караулары да, сөйләшүләре дә, көлүләре дә — берсе дә татарныкы кебек чыкмый. Барлык көчләнеп эшләнгән җылы күренешләре, аларның бөтен хәрәкәтләре, аз-маз татарча белгән яки беләм дәгъвәсендә булган русның татар телендә сөйләве кебек чыга. Сабан туе — чын-чын милли бер бәйрәм. Аның һәммә эшендә миллият рухы аңкып тора.

АВЫЛДА САБАН ТУЕ КӨНЕ

Бу көн авылда кояш чыгу берлән үк кызу хәрәкәт башлана: урам тулы бала-чага уйныйлар, көләләр, сикерәләр,

йөгерәләр — һәммәсе шат. Бу көн алар кояш берлән бергә йокыдан күтәрелеп, «бүген Сабан туе», дип күбесе ашамыйэчми урамга чыккан, урамга ташланган.

Кояш чыгып, берәр сәгать вакыт үтми, урам тулы ат, атка менгән үсмер егетләр, алар артыннан ат өстендә үзен-үзе тота алырлык кечкенә балалар. Атлар тазартылган, таралган, койрыклары, җаллары төрле аллыгөлле чүпрәкләр берлә зиннәтләнгән. Бу атлар арасында ниндиләре генә юк инде! Монда озын-озын җоннары салынган ябык-җабага тайлар, җеп сыйрак, мичкә корсак буаз бияләр, ләкин күбрәге — авылның иң һәйбәт атлары, сабан эше җитү мөнәсәбәте берлә симертелгән, тазартылган, каралган, эшкә пешсә дә әле картаймаган, яшьлеген бигүк җуймаган гади хезмәт атлары. Бу атка менгән үсмер егетләр — Сабан туенда атларга, кешеләргә биреләчәк приз өчен сөлге җыючылар. Болар һәркемнең капкасы төбенә, өенең тәрәзәсенә туктап, ат өстеннән генә сөлгене алып, бер-берләренә кыстырып йөрүчеләр. Башка балалар исә, зурларга ияреп, алардан бер дә калышмый, ду иттереп урам тулы чабып йөриләр.

Бу вакытта авылның читендә перәннек вә башка нәрсәләр сатар өчен кечкенә генә балаганнар коралар. Сәгать 11ләрдә авылның эчендәге, урамдагы тормыш кырга күчә. Тиздән теге балаганнар тирәсе кап-кара халык берлә тула. Рәсми Сабан туе башланганчы, теге сөлге җыючы егет вә балалардан мөркәб [торган] фирка [төркем] үзара, берәр генә чакрымнан атта чабыштырып алалар — монысын саф балалар Сабан туе дияргә ярый. Чын Сабан туеның башы өйләдән соң, сәгать берләрдә була. Һәр йортның ирләре үзләренә чит авылдан килгән кунаклар берлә кырга, авыл читенә чыга башлыйлар. Урамның бер ягыннан ирләр агымы хәрәкәт итә. Икенчесеннән, бик күзгә чалына торган ачык төсле күлмәк, яулык вә нечкә шәлләрдән, хатын-кызлар баралар. Хатын-кызлар мәйданнан ераграк бер читтә, ирләр аягы басмый торганрак бер уңача җирдә җыелалар. Бала-кызлар шунда ирләр берлә бергүк аралашып йөриләр.

Беренче мәртәбә атлар җибәрелә. Ә бу вакытта исә Сабан туеның кызуы һаман юк әле. Халык берничә кеше берлә төркем-төркем булып, үзара сөйләшеп кенә йөриләр әле. Берәр сәгать вакыт үтә. Атлар килер вакыт җитә. Бу вакыт авылның бөтен тормышы кырда, бу вакыт мәсҗедләрнең манаралары авылның иң җитле, иң кадерле, иң атаклы, иң хәлле кешеләренең кызлары, хатыннары берлә тула. Манаралар язның матур кояшында ялтырап торган калфаклар, укалы камзуллар, ак, кызыл, ачык сары, яшел төстәге материаллар берлә тулы була. Урамда вакыт үтми. «Киләләр!» дигән тавыш ишетелә. Мәйдан тирәсен каплаган гаскәр кеби халык арасында кызу-кызу хәрәкәт башлана. Һәркаюсының баш киләсе атны күрәсе килә. Юл буенча ике яклап тезелгән халык уртасыннан яшендәй атлы уза.

Аннан соң җәяүлеләр чаба. Бераздан икенче мәртәбә атлар килеп, көрәшләр башлана. Хатын-кызлар исә өйләренә агыла башлыйлар.

Көрәш мәйданы. Балалар көрәшүе берлә мәйдан ачыла. Мәйдан уртасында ике-өч яшь егетләр көрәшерлек итеп бер-ике саф утырган, калганнары басып торучы халыктан мөркәб [торган] түгәрәктән гыйбарәт. Мәйдан уртасында күркәмлек өчен генә чыбык яки таяк тоткан авыл куштаннары әрле-бирле йөреп, утырган вә баскан халык арасыннан көрәшергә кешеләрне тартыптартып чыгара. Көрәштә һәр ике тараф чит вә ят авылларныкы булганлыктан, көрәш кыза-кыза авыллап бик шәп якалаш та китә. Бер авылның кешесе тәмам бетә. Менә яхшы ук картайган, бәгъзе ап-ак сакаллы кешеләр кызышып, үз авылы өстеннән хурлыкны җибәрер өчен, сикереп-сикереп чыга башлыйлар. Көрәш мәйданының иң кызык вакыты шушы вакыт. Бәгъзе бу

кызышуның нәтиҗәсендә, зур тавыш күтәрелсә дә, бер җирдә дә сугышка кадәр эшнең җиткәне күренми. Бераз тавышлыйлар да, берәр авторитетный кеше арага катышуы берлә тиздән тәмам тын булып, янә көрәшләр әүвәлге хәлдә дәвам итә. Һичбер полициянең мөдахәләсеннән [арага керүеннән] башка да шундый зур мәйданнарның шома гына баруы, тыныч кына бетүе, татар халкының Сабан туен чын сөюен вә аны бик кыйммәтле санап, башка милләтләр алдында аны күздән төшермәскә тырышуын күрсәтә. Бу да Сабан туеның чын милли бәйрәм идекен ачык аңлата.

«Мин».

Кояш. — 1913. — №99. — 18 апрель

САБАНТУЙЛАРЫ

«Безнең Шушма буенда Сабантуйлары вакыты җитте. Шул мөнәсәбәт белән халык зур расходлар тота вә бөлгенлеккә төшә. Һәм бик күп кешеләр аракы китереп вә аны эчеп вә эчешеп сыйланышалар. Муллалар аракы эчүне киметү вә бетерү юлында халыкка бер сүз дә әйтә алмыйлар. Шулай ук җыеннар да була. Анда да халык аракы һәм бал эчә... Бәс, Сабантуйларын бетергә кирәк иде...»

Идарә: Ошбу мәктүбне бик тырышып вә зур тавыш белән язган Г.Г. әфәнде милләтнең тарихыннан вә милләтнең торышыннан бөтенләтә хәбәрсез бер кеше булса кирәк. Имеш, халык аракы алып кайта да, шуның өчен Сабантуйларын бетергә кирәк иде... Борадар! Хәзер хөкүмәт вә халык аракы сатуны вә исереклекне бетерергә тырыша. Мөселманның шәригате исә күптәннән аракыны сатмаска вә эчмәскә хөкем иткән. Әмма Сабан туен сезнең әллә кайчангы бабаларыгыз ясап килгәннәр. Мөселманның шәригате дә бу гадәткә бәйләнмәгән. Милләтнең рухын күтәрәчәк җаны һаман бар икәнен белдерәчәк шул матур гадәтне, алай тиз генә, газетага берәр бит нәрсә язу белән генә бетереп булырлык нәрсә, дип сез ничек уйлый алдыгыз? Сезнең чак

кына милләткә хөрмәтегез булса, сез ул эшләрне эраткә китерү, аек вә матур бер рәвештә үткәрүнең чараларын күрү юлында исәп йөртер идегез.

Кояш. — 1914. — №385. — 11 апрель

ИСЕРЕКЛЕК БЕЛӘН КӨРӘШҮ ҺӘМ САБАН ТУЕ. ТӘТЕШ ӨЯЗЕННӘН

Хөкүмәтнең исереклек белән җитди көрәшергә тотынуы Тәтеш өязендә дә күренә башлады. 4 нче участканың эшлекле яшь земский начальнигы Рождественскийның бу юлда башлаган хәерле эшләренең җимеше бу көндә сизелә башлады. Бу тирәдәге кабаклардан хәзер инде староста печатеннән башка килгән кешеләргә аракы сатмый башладылар. Кабактан аракы аласы килгән кеше үз авылының старостасыннан ни өчен аракы алырга кирәк булуына печать бастырып, язу алып барырга мәҗбүр. Староста печате белән барган кешегә дә ике бутылкадан артык бирелми. Яшерен аракы сатучыларга кабактан бер дә аракы сатмаска әмер ителгән. Трактирларда да кеше башына ярты савыттан артык бирмәскә кушылган. Бу тирәдә шушы көннәрдә генә ясала торган безнең милли бәйрәм — Сабантуйларына бу хәрәкәтнең, әлбәттә, күп тәэсире булачак һәм бар. Менә шушы көндә генә булган бер Сабан туе әүвәлге Сабантуйларына бер дә охшамый: аек күз, аек йөреш, аек тормыш, аек халык. Ямьле, күңелле! Ни бер тавыш, ни бер кычкырыш! Чын-чын милли бәйрәм. Сабан туе шикелле милли бәйрәмнәребезгә электә хатын-кызлар күп катыша алмый иделәр: рәтлерәкләре, үзләренең кешелекләрен югары тотканнары шул исерекләр эчүеннән, аларның, читтән генә булса да, яман сүз әйтеп китүләреннән куркып, Сабан туена бер дә чыкмый иделәр. Чыкканнары да мәйданнан әллә кайда, читтә йөреп, ерак торып бернәрсә күрә алмыйлар, Сабан туенда үзләрен ят кеше саныйлар иде. Моннан соң инде хатын-кызларыбыз да милли бәйрәмнәребезгә, Сабантуйларыбызга катыша башларлар. Чөнки иген эшләрендә, авыл тормышында ирләр белән бергә булырга өйрәнгән авыл хатын-кызлары авыл бәйрәмнәрендә дә бергә була алырлар, дип фалланырга мөмкин. Хасыйл исереклек белән җитди көрәшүгә, башка милләтләрдән элек без, мөселманнар,

шатланабыз һәм шатланырга бурычлыбыз.

Кояш. — 1914. — №389. — 16 апрель

КАЗАН АРТЫНДА САБАН ТУЕ

Казан арты халкы инде Сабантуйлары вакытын көтеп торалар. Бу көннәрдә боларны ясау да башланса кирәк. Моның өчен халык хәзерләнә башлады. Чыпчык, Тугаш кеби авыллардагы казёнкалардан Сабан туе өчен бу тараф халкының тәгъбиренчә тонык китерелә башлады. Мәзкүр тонык илә кәефләнгән халык бәгъзе авылларда ат аягы кыздыра да башладылар.

Исереклек илә көрәшү мәсьәләсе Казан арты мужикларының да колагына кергән. Урамнарда: «Думада козёнкаларны бетерәләр икән. Бары Казанда ике генә җирдә калачак, имеш. Ул ике җирдән алганда да мелладан яки старостадан язу алып барырга кирәк икән, боларның язуыннан башка бирмиләр, имеш», — дип үзара сөйләшәләр.

Кояш. — 1914. — №393. — 21 апрель

ЗӨЯ ӨЯЗЕНДӘ САБАНТУЙЛАРЫ

Зөя өязендә Сабантуйлары күңелле генә булып үттеләр. Бер-ике авылда булган җөзьи [кечкенә] генә тавышларны игътибарга алмаганда, бөтен бу тирә Сабантуйлары әдәп даирәсендә генә уздылар, дияргә ярыйдыр. Сабантуйларының мондый матур сурәттә үтүләренә сәбәп — муллаларның катышуыдыр. Алар катышса, кычкырыш та булмый, тавыш та булмый.

Бездә Сабан туе ясау, гадәттә, болай була: наборга барасы егетләр ил имамнарыннан рөхсәт сорыйлар да, сөлге, акча, җаймә вә йомырка җыялар. Сөлгеләрнең иң яхшы вә иң матуры узган Сабан туеннан соң төшкән киленнәрдән җыела. Җыелган нәрсәләрнең бары да ат чаптырасы көнгә кадәр муллалар кулында саклана.

Ат чаптырасы көнне бер бик һәйбәт сөлге авылның бер басу капкасы янындагы озын агачка эленгән була. Моны күреп, күрше авыллардагы руслар да Сабан туена киләләр.

Бу тарафтагы күп авылларда өйләдән соң хәзрәтләрне чабыш вә көрәш мәйданына алып баралар. Анда аларга уртача бер сөлге биреп, дога кылдыралар.

Чабыш вә көрәш мәйданындагы тәртип болай була: беренче бүлек — атлар чаптыру. Болар ике-өч чамасы чакрым җирдән чабалар. Икенче бүлектә — кешеләр йөгертү. Монда элек балалар, соңра зурлар йөгерешәләр. Өченче бүлектә — көрәш. Көрәш мәктәп балаларыннан башланып, әкрен-әкрен зурларга күчә бара. Ниһаять, руслар илә татарлар көрәшә.

Күп авылларда кешеләрне көрәшкә кушу вә көрәшкәч аерып алу авылның старостасына йөкләтелә. Көрәшүчеләрнең хәрәкәтенә дикъкать итү бүләк вә сөлге җыючы егетләрнең вазифасы була. Алар көрәшченең эшендә хыянәт итеп-итмәвен бик дикъкать илә карап торалар. Батырларга бүләк бирү дә болар эше була: ике кешене егучыга акча, өчне егучыга сөлге бирәләр. Һәр авыл үзенең бер төбәгән кешесен батыр итеп калдырасы килә, чөнки үз авылыннан батыр чыгуның мәгънәви кыйммәте булган кеби, мәйданда батыр булып калучы биш-алты аршинлы сөлге дә ала. Татарлар, русларга караганда, көрәш эшендә сәләтлерәк булалар. Чөнки алар мәктәптә вакытларында ук атна кичләрдә мәктәп эчендә көрәшеп, идән сындырырлык дәрәҗәдә бер-берсен атышып өйрәнәләр. Көрәшкәндә аяк чалып егу катгый тыеладыр. Көрәшче өч юлның берсе илә егарга тиеш: билдән кысып күтәреп алып, янбаш берлә атып, йә баш аркылы җибәреп, мәгълүбне [җиңелгәнне] аркасы илә җиргә төшерергә кирәк. Көрәшүгә һәркемгә рөхсәт булып, әдәп даирәсендә һәркемнең көрәшергә хакы бардыр.

Дүртенче вә бишенче бүлекләрдә сикерешү вә тартышу була. Мондагы батырларга тиешле бүләкләр бирелә.

Бу эшләрнең соңында муллалар кайтып китәләр. Алар киткәч, яшьләр

гармун вә скрипкада милли көйләрне уйнап, җыелган халыкны озаталар. Авылга кайткач, һәркем үзенең кунагын вә күрше авылдан килгән белештанышын өенә алып кереп, сыйлап вә хөрмәт итеп озата. Шуның илә Сабан туе тәмам була.

Кояш. — 1914. — №397. — 25 апрель

САБАНТУЙЛАРЫ

Чирмешән буендагы Әбдеки, Карабиккол, Денис авылларында Сабан туе апрельнең 15-17ләрендә булып узды.

Менә 15ендә авыллар инде кызыл төс алган. Ире-хатыны, кызы, баласы-чагасы һәммәсе үзләренең иң матур вә иң дә яңа киемнәрендә урам тутырып йөриләр. Бөтенесе шат, мәсгуд [бәхетле], өсләреннән фарыз төшкән кебек кыланалар иде. Авыл кырыендагы ындырлар артында, зур агач киртәгә сөлге дә чыгарылып асылган, ул язгы җил белән җилферди. Бөтен авылыбыз халкын үзе тора торган яшел чирәмгә чакыра, урам тулы халык та шуның чакыруын кабул итәләр төсле иде.

Бер тыкрыктан егетләр, ирләр чыгып китсәләр, икенче тыкрыктан төркем-төркем кызлар агылалар. Тегендә, ындыр артында түбән оч ягын кып-кызыл хатын-кыз сыра башлаган. Инде элеккеге простойлыклар беткән, борынгы замандагы француз күлмәк вә яулыклардан җилләр искән. Кызларның күлмәкләре аршины 25-35 тиенлек сатин, башларында 4-5 сумлык шәльяулыклар. Аякларында һәркаюсының резинкә галош я кәвешләр[5], теге килешле итеп тугылган матур киндерле чабаталар юк, аны кигән адәмне бөтен авылда да тапмассың. Аның сатин күлмәге, резинкәсе[6] булмаса, ул инде Сабан туена чыкмыйча тора.

Яка чылбырлар, хаситә, зур вә киң беләзекләр дә күренмиләр, алар урынына шомартылган, сарылы-яшелле ташлар урын тотканнар.

Теге җиңнәре укалап бетергән көмеш каптырмалы казакилар да юк, алар урынына зур шәлләр кереп баралар.

Егетләр инде тагын купшы, тыгын фарсит итә төшәләр. Алар үзләренең кая басканлыкларын белмиләр, аларга бу көн бик кыйбатлы, алар бу көн бөтен эшне, бөтен кызыкны эшләп бетермәкче булып йөриләр. Башларында бәйләгән Казан бүркесе, өсләрендә тужурка чалбар, аякларында резинкә галош. Әүвәлге замандагы тезгә чаклы җире җанкайлары тарафыннан чигелгән чалбар балаклары да күренми. Бу көннәрдә инде бөтен авыл шат, бөтен кеше үзенең нәрсәдәндер килгән шатлыгын әйтеп бирә алмый. Ул үзе дә белмәгән бернәрсә өчен шатлана, ул бер урында тора алмый, ул көнне бөтен авыл нурга чумган-чолганган.

Теге матур зифа тәнлеләр, бөтен авылга, аның урамнарына, тыкрыкларына, хәттә аның навозлык башларына ямь керткәннәр. Бөтен авыл гөж килә, һәммәсе Сабан туена, милли бәйрәмгә ашыгалар, шул сөемле бәйрәмебез белән үзләрен юандырмакчы булалар.

Дөрес, бу көн чырай сытып йөрүчеләр дә булгалый. Алары инде — муллалар җәмәгате. Алар бу көнне ярканат кебек өйләреннән чыкмыйча яталар. Ходайның якты кояшы ярканатка очарга ирек бирмәгән кебек, бу милли бәйрәм дә ялган суфилык сатучы муллаларга күтәрелергә, очарга ирек бирмидер. Инде алар үзләренең өйләреннән тешләрен шыгырдатып, ничә еллардан бирле тырышып-тырышып та Сабан туен бетерә алмаганлыкларына көенеп яталар. Җитмәсә тагын кайсыбер яшьләрнең Сабан туен химая итүләрен динсезлектән башка бернигә дә багышламыйлар. Аларга халыкны укытып, вәгазьләп, юл күрсәтеп, авылдагы эчке, яман гадәтләрне бетерү тиеш иде. Югыйсә үзләре итәк астыннан әллә ниләр эшләп

[5] Кәвеш — йомшак күннән тегелгән кунычсыз аяк киеме.
[6] Резин галош.

бетерәләр дә, мескин халыкның елда бер әйләнә торган милли Сабантуйларын әллә нәрсәгә юрап бетерәләр.

Без, Сабантуйларын бетергәнче, аны әдәби юлга салсак, шактый гыйбрәтле күңел ачу урыны булыр иде.

3 авылда да атлар узыштырдылар, кечкенә малайлардан башлап картларгача үзләре узыштылар, көрәштеләр, сикерештеләр, көчләрне сынашып тартышып та карадылар.

Хатын-кызлар үзләре аерым гына, икенче бер төштә уйнадылар, йөгерештеләр, куыш уйнадылар. Үзләре белә торган бер уен да калмады. Һәр авыл саен җыелган уннан артык сөлге, ничә йөзләп күкәйләр, һәммәсе дәрәҗәсенә карап, узган атларга, узучыларга, егучы батырларга өләшенде. Мөкяфәт [бүләк] алучылар билләренә зур кызыл озын сөлгеләр бәйләп, мактаныша-мактаныша китеп бардылар.

Узган, матур, сөлек кебек атлар, зифа буйлы үсмер егетләр, аларның батырраклары тагын әллә кемнәргә җәй буе сөйләнергә, икенче Сабан туе җиткәнче бөтен халык өчен мөхакәмә кылынырга [хөкем ителергә] зур сәрмая булып калды. Меллалар никадәрле җикеренмәсеннәр, халык киләсе елга тагын шәбрәк, тагы зуррак ясыйсы иде, дип йөрәксенеп калды.

Менә шул халык көченә әдәби көч тә кушылса, Сабантуйлары тагы да хозур, авыл халкы өчен күңел ача торган җир булыр иде. Әллә кайчаннан бирле ясалган, нигезләнеп килгән бу туйны бетерү кайда, бәлки, аның булуы өчен шатланырга, аны халык арасында тагын да тамырландырырга, милли гадәтне тештырнак белән сакларга тиештер, дим.

Зөфәр Ягъкуби.

Кояш. — 1914. — №399. — 28 апрель

КАЗАН ӨЯЗЕНДӘ

Казан өязендә Сабантуйлары үтеп китте. Боларда яңалык күренмәде. Шунысы бар ки, Сабан туе мәйданында бик күп очрый торган исерекләр бу ел күренмәде. Олуг Әтнә мәйданында бер генә исерек күренде исә дә, полиция тотып алып, аны каравылга илтеп япты.

Сабан туеның кайсы авылда, кай көн буласы Казан өязендә базарларда тәгаен ителә. Бу сәнә, гөнаһ шомлыгына каршы, Күшәр авылы илә Иске Тазлар авылының Сабантуйлары икесе дә бер көн — чәршәмбе көнгә тәгаен ителгән. Бер-беренә күрше бу ике авылда бер көндә Сабан туе булуны, Күшәр картлары, мәслихәт күрмәгәннәр. Шул сәбәпле, Иске Тазлар картларына мөрәҗәгать итеп, Иске Тазлар Сабан туен икенче көнгә күчерүләрен үтенгәннәр. Күшәрләрнең бу үтенечләренә каршы, Иске Тазлар картлары бу җавапны биргәннәр: «Юк, булмас, мөмкин түгел! Бездә әбҗәд укылды инде!» Әбҗәд укылу болай икән: Иске Тазлар мулласы җомга соңында: «Җәмәгать! Фәлән көн әбҗәд шәриф укылыр. Аның иртәсе фәлән көн Сабан туе вә мәйдан булыр», — дип әйтә икән. Әбҗәд укылган көн «әрәпә-гарәфә» [бәйрәм алды] көн булып, хәзрәт чиләк тоттырып, малайларны авыл буенча йөреп йомырка җыярга чыгара вә халыкның иң фәкыйре икешәр вә байлары бишәр-алтышар йомыркадан чиләккә салалар, балалар да аны әбҗәд укып кабул итәләр.

Чиләк тулгач, балалар йомыркаларны хәзрәткә китерә вә хәзрәт тагын әбҗәд укып дога кыла икән. Бу вакыйга булганның иртәгесе көн Иске Тазлар карьясендә Сабан туе була вә булмый калу мөмкин түгел икән.

Кояш. — 1914. — №404. — 4 май

Фотолар Д.Шәрәфетдиновның «Татар барда — Сабан туе бар» (2003) исемле китабыннан алынды.

*Текстларны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде* ■


З.Бәширов фотосы

САБАН ТУЕ БИЗӘКЛӘРЕ

Мөхәммәт Мәһдиев
(1930-1995)

БЕРАЗ ГЫНА ТАРИХ...

Бу хәл 1920 елның 27 маенда була. Ул көнне Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советы Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү турында карар кабул итәләр. Бу тарихи декретка В.И.Ленин, М.И.Калинин һәм А.С.Енукидзе кул куялар. Ә 25 июнь көнне Казан Советының Казан губернасы партия, профсоюз, комсомол органнары вәкилләре белән берлектә уздырылган тантаналы утырышында Татарстан АССРның Вакытлы Революция Комитетына власть тапшырыла... Республикабызның туган көне татар халкының бик борынгыдан килгән хезмәт бәйрәме белән бер көннәргә туры килә. Ул бәйрәмнең исеме — Сабан туе... Борынгы дигәннән, аның тамырлары бик еракларга китә...

Кешеләр кайчандыр таштан корал, юан агачларны чокып көймә, балык сөягеннән энә ясаганнар, юкәдән чабата үргәннәр, ике тәгәрмәчле арбалар әмәлләп йөк тартканнар... Цивилизациянең үсүе, социаль хәлләрнең үзгәрүе, сыйнфый көрәшләр нәтиҗәсендә бик күптөрле хезмәт ысуллары алмашынган, кирәксезгә чыккан, онытылган. Болар турында инде без тарих китапларында укып кына беләбез. Ләкин урта полосадагы кешелек җәмгыяте өчен бер дә искерми торган бер хезмәт бар — ул игенчелек. Дөрес, җирне эшкәртү, аннан файдалану формалары гасырлар буе үзгәреп торган, әмма хезмәт халкының туклану нигезе булган икмәкне җитештерү кешелек җәмгыятенең төп шөгыльләреннән булып килгән. Игенчелек — Идел буенда яшәгән борынгы Болгар халкының төп кәсебе булган. Игенче болгарларның нәселе — Идел буе татарларында да ул шулай көнкүрешнең төп тармагы булып килгән. Шунлыктан Идел буе татарларының бөтен әдәбиятында, халыкның авыз иҗатында, гореф-гадәтләрендә игенчелеккә бәйле бик күп йолалар чагылыш тапканнар. Бу йолаларның барысы өчен дә уртак бер сыйфат бар, ул — игенчелек эшен изгеләштереп карау, аңа табыну. Татар крестьянының гасырлардан бирле килгән тирән ышануынча, иген иккән кеше начар холыклы, бозык табигатьле булмый. Иген иккән кеше начар юлда йөрми, кан коймый, мәкерле булмый, дустына, иленә хыянәт итми. Иген игү — егетлек, булганлык билгесе, саф күңеллелек билгесе. Икмәк үстерү — иленә, халкына игелек күрсәтү дип бәяләнгән. Әнә шуңа күрә XVII йөз татар шагыйре Мәүлә Колый үзенең «Хикмәт»ләрендә игенчелек хезмәтенә дан җырлаган, М.Колый фикеренчә, «хак колларына игенчелек — иң хуш һөнәр, иген иккән кешенең дөньялыгы вә ахирәтлеге — үз кулында»...

Дөньяда башка бер генә хезмәтнең дә, ихтимал, шундый хөр, тарихның үзе кебек чал, милли дә, интернациональ дә

Р.Якупов фотосы

үз бәйрәме юктыр. Ә игенчелекнең шундый бәйрәме бар. Ул бәйрәмнең туган җире — Идел буе болгарлары яшәгән төбәк. Ул бәйрәмнең исеме — Сабан туе. Элек ул язгы кыр эшләрен башлау бәйрәме булган. Хәзер исә Сабан туе — язгы эшләрне төгәлләү бәйрәме.

...Сабан эше — крестьян өчен иң җаваплы, иң киеренке хезмәт. Крестьян моңа кыштан хәзерләнгән, орлыкларны кат-кат тикшергән, атын көрәйткән, сукасын көйләгән, сбруйларын яңарткан. Сабанда ул кырыкмышны беренче тапкыр тырмага җиккән, 10-11 яшьлек малаена беренче тапкыр дилбегә тоттырган. Тула оек, яңа чабата кигән күк киндер ыштанлы татар малае тырма тагылган ат белән беренче мәртәбә җир өстенә кереп киткәндә җир башында аның әти-әнисе карап калган: бу — аны зур юлга, изге хезмәт юлына озату булган. Яңа тула оекның балтырына чабата киндерәләрен матурлап бәйләгән әти кеше орлык тубалын күтәреп җир өстендә аяк атлаган. Иң беренче адымында ул орлык белән бергә ап-ак эре тавык йомыркаларын җир өстенә сипкән. Яңа орлыклар шулай эре, таза булып өлгерсеннәр, янәсе...

Бер адым — тубалдан бер уч орлыкны, ярымтүгәрәк ясап, әйләнә-тирәңә сибәсең. Икенче адым — икенче учны. Игенченең күзе үткен, ата-бабадан килгән тәҗрибә зур: җирнең икенче башыннан килгән чабата эзеннән нинди ара калдырасы, адымны ничек атласы, кулны нинди хәрәкәт белән селтәсе — ул барысын да белә. Ә зәңгәр күктә тургай җыры ишетелә, кара җирдән сулышны киңәйтә торган пар күтәрелә, крестьянның күңеле, йөрәге җиргә якын кешедә генә була торган изге теләкләр белән тула: мулрак булсын иде бу җир дигәннәре, азрак булсын иде ул җирдән түли торган имана налогы! Тәүфыйклы булып үссен иде аның бүген тырмага чыккан малае, игенче булсын иде ул! Тигез булып тишелсен иде игеннәр, җылысы да, яңгыры да булсын иде, матур итеп Сабан туен уздырыр идек бер!

Крестьянның миен әнә шундый уйлар били. Хәер, әлеге күк киндер ыштанлы бәләкәй «крестьянның» уйлары да шул тирәдә. Тиздән Сабан туе! Менә инде егетлекне күрсәтә башларга вакыт. Нәрсә, улмы быел иртә таңнан торып тургайлар җырын тыңлый-тыңлый җир тырмаламаган, улмы сука көйләргә өйрәнмәгән, улмы күз ачып йомганчы ат җигә белми? Ә татар малае өчен ат җигә белү, ихтимал, гасырлар буенча егетлекне үлчи торган бер критерий булып килгәндер... Кичке уеннарда кызлар юкка гына җырламыйлар бит:

Ат тугарып җигә белми,
Кызлар сайлаган була...

Ат көйгә генә атлый, аның һәр адымына җавап биргәндәй камыт агачы шыгырдый, аяк астында — күпергән кара җир, тырма артында — каргалар... Тизрәк, тизрәк җитсен иде ул Сабан туе...

КАЯ ГЫНА БАРСАҢ...

Татарстанда бер тапкыр булган кеше безнең як табигатенә гашыйк булмый кала алмый. Сез, Тукай әйткәнчә, «галибанә яктырып» ал таң атканын күзәтегез. Әгәр сез бу вакытта Идел өстендә икәнсез, көймәгезне туктатыгыз да тыңлагыз: мәһабәт Идел сезнең йөрәгегезне бөек туган илебезнең киңлекләре белән тоташтырыр, Идел буендагы нарат урманнары кояшның беренче кызгылт нурларына коеныр, сез әкияттәгедәй серле декорация эчендә калырсыз. Идел агышын тыңлагыз, таң атканда аның агышы бик серле була...

Әгәр сез Ык буйларына барып чыксагыз, андагы әрәмәлекләр, андагы су буйларыннан аерылып китә алмассыз. Башка бер җирдә дә сандугачлар андый ук музыкаль тавыш белән сайрамыйлар. Әгәр инде сез Арча, Балтач ягы урманнарына килеп чыксагыз, андагы матурлыкка таң калырсыз. Калын-калын чыршы, имән, нарат, каен урманнарының җиләкле аланнарында йөргәндә Тукай «Шүрәле»сенең нәкъ менә шунда гына тууы мөмкин булганын аңларсыз. Җил искәндә ул мәһабәт

агачлар шавын тыңлагыз: колагыгызда, һичшиксез, Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетындагы музыка яңгырар.

Язгы сабан вакытында кара туфраклы Сарман яки Буа якларына чыгыгыз: андый матурлыкны, андый байлыкны сез тагын кайда күрерсез? Күпереп яткан гөлбалчыгыдай җир өстеннән диңгездәге кораблар сыман тракторлар килә. Кара туфраклы басу өстендә рәшә. Җир исе, парлы балчык исе, һавадагы тургайлар җырына тракторларның тигез гөрелтесе кушыла.

Әгәр сез безнең Казан янындагы Ослан тавына килеп чыксагыз... Хәер, Татарстанның кайсы почмагына гына барып чыксагыз да, сез ул урынга мәңгегә гашыйк булачаксыз...

Сабан туе — әнә шул игелекле җирдә мул уңыш үстерүче җир хуҗаларыныкы. Бу бәйрәмдә борынгыдан килгән бик күп күркәм гадәтләрне әле дә саклыйлар. Арадан берсе...

САБАН ТУЕНА БҮЛӘК ҖЫЮ

Менә-менә иртәгә сабан туе... Урамда гармун тавышы. Көпә-көндез. Элегрәк кичен ишетелгәләгән гармун тавышына да чукмар башлы таягын тотып килеп җиткән, егетләрне тараткан карт хәзрәт тә бүген берни эшли алмый. Тәкъва картлар, куштаннар да бүген беркемне дә уен-җырдан, музыкадан тыя алмыйлар. Чөнки иртәгә — Сабан туе, хезмәт туе. Әтисе кушканга гына аратирә мәчеткә йөргәләгән крестьян егете, бүген, бернигә дә карамый, арбага менеп иптәшләрен кочаклап утырган да, урамнан җырлап бара. Ә ат дугасында кызыл башлы сөлгеләр, чәчәкле-чуклы эскәтерләр, егетләрнең берсе нәкъ шундый ук әйберләр бәйләнгән озын колганы арба өстенә күтәргән. Ат бизәлгән — тәңкәле йөгән, тәңкәле шлея, дугада пар кыңгырау, ыңгырчакларда шөлдер, кызыл чуклар асылынган...

Урамнан арбага төялгән егетләр төркеме килә. Юк, бу төркем генә түгел, бу — игенчелек белән көн күргән татар халкының гасырлар буенча хәзерләнгән филармониясе, консерваториясе, фестивале, халык хоры килә...

Әйдә барыйк бер җиргә,
Кемнәр тияр бер иргә;
Безгә каршы килгәннәрне
Йөретмәбез бу илдә.

Гармун тавышы якынлашкан саен капкалар ачыла, атлы арба артына балалар җыела, карт-коры вәкарь белән генә капка төбенә чыгып баса, кыз-кыркын йорт тирәсендә йөгерешә башлый. Ләкин арада иң нык дулкынланганы ата да, ана да түгел. Хәтта буй җиткән кыз да түгел. Йортта иң дулкынланган кеше — быел төшкән яшь килен. Чөнки бүләкләр эленгән колгада иң күренекле урынны аның бүләге, быелгы яшь килен бүләге алырга тиеш. Бүләк уңышлы сайландымы икән? Ошатырлармы икән? Кеше арасында хур итәрлек түгелме? Бит, быелгы яшь киленнең бүләге мәйданда батыр калган кешегә биреләчәк. Әнә шулай дулкынлана-курка яшь килен егетләр кулындагы колгага кыз вакытта үзе утырып чиккән кызыл башлы ап-ак киндер сөлгесен элә. Бу — авылга яшь киленнең ил алдында беренче имтихан тапшыруы. Хәер, икенчеседер. Беренчесе — килен булып төшкән көннең иртәгесен чиләккөянтә күтәреп чишмәгә суга барганда тапшырылган иде. Анда да менә шулай каушады, аяк атлаулары ялгышты. Анда да капка ярыгыннан бөтен урам халкы карап калды, килеш-килбәте ничек? Аяк атлаулары матурмы? Суы чәчрәмиме?

Сөлге колгага бәйләнде. Колга тоткан егет арбага менеп утырды. Гармунчы гармунында аккорд бирде. Ә колга тоткан егет яшь киленгә мутланып күз кысты да, сөрән салды:

— Яшь киленнең сабан туе бүләге котлы булсын!

Шуны гына көтеп торган егетләр хоры урам яңгыратты:

— Һә-лә-лә-ләү!

Аннан җыр белән кузгалып киттеләр.

Бу — элек шулай булган. Ләкин хәзер дә шулай. Сабан туе бүләген бүген дә шулай җыялар. Нигә аны җыярга,

колхоз хисабыннан исәпләтеп кибеттән генә алсаң булмыймыни? Әнә бит колхозлар хәзер ничек бай, культурасәнгать мәсьәләләренә әллә ничәшәр мең сум акча тоталар. Хәер, Сабан туена да тота колхоз идарәсе акчаны. Әмма хикмәт анда түгел. Хикмәт — халыкның бу бәйрәмгә үз кулы белән, үз әйбере белән катнашырга теләвендә. Чөнки аның борынгыдан килгән традициясе шулай. Мең еллар элек әнә шулай өйдән-өйгә йөргәннәр, колга башына бәйләп сөлге-эскәтер җыйганнар. Бу — әле дә шулай…

ШӘРИГАТЬ КАНУННАРЫН ҖИМЕРЕП…

Сабан туе булсын да, анда хатынкыз булмасын, имеш. Безнең үткәнебез турында кайберәүләр шулай язгалыйлар. Имеш, ислам дине изүе астында яшәгән татар хатын-кызлары андый бәйрәмнәрдә катнаша алмаганнар, алар өйләрендә бикләнеп ятканнар… Дөрес түгел!

Сабан туе булсын да, анда хатынкыз булмасын, имеш! Яшь-җилкенчәк, хатын-кыз карап тормаганда көрәшеп, егетлек күрсәтеп буламыни? Кызлар карап тормаганда йөгерештә узышып, ат чабышында ярышып буламыни? Биек колга башына үрмәләп менүнең ни кызыгы бар, әгәр аста карап торучылар арасында әниең, сеңелләрең һәм, ниһаять, күптәннән күзең төшеп йөргән бер чибәр кыз булмаганда!

Идел буе татарларында шәригать кануннары ул көнне чигенеп торган! Игенчеләр бәйрәме бит ул, дини бәйрәм түгел. Монда яшьләр очрашканнар, күз кысышканнар, бүләкләр алышканнар, җаен туры китереп сөю сүзләрен әйткәннәр, вәгъдәләр бирешкәннәр. Диннең каты законнары хезмәт халкының бу бәйрәме алдында чигенеп торган…

…«Дин изүе астында яшәгән татар халкының уен кораллары булмаган. Бердәнбер корал кубыз булган», дип язган кешеләр белән дә килешүе кыен. Тормышта, фактта алай булмаган…

…Еллар буе татар халкының этнографиясен, фольклорын өйрәнгән рус галимнәренә мөрәҗәгать итик. Казан университеты профессоры Карл Фукс, XIX гасыр уртасында Казан тирәсе авылларындагы татар фольклорын өйрәнеп, аларның яраткан музыка кораллары гармун икәнлеген әйтә. Моны башка чыганаклар да раслый. «Казанский телеграф» газетасы, мәсәлән, татарларның сабан туе турында хәбәр итеп болай яза:

«Татары привезли с собой кто скрипку, кто гармошку и каждый, кто как умел, изливал свои чувства на этих незатейливых инструментах. Своеобразная татарская мелодия, заунывные песни и пляски слышались повсюду» (1912, № 577).

Юк, сабан туе йоласы, аның җырлары буш урында гына барлыкка килмәгән. Ул җырлар, йолалар гасырлар буе халык күңелендә, телендә яшәгән, шомарган. Ул йолалар халыкның үзе кебек көчле, яшәүчән булган. Әнә шуңа күрә алар безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәр.

Сабан туе гөрләп узган. Чәчәккә күмелгән болынга кыш буе сандыкта сакланган кадерле киемнәрдән нафталин исе таралган, кыш буе аулак өйләрдә җеп эрләгән, киндер сугып, бирнә әзерләгән кызлар беренче тапкыр шулай иркенгә чыкканнар, батыр егетләрне күзәткәннәр. Ә егетләр бил алышканнар, ат чабыштырганнар, колгага менгәннәр, бау тартышканнар, чүлмәк сугыш, капчык сугыш уйнаганнар… Гасырлар буе шулай. Ә озын таяклар тоткан аксакаллар — авылның могтәбәр картлары — мәйдан эчендә тәртип саклап йөргәннәр. Хәзер — фән һәм техникада никадәр алга киткәннән соң! — Сабан туе комиссиясе кызыл япкан өстәл янында утыра, председательнең кулында микрофон, велосипедчылар ярыша, волейбол, баскетбол ярышы — ләкин традицияләр яши. Түгәрәк эчендә озын таяклар тотып, тәртип саклап йөрүче картлардан

башка бер генә Сабан туе да узмый. Моннан биш йөз ел элек, җиде йөз ел элек ничек капчык белән сугышсалар — әле дә шулай. Борынгы заманнарда ук ничек кашыкка тавык йомыркасы куеп, кашык кабып йөгерешсәләр — әле дә шулай. Матур гадәтләр шулай сакланалар. Матур гадәтләр дигәннән, шуларның берсе атка бәйле...

Ат дигәндә татар халкы нәкъ Дон казагы шикелле. Ат аның гомерлек юлдашы, иптәше, туйдыручысы булган. Татар халкы атка бервакытта да хайван дип карамаган. Ат — ышанычлы терәк. Караңгы төннәрдә кара урманнарны үтәр өчен татар агаена яхшы ат кирәк булган. Ат белән ул сәфәр йөргән, иген иккән, лашман хезмәтенә чыккан — патшага урман кискән. Ат атланып татар агае Пугачёв явына киткән, боярларга каршы көрәшкән...

Әнә шуңа күрә Сабан туе программасының иң кызык өлеше — ат чабышы. Моңа 10-15 яшьлек малайлар катнаша. Чабыш атларын алдан ук әзерлиләр, аерым ашаталар. Сабан туе көннәре якынлашканда атның «аягын кыздыралар», спортчылар телендә әйтсәк, «разминка» ясыйлар.

Татар халкының классик язучысы Галимҗан Ибраһимовның берничә әсәрендә ат чабыштыру, чабыш атлар турында языла. «Яшь йөрәкләр», «Алмачуар» кебек әсәрләрне укыганда ат чабыштыруның халык күңелендә никадәр зур урын алганын күрергә мөмкин. Бу — бик борынгыдан килгән гадәт. Чабыш атларын элек-электән халык бик яратып караган, аларның даны еракларга киткән. Чабыштан килгән атларны мәйдан уртасында, түгәрәк эчендә әйләндерәләр. Шулвакыт хатын-кыз уртага чыгып, атларны бүләк белән күмә.

Һәр ярышта кемдер беренче була, кемдер уртадарак, кемдер иң ахырда... Ат чабышында да шулай. Беренче килгәнне сырып алалар, мәйдан уртасына атның йөгәненнән саклап кына тотып алып керәләр, әйләнәдә йөртәләр. Ат өстендәге малайның авызы колакка җиткән. Атны инде бүләк белән күмгәннәр, хайван димә, ул да шушы моментның тантанасын сизгәндәй, башын югары күтәреп «атлар горурлыгы» белән горурланып атлый. Икенче, өченче... Алтынчы килгәннәргә инде игътибар кимрәк. Ләкин кемдер иң соңгысы бит! Аңа да мәйдан эченә керергә кирәк, аңа да әйләнергә кирәк. Бәлки бөтенләй кереп тормаскадыр? Халык шаулап көлсә, авыз ерып мыскыл итә башласалар нишләрсең?

Башка халыкта андый гадәт бардырмы, әмма Идел буе татарларында бик күркәм бер традиция яши: сабан туенда иң соңгы булып килгән атка бүләк бирү гадәте ул. Моны өлкән яшьтәге хатыннар, карчыклар эшли. Алар сабан туена килгәндә махсус рәвештә бер бүләк алып киләләр: кыз вакытта үзе чиккән сөлге, эскәтер, ашъяулык, баш яулыгы... Соңгы килгән атны әнә шулай карчыклар, өлкән яшьтәге хатыннар (күбрәге тол хатыннар) чорнап ала, ул атның башыннан сыйпыйлар, муеныннан кочаклыйлар, йөгәненә бүләк бәйлиләр... Татар халкының элек-электән атка иптәш, дус, туйдыручы итеп карап килүеннәндер инде ул гадәт. Бу вакытта мәйдан уртасында ак яулыклар, чуар эскәтерләр белән күмелеп калган атка ул хатыннар һич тә хайван итеп түгел, ә тормышның нindидер бер гаделсезлеге аркасында кимсетелгән бер адәм баласына карагандай карыйлар. Бәйрәм — гомумхалыкныкы, аннан бер җан иясе дә китек күңел белән китәргә тиеш түгел. Аннан соң, кимсетелгәннәргә ярдәм кулы сузу — ул инде элек-электән хезмәт халкының матур гадәте...

ТАТАРЧА КӨРӘШ. МӘЙДАН БАТЫРЫ

Татар авылларында хезмәт сөймәгән, эш эшләмәгән кешегә борынгы заманнардан килгән гадәт буенча урын булмаган. Татар фольклорындагы меңнәрчә җырлар, меңнәрчә мәкаль эш сөймәс ялкауларны тәнкыйть итә. Эшсезнең

ил өлкәннәре каршында да, егет-кызлар арасында да абруе юк. Ләкин авылда бер-ике кеше сабан туе алдыннан унунбиш көн кыр эшләренә йөрмәгән. Моңа халык үзе юл куйган, үзе шулай кушкан. Хәллерәк йорттан булса ул кешегә мондый вакытта зур бер сарык суеп ашатканнар, алдында теләгәнчә йомырка, сөт-май торган. Теге кеше ял иткән, ашаган, көч җыйган...

Ул — көрәшче. Сабан туенда аңа шушы авылның данын яклап көрәшергә кирәк булачак. Картларның бөтен өмете шунда. Кайвакытта батыр егет күрше авыл сабантуйларына барып та көрәшә, бер елда берничә урында батыр кала. Моның дәрәҗәсе тагы да зуррак. Көрәшченең татар халкы арасында абруе искиткеч. Казан артында татарча көрәшнең бөтен нечкәлеген, әдәп-әхлак кагыйдәләрен белгән көрәшчеләр авыллары бар. Элек-электән Казан артында Курса авылы егетләренең көрәшче буларак даны зур иде. [...]

Сабан туенда батыр калган егетнең авыл халкы алдында дәрәҗәсе — искиткеч. Батырны һавага чөю — мәйданның соңгы акты. Батырның алган бүләкләрен, гадәттә, аның туган-тумачасы җыеп ала, батыр аларга кулын да тидерми. Аны уртага алып саклап кына ат янына алып киләләр, атның дугасын аның бүләкләре белән бизиләр, батыр утырган ат кузгалу белән мәйдан тарала.

Батырга бүләк бирү — сабан туе программасының төп кадагы. Батырга элек-электән тәкә бүләк иткәннәр...

Батыр утырган ат шөлдерләр, кыңгыраулар белән авыл урамына кайтып кергәндә авыл дөрт итеп тора: җиңүче кайта! Капка төбе тулы халык, барысы да аңа елмаялар, кул болгыйлар... Ул киләсе ел сабан туена кадәр әнә шундый мактаулы, дәрәҗәле, ул — ел буе игътибар үзәгендә була...

САБАН ТУЕ ПРОГРАММАСЫ

Сабан туеның программасы бик зур. Монда иң борынгы уеннардан алып иң яңаларына хәтле була. Иң борынгылары шул: Сабан туе кечкенә малайларның көрәшеннән башлана. Егылган берсе мәйданнан чыга бара. Шулай итә-итә мәйданда бервакыт таза егетләр генә кала. Алар Сабан туе батыры дигән исемне алу өчен көрәш башлыйлар. Халык гадел. Еккан кешегә генә түгел, егылганга да бүләкләр бирелә. Көчен сынап караган өчен. Халыкны ихтирам итеп уртага кергән өчен.

Аннан чүлмәк ватыш. Монысына көч кирәкми, әмма сизгерлек кирәк. Йөгереш. Монысында күбрәк яшүсмерләр катнаша. Капчык сугышта елдамлык та, көч тә, хәйлә дә кирәк. Ә менә колга башына менеп андагы әтәчне алып төшү бик сирәк кешедән генә булуы мөмкин. Аякка капчык киеп йөгерү, авызга кашык белән йомырка кабып йөгерү дә бик борынгыдан — игенчелек белән көн күрүче бабаларыбызның көч, егетлек, елдамлык сынашыннан килә. Бау тартыш — хезмәтнең үзеннән килгән уен. Крестьян нинди генә хезмәт башкармасын, элек-электән бау белән эш иткән. Бау — көчлеләрне ярата. Йон эрләүдә, су китерүдә ярышу — хатын-кыз эше. Мондый уеннарга әбиләр дә бик теләп катнаша. Боларның берсенә дә хәрәм кертеп булмый.

Менә бер почмакта гер күтәрәләр. Икешәр потлы герләрне кем ничә мәртәбә күтәрә ала? Шулай итеп, Сабан туе хезмәтнең һәр өлкәсендә иң көчлеләрне, иң булганнарны аерып бирә...

Җыр, бию, уеннар, көч сынашу — татар Сабан туеның бөтен программасы шуннан гыйбарәт. [...]

ӘДӘПЛЕЛӘР БӘЙРӘМЕ

Әйе, Сабан туе — әдәплеләр бәйрәме. Борынгы заманнардан бирле килгән традиция буенча мәйдан уртасына исерек кешене бөтенләй кертмиләр. Көрәшкә керү турында уйлыйсы да юк. Мәйдан уртасына кызмача баштан килеп керү ул — халыкны, тәртип саклаучы аксакалларны ихтирам итмәү

дигән сүз. Халык мондый кешене гафу итми, исерек күренсә, таза егетләр аны тиз генә мәйдан уртасыннан алып чыгып китәләр. Элек-электән шулай килгән. Татарларны теләгән кадәр мыскыл итеп язган реакцион «Казанский телеграф» газетасы да сабан туеның аракысыз гына узуын күрсәтми кала алмаган. Газета болай дип язган: *«Справедливость требует отметить, что несмотря на такое многолюдство, на «Сабан»е редко можно встретить пьяных или вообще хулиганствующих. Порядок образцовый и ревниво оберегается самими гуляющими. И в этом случае татар лишь можно похвалить, что они разумно пользуются своим отдыхом»* (1912 год, № 5727).

Татарның кунак сыена аракы дигән нәрсә бөтенләй кермәгән. Хәтта сабан туена да аракы алынмаган.

Татар фольклорында эчкечеләр, аракы яратучыларга багышланган бик күп җыр, бәет, мәкаль бар. Ул әсәрләрнең барысында да эчкечелек халык алдындагы бик зур начарлык буларак бәяләнә һәм тәнкыйтьләнә. Сабан туеның әнә шундый аеклар бәйрәме булуы өчен аны рус галимнәре бик яратканнар. Казан университеты профессоры К.Фуксның рус газеталарында сабан туе бәйрәменең самимилегенә, андагы тәртипкә сокланып язган мәкаләләре басылган. Бу бер дә очраклы хәл түгел. Чөнки сабан туе гади хезмәт кешесенең дини йолалардан, социаль җәбердән азат булган иң демократик бәйрәме. Ул бәйрәмдә сәламәт рух, крестьянча хөрлек патшалык иткән. Ул — халыкның үзенеке булган. Әнә шуңа күрә ул бәйрәм гасырлар буенча яши һәм әле дә булса Идел буенда яшәүче барлык милләтләрнең дә бәйрәме буларак үткәрелә.

...Әгәр сез татар авылындагы Сабан туена кунак булып килсәгез, игътибар итегез: ул — хезмәт кешесе бәйрәме. Анда сез тәртип бозучыларны күрмәссез. Сабан туе — дуслык бәйрәме, саф күңелләләр бәйрәме. Чөнки саф әхлаклылык — хезмәт кешесенең төп сыйфаты...

КИЛӘСЕ ЕЛГА КАДӘР...

Сабан туе атнасы тәмам. Бәйрәмгә кайткан кунаклар да инде китә башлыйлар. Сабан туе рухы кунаклар белән шәһәргә күчә. Андагы җырлар, биюләр шәһәр сарайларының, театрларының сәхнәләрендә әле озак яшәр...

Колхозчы-крестьян да инде сабан туе мәйданындагы озын колгага түгел, еш-еш кына иген басуына карый. Арыш басуы инде каракучкылланып дулкынлана, арыш серкә очыра. Арыш басуы инде тигезсез сулый, кичләрен иген басуы өстендә аҗаган уйный. Тиздәнтиздән кыр-болын эшләре башлана.

...Картлар тәҗрибәсе буенча инде шушы атнадан соң озак та үтми руларның «Петров день» дигән көннәре җитә, татарлар аны «Питрау көне» дип йөртәләр. Ә татар агаеның ышануынча, «Питрау көне»ннән соң «үлән арасына ут керә», ягъни, үлән инде үсүдән туктый һәм, арасына чалгы кергәнне көтеп, язмышына буйсына...

Авыл җәйге кыр эшләренә әзерләнә. Ә Сабан туе булган мәйданның бер кырыенда әле генә үткән хезмәт бәйрәменең матур истәлеге булып зәңгәр күккә ашкан ак колга җәйге җилдә чайкалып утыра — җиңелчә сызгырып тыныч хезмәткә гимн җырлый. Ул колга шулай җәй буе кояшта ялтырап утырыр, иген басуындагы комбайн штурвалындагы егет тә, иртән фермага баручы кыз да аңа карап күңелле хезмәт бәйрәмен хәтергә алыр, матур хисләр аларны гүзәл хезмәткә рухландырыр.

Җилдә чайкалып утырган ул колгага вакыт-вакыт авылның ак сакаллы карты да күз салыр: ул колга аның типсә тимер өзәрдәй таза вакытын, кызыл башлы сөлгеләрне бөтереп бил алышкан чакларын хәтерләтер...

Әнә шулай кадерле, бик кадерле йола ул Сабан туе дигән халык бәйрәме!

1974, июнь ■

КӨРӘШЧЕ МӘРҖАНИ*

1818 елның 16 гыйнварында Татарстандагы хәзерге Әтнә районы Ябынчы авылында туган, татар дөньясына XIX йөзнең мәшһүр галиме, дин эшлеклесе, фәлсәфәчесе, тарихчысы, мәгърифәтчесе булып кереп калган Шиһабетдин Мәрҗани дә яшьлегендә көрәшне бик яраткан. Бу хакта 1915 елда Казанда чыккан «Мәрҗани» — дигән китапта болай дип язылa: «Мәрҗани яшь вакыттан йөрәкле, батыр булып, кайчакларда куркынычлы, хәвефле эшләргә дә керешә торган булган. Бервакыт ул, унбиш яшьләрдә вакытта, бер кыз туганын һәм энесе Садретдинне гади бер ишеккә утыртып, тирән тегермән суыннан, Ташкичүдән бер чакрым ераклыкта булган Кысна авылына алып барган.

Мәрҗанинең кыюлык һәм батырлыклары өстенә, егет вакытларында бәдән тазалыгы вә каһарманлыгы да булган, йөрәк вә баш тазалыгы белән гәүдә тазалыгын җыйган егет вакытында әтрафында мәшһүр көрәшчеләрнең берсе булган.

Садретдин хәзрәт яза: *«Мәрҗани һәр җәһәттән башкалардан өстен булуны сөя иде. Көрәшне бик ярата иде. Көрәшкә яхшы ук осталыгы да бар иде. Яңа гына балигъ булган заманында, Ташкичү вә күрше авыл Сабантуйларында, камил ир булган таза мужикларны ега иде. Шуңа күрә Ташкичү вә әтрафында батырлык вә көрәшлелек илә исем алган, тирәякның кешеләре Мәрҗанине «Көрәшче Шиһаби» дип таныйлар иде».*

Ташкичү кешеләре дә ошбу «Көрәшче Шиһаби» белән горурланып, күрше авылларда Сабантуйлары, Җыеннар булганда, Баһаветдин хәзрәттән үзләре илә Мәрҗанине дә җибәрүне үтенә, фәкать Ташкичүнең кайбер картлары гына «мужиклар илә көрәшеп яшь көенчә имгәнеп бетә» дип, яратмый сөйли, көрәштән туктатырга киңәш бирә торган булганнар. Ләкин Мәрҗани үзе байтак вакытлар көрәшкә ихлас куеп, Сабан туйларында йөргән, мәшһүр батырлар белән көрәшкән. Бервакыт, унтугыз яшьләрендә вакытта, әтрафларында «Ибрай батыр» дип танылган бер кеше илә көрәшергә туры килеп, янында булганнар көрәшмәскә киңәш бирсәләр дә, Мәрҗани алар сүзенә карамый, аның белән көрәшеп, Ибрай батырны еккан.

Садретдин хәзрәт яза: *«Көрәшкәндә Мәрҗанинең шул гадәте бар иде – егылганнар белән түгел, бәлки егучы баһадирлар белән көрәшүне сөя иде. Үзеннән бер мәртәбә егылган кеше илә көрәшми иде. Һәм дә ул кеше еккан кеше белән дә көрәшми иде».* ■

*Язма Илдус Илдархановның «Без — көрәшче халык» исемле китабыннан алынды.

Хәмит Латыйф рәсеме

Мөдәррис Әгъләм
(1946-2006)

Сөлгеләр тотыла, һәр авыл
Батырын күзәтә, билгеле…
Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:
— Бирмә билеңне!
— Бирмә-ә-ә!

Дошманнар таптаса җиреңне,
Сорамый: «Син батыр идеңме?»
Мәйдан күк кысыла бар халык:
— Бирмә билеңне!
— Бирмә!

ДӨНЬЯ ИҢЛИ САБАНТУЙЛАР

Атлас Гафиятов

Халкыбызның милли бәйрәме – Сабантуйлары килеп җитте. Республикабыз авылларында, шәһәрләрендә алар, гадәттә, июнь аенда үтә.

Сабан туе, кайберәүләр уйлаганча, елга бер килүче бәйрәм генә түгел. Әгәр төптәнрәк уйлап карасак, ул дин, тел һәм моң белән бергә халкыбызны бөтенләй бетүдән саклап калган тарихи бер чара да.

Ел саен ул безнең һәркайсыбызны, бигрәк тә авылдан чыкканнарны, Хәтер Мәйданына җыя. Элек-электән шулай булган: читтә, туган җирләреннән еракта яшәүче милләттәшләребез (ә татар яшәмәгән урын Җир шарында юктыр да!) үзләренең елга бер килә торган ялларын нәкъ шушы вакытка туры китереп, туган якларына кайткан. Биредә күпләр яшьлек дуслары, классташлары, беренче мәхәббәтләре белән күрешә, әлеге очрашудан тагын бер елга җитәрлек истәлек, рухи дәрт, күңел күтәренкелеге алып китә...

Сабан туеның кайчан килеп чыгуы хакында бернинди дә төгәл мәгълүмат юк. Мин үзем, шәхсән, аны грекларның безнең эрага кадәр барлыкка килгән Олимпия уеннары белән бергә яки аннан да алдарак барлыкка килгәндер дип фаразлаучылар төркеменә карыйм. Моңа нәкъ менә Сабан туе программасына кергән көч сынашуларның байтагының Олимпия программасы белән тәңгәл килүе, ә безнең бәйрәмдәге көч сынашуларның Олимпия уеннарындагыдан да баерак булуы җирлек бирә дә.

Сабан туеның төп бизәге саналган ат чабышы һәм көрәш элеккеге заманнарда ук булган һәм бүген дә бар. Тик менә соңгы вакытта ир-атның гомер юлдашы саналган атка игътибар кимү генә аның Сабан туе программасыннан бөтенләй төшеп калу ихтималын арттыра. Көрәш дигән спорт төре белән шөгыльләнү ир-егетләрдә

иң беренче чиратта көч-куәт барлыкка китерү чыганагы булып тора. «Батыр ярасыз булмый» дигәндәй, көрәшкәндә җәрәхәт алу мөмкинлеге дә бик зур. Яуга чыгар алдыннан җәрәхәтләнүне булдырмас өчен, көрәшчеләр башта ук бер-берсеннән: «Алыштанмы, салыштанмы?» — дип сораган. «Алыштанмы?» — дию көндәшнең аякларын җирдән аерып, күтәреп кире куюны аңлаткан. Ягъни бу очракта көрәш шунда ук туктатыла һәм көндәшен күтәрүче җиңүче санала. «Салыштанмы?» — дигәнендә инде көндәшне күтәреп алып үзең аркылы чөеп җиргә егу сорала. Бу очракта һөҗүм итүченең дә, саклаучының да җәрәхәт алу мөмкинлеге бермә-бер арта. Шуңа күрә зур яу алдыннан көрәш бәйгесендә нигездә беренче вариант кулланылган.

Күпләр, бигрәк тә башка милләт вәкилләре өчен җиргә кагылган ике нәни колгага утыртылган вертикаль бүрәнә өстендә капчык белән сугышу бик тә сәер тоела. Югыйсә, бу аттракцион да сугышчы әзерләүнең бер күнегүе саналган. Чөнки Сабан туе барлыкка килгән чорда бабаларыбыз ат өстендә йөргән, ә кулларында кылыч, сөңге, чукмар булган. Ат өстендә утыру күнекмәләрен яхшырту, кул (беләзек) көчен арттыру өчен бүрәнә өстендә капчык белән сугышып күнегүдән дә әйбәтрәк уен була алмыйдыр, мөгаен. Колга башына үрмәләү дә җитезлекне арттыруның бер төре. Борынгы бабаларыбыз иксез-чиксез дала уртасында кай яктан дошман явы килгәнен җиргә тиз генә 15-20 метрлы колга (багана) утыртып, шуңа иң җитез, җиңел гәүдәле берәүне меңгереп җибәреп белгәннәрдер?!

Сабан туе программасында капчык киеп яисә ике аякны бәйләп йөгерү төре дә бар. Бу төр дә юктан гына барлыкка килмәгән. Дошманнар, качып китмәсеннәр дип, әсирлеккә эләгүчеләрнең аякларын бәйли торган булганнар. Ә инде капчык киеп йөгерү күнекмәләрен ныклап үзләштерүчеләр аяклары бәйләнмәгәннәр дәрәҗәсендә йөгергәннәр. Бу да чын сугышчы әзерләүнең бер ысулы булган.

Сабан туенда кулга озын таяк (колгачык) тотып күзләр бәйләнгән килеш чүлмәк ватуның да нечкәлекләре бар. Гомерендә бер тапкыр да чүлмәк ватып карамаучылар күзләре бәйләнгән килеш түгел, гадәти хәлдә дә таякларын чүлмәккә тидерә алмаска мөмкин. Хәтерләсәгез, бер елны Русия президенты Борис Ельцин Арча Сабан туенда күзләре бәйләнгән килеш озын таяк белән бәреп чүлмәкне челпәрәмә китерде. Аның күзләрен бәйләгән кара бәйләвеч аркылы күреп булгандыр, дип тә фаразлаучылар булды. Гөнаһына керә алмыйм, андыйларга күзләрен бәйләмичә генә чүлмәк ватып карарга киңәш итәм. Ә инде бу аттракционның төп асылына килсәк, ул да төнлә дошман белән сугышуга әзерлекнең бер ысулы булган дип фаразлау кыен түгел.

Бер башы җиргә беркетелгән авыш колга аша чыгу, тауга каршы йөгерү, таш күтәрү кебек төрләр белән шөгыльләнү дә сугышчыларның көчен, җитезлеген арттыргандыр. Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Сабан туебыз программасына кергән төрләр белән шөгыльләнү чын сугышчы әзерләүнең нигезе булып торган.

Бүген Сабан туебыз программасына кергән кайбер төрләр бөтенләй онытыла бара, аларны яңалары алыштыра. Әйтик, кайбер урыннарда ат чабышы урынына машина яки мотоцикл узыштыралар. Моны мин уңай күренеш димәс идем. Чөнки күп кенә авылларда ат бетү ул атка атланып сөлге-яулык җыю, урам әйләнү, тол хатыннарның бәйгедә иң соңгы килгән атка бүләк бирүе кебек меңәр еллык гореф-гадәтләрнең бетүенә барып тоташа. Ничә гасырлар буе формалашкан, байтак буыннарны тәрбияләгән гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы исә киләчәк буыннарда әхлаксызлык, гаделсезлек, намуссызлык кебек сыйфатларның барлыкка килүенә этәргеч ясый. Сабан туе мәйданы исә халкыбызның күңелен чагылдырган көзге кебек – анда начар сыйфатларга урын булырга тиеш түгел. ■

ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ *

Йосыф Акчура

ӘХМӘТ ҖӘҮДӘТ ПАША

Иң күренекле вәкилләре — Сөләйман паша, шәех Сөләйман әфәнде һәм Әхмәт Мидхәт әфәндедән торган төрекчелек хәрәкәтенең бу икенче дәверендә Әхмәт Җәүдәт пашаның язганнары тел һәм сәясәт турында. Аның төрекчелек һәм бөтен төркичелек (төркиләр бердәмлеге) карашына катнашы барлыгын күрмәү — кимчелек булыр иде. XIX гасырның соңгы чирегендә хокук, тарих, тел белеме өлкәләрендә мәшһүр, үткен фикерләр әйткән бу галим пашаны, әлбәттә, тулысынча төрек милләтчелеге яклы, дип әйтеп булмый.

Шул ук вакытта төрекчелек фикере белән бәйләнеше юк яки аның дошманы булган, дип уйлау да хата булыр иде. Җәүдәт паша ислам фикъһын берникадәр төркиләштергән кеше түгелме?! «Кыйссасел әнбия»се белән төрекчелек хәрәкәте теленә гамәли хезмәт күрсәтүче түгелме? «Тарих-и Җәүдәт»ендә төп фикере белән Әхмәт Мидхәт әфәнде кебек «госманлы милләте» позициясендә булган хәлдә, төрек милләтчелегенә, төрек кавеменә, үз сүзләре белән әйткәндә, «җенсиятенә» игътибар каратмыймы? [1] Бу әсәре Госманлы тарихының кайбер вакыйгаларын, беренчеләрдән булып, алгы планга чыгаруы, сәяси вакыйгаларга караганда җенесияткә игътибар каратуы белән әһәмиятле. Мәсәлән, Русиянең Кырымны басып алуы уңае белән, Сөләйман Кануни заманыннан башлап Госманлы дәүләтенең «Немчә» (Австрия) походлары белән мәш килүен тәнкыйть итә: «Маҗарстан, Хорватстан җиңүләре, басып алулары белән мавыкмыйча, Казан һәм Әстерхан ханлыкларын басып алыну хәвефеннән саклау Госманлы дәүләте өчен тагын да файдалырак, нәтиҗәлерәк булыр иде. Чөнки Кавказ, Әстерхан һәм Казан халкы басып алынган хәлләрендә дә якынлык, кавем, дин һәм мәсләк берлеген саклыйлар, госманлыга сыеналар». Ул чактагы Кырым да, Госманлы дәүләтенең башка вилаятьләре кебек, империягә керде. Госманлылар Казан һәм Әстерхан ярдәмендә ул төбәкләрдә игътибар казанган булыр иде.

ГОСМАНЛЫ МИЛЛӘТЧЕЛЕГЕ. ИСЛАМ БЕРЛЕГЕ ҺӘМ ТӨРЕКЧЕЛЕК

Әлегә кадәр, Көнбатыш (Госманлы) төрекләре арасында 1865-1870 һәм 1876-1880 елларда, азмы-күпме билгеле булган фактларга нигезләнеп, төрек милләтчелеге башлангычлары мәйданга килә башлавына игътибар юнәлттек. Бу вакыйгалар өйрәнелә башлаган еллардан соңгы дәверләрдә, әлеге мәсьәлә ни өчен җентекләбрәк эшләнә башлавының сәбәпләрен дә ачыкларга тырыштык. Госманлы төрекләренә төрек милләтчелеге

* Дәвамы. 2014 елның 1 нче санында басылып килә.

кай яклардан һәм нинди юллар белән килгәнлеге турында кайбер фаразларыбызны белдердек.

Госманлы империясе чикләренең аргы ягында яшәүче күпчелек төркиләрнең милләт рәвешендә формалашулары һәм аларның камиллеккә ирешүенең нинди икътисади, иҗтимагый, сәяси шартлар өстенлек итү нәтиҗәсе булуын нечкәләп тикшерүгә әлегәчә керешә алмадык. Бу мәсьәләне тиешле рәвештә хәл итәр өчен җитәрлек чыганакларның, материалларның кулда булмавын да әйтми булмый. Госманлы империясенең XVIII гасыр азагы — XIX йөз башындагы икътисади һәм иҗтимагый хәле җентекләп өйрәнелмәгән. Ул чактагы вазгыятьне барлаган һәм нечкәләп тикшергән хезмәтләр дә юк. Дәүләтнең эчке сәясәте һәм идарә проблемаларының аспектлары турында кайбер мәгълүматлар чит ил галимнәре язмаларында гына очраштырылгалый. Чит ил материалларында сәясәт һәм тышкы мөнәсәбәткә кагылышлы фикерләрне генә табып була. Шуңа күрә, иҗтимагый һәм икътисади хәлләргә кагылмастан, сәяси һәм дипломатик мөнәсәбәтләрне күзаллау белән генә чикләнәбез.

Греклар, серблар һәм богдан-валахларының (румыннарның) мөстәкыйльлек казанып, Госманлы дәүләтеннән аерылуларына, Госманлы дәүләтендәге христиан халыкларының, грекларның мөселманнарга, төрекләргә дошманлыкларына, христиан гарәпләрнең, болгарларының, хәтта әрмәннәрнең милли мөстәкыйльлек хәрәкәтләренә, христиан динендәге Госманлы империясе халыкларының милли мөстәкыйльлек алуы файдасына, озак заманнар дәвамында, бөтен Европа христиан дәүләтләре ачыктан-ачык катнаштылар. XIX гасыр урталарына барлык шундый хәлләр, мөселман һәм төрек госманлыларга, моннан ары христианнар белән бер дәүләт булып яшәү кыенлашканын бик ачык күрсәтте. Бу сәяси һәм дипломатик вазгыять шартларында мөселман госманлылар дини бердәмлекнең әһәмиятен тагын да сизә һәм аңлый башласалар да, сәяси вакыйгаларга бераз тирәнрәк күз салып, бу бердәмлекнең югары дәрәҗәдә (берлек) түгеллеген аңладылар. Империядә төрекләр хакимияте хәвефсезлеге, солтан сарае даирәсе карашына да якынлыгы төрек милләтчелеге көченә һәм өстенлегенә, әлбәттә, тәэсирсез калмый. Шуның белән бергә «төрекчелек көчәюе» империя чикләренең тартылу-тараюына файдаланырлык хезмәт иттерерлек сәяси чара булмаган. «Төрекчелек көчәюе»нә тулысынча ышанып, аңа таяну мөмкин булмагангамы, Европа илләренең кайберләренең (аеруча Француз империясе) яхшылык теләү булып күренгән тәкъдимнәренә аеруча ышаныч күрсәтелгәнгәме, ни өчендер, ислам динендә булмаганнарны төрекләр белән тиң рәвештә ил белән идарә итү эшләренә тартып, Госманлы дәүләтен бергәлектә кризистан чыгару, реформалар фикеренә өстенлек бирелде. Төрек элементының икътисади һәм иҗтимагыять өлкәләрендә тиешле дәрәҗәдә җитлекмәгән булуы, христиан динендәге халыкларның мөстәкыйльлек, бәйсезлек әмәлләре белән артык шыплап тутырылганлыгы көтелгән нәтиҗәләргә ирешүне тоткарладылар. Шуңа күрә госманлы милләтчелеге төрекләрне төрек булмаган мөселман халыклар белән якынлаштырып, ислам берлеге идеяләренә дә әһәмият бирә. Кыскасы, бу ике дәвердә сәяси төрекчелек госманлы милләтчелеге һәм ислам берлеге белән укмашкан хәлдә яши.

ШӘЕХ ҖӘМАЛЕТДИН ӘФГАНИ

Көнбатыш (госманлы) төрекләре арасында мәйданга чыккан төрек милләтчелегенең сәяси идеясе Госманлы империясенең бөтенлегенә һәм яшәеш дәвамлылыгын саклауга хезмәт итте. Бу идея Мостафа Җәлалетдин паша һәм Сөләйман паша әсәрләрендә аеруча ачык күренде. Башлыча XVIII гасырдан, госманлы төрекләре таушалган солтанлыкларын бөтенләй егылудан саклар өчен, тәнзимат белән госманлы милләтчелеге кебек идеяләрне файдаландылар. Бу тәҗрибәләрнең нәтиҗәсезлеген күргән кайбер госманлы фикер ияләре, йә ислам дине, яисә төрекчелек идеа-

лы белән милләтчелеккә таянып максатка ирешү мөмкин булачын аңладылар. Госманлы җирлегендә милләтчелек сәяси ноктадан шундый чыганакларга кушылып, Үзәк Азиядән чыгып бөтен ислам галәменә фикри тәэсир күрсәткән бер затның фикере рәвешенә кереп, бер кеше кулы аша гомуми теләккә әйләнеп тагын да киңрәк тарала. Бу зат — шәех Җәмалетдин әфәнде Әфгани. Ошбу мәшһүр шәех — бөтен ислам галәме яшәеше өчен мөселман милләтләре милли аңга ия булырга тиешлеге фикерен алга сөргән кеше. Ислам галәменең һәр тарафына Җ.Әфгани бәрәкәтле фикерләре, сүзләре, шигырьләре белән тәэсирле караш орлыклары чәчкән, көнбатыш төрекләре арасындагы кебек, төньяк төркиләре арасында да милләтчелек фикере җәелүенә хезмәт күрсәткән. Ирандамы, Әфганстандамы 1836 елда туган һәм 1897 елда Истанбулда вафат булган шәех Җәмалетдиннең биографиясе легендалар белән тулы. Нәселе кайсы мөселман кавеменнән? Катгый белмибез. Бер әсәренең гарәпчәгә тәрҗемәсендә кереш итеп китерелгән биографиясендә [2] гарәпләрдән булуы, хәтта пәйгамбәр токымы — Хөсәен бине Гали бине Әбу Талиб нәселеннән дип күрсәтелә. Үзләрен пәйгамбәр нәселеннән дип күрсәтүләр мөселман дөньясында шулкадәр киң таралган ки, мондый раслаулар кешедә, шунда ук шик-шөбһәхисләрен тудыра. Шәех Җәмалетдиннең Истанбулда яшәгән вакытта иптәшләренә нәсәбен һәрчак төркиләрдән дип сөйләве, бу шик-шөбһәләрне тагын да көчәйтә. Туган җире турындагы фикерләре дә шундый ук каршылыклы. «Әфгани» нисбәсенә карап, Кабул тирәсендә туган, дип уйлыйсың. Кабул тирәсеннән дисәң, бу этник асылны ачыклауга бер нәрсә дә өстәми, әфган, фарсы, төрек яки гарәп нәселеннән булуын раслый да, кире кага да алмый. Шунысы бәхәссез: Җәмалетдин Әфгани әфганча да, фарсыча да, төрекчә дә, гарәпчә дә иркен сөйләшә, әсәрләренең күбесен фарсы яки гарәп телендә яза. Ислам галәменең төрле төбәкләрен гизә, дәрес бирә, вәгазь сөйли, китап рәвешендә әсәрләрен тарата. Көнчыгыш белән бәйләнешле күренекле Европа дәүләтләре башкалаларында фикерләрен кабул иттерер өчен кайбер сәяси комбинацияләр эшләргә тырышкан бу илгизәр хакимне (философны) фәлән, йә фәлән кавемнән диюгә, минемчә, һичнинди ихтыяҗ юк. Көнбатышта «бөек Европа» дигәннәре кебек, без аны «бөек бер мөселман», яисә «бөек ориенталист» дип атарбыз. Бу бөек көнчыгышлының яшәеш максаты Көнчыгыш мөселманнарының төшенкелеккә китүе, артка калуы сәбәпләрен эзләүгә, бу төшенкелектән чыгу чараларын табуга, аны гамәлгә кертүгә юнәлтелгән. Шуны эзләү процессында ул бер мөселманның да нәселкавеменә әһәмият бирми, торгынлык һәм артка калу сәбәпләре белән генә кызыксына. Фарсы булсын, һинди булсын, төрек булсын, теләсә кем булса булсын, барлык ислам кавемнәренә, милләтләренә, үз сүзе белән әйткәндә, «җенесләренә» әһәмият бирмәскә киңәш итә. Шәех Җәмалетдин Әфгани ислам галәменең яши алуын, алга китүен, мөселман кавемнәренең аңлы милләтче булуларында, миллиятләрен (женсиятләрен) эчтән торып алга җибәрүләрендә күрә. Шәехнең бу фикерен бәян иткән ике әсәре — Һиндстанда фарсы телендә басылган «Мәкаләт-е Җәмалия» исемле мәкаләләр җыентыгында бар. Аларның берсе — «Вәхдәт-и җенсия фәлсәфәсе» дигән мәкаләсе. Икенчесе — төрек шагыйре Мәхмәт Әмин бәйгә нәсихәтләре.

Шәехнең «Вәхдәт-и җенесия фәлсәфәсе» («Милләт бердәмлеге фәл-

[1] Җ. Әфганинең бер әсәре М.Һади тарафыннан татарчага тәрҗемә ителеп, Казанда да басылып чыга: «Тәтиммәтел бәян фи тарих Әфган» 1902 ел, 49 бит (үз акчасына бастыра).

сәфәсе») фарсычадан төрекчәгә тәрҗемә ителеп, «Төрек йорты» журналында басылган [3][1]. Тәрҗемәчесе — Мәхмәт Әмин. Фарсыча оригиналының башында гарәп телендә цитата бар. Тәрҗемәдә дә ул шулай, гарәп телендә калдырылган. Мәкаләнең төп фикере (идеясе): Җенсияттән (миллияттән) тыш сәгадәт (бәхет) юк. Телсез җенсият булмый. Ул халыкта (җенестә) барлык катлаулар һәм сыйныфлар кулланмаган, файдаланмаган, алар ихтыяҗын тәэмин итмәгән сүз юк. Шәех фикеренә караганда, кешеләр яшәешендә аерым шәхесләрне бер-берсе белән берләштерә-бәйли торган ике көч бар. Берсе — тел берлеге, икенче төрле әйткәндә, җенес берлеге; икенчесе — дин. Тел берлегенең (миллиятнең) дөньяда яшәеш еллары (гомере) тотрыклылыгы, дингә караганда дәвамлырак. Тел кыска вакыт эчендә үзгәрми. Бер үк телдә сөйләгән халык төркеме үз телен мең еллар дәвам иттерә. Икенче бәйләнеш — дин. Аның гасырлар дәвамында ике-өч мәртәбә алышынуы, үзгәрүе мөмкин. Бу фикер сөрешеннән, шәех Җәмалетдиннең дин берлегенә караганда җенес (милләт) берлегенә, «бөтен төрек» (төрки халыклар) бердәмлегенә артыграк әһәмият бирүен аңлап була. Игътибарга лаек икенче бер үзенчәлек — шәех Җәмалетдин Әфгани җенсиятне, немец философлары кебек, тел берлеге дип билгели. Бу яктан, телгә, телнең байлыгына, сафлыгына, яңа терминнарның төгәл мәгънәлелегенә һәм шул ук вакытта милләтнең теле төрле катламнарының барсы өчен дә аңлаешлы булуына җитди әһәмият бирә. *«Билгеле бер халыкның төрле катламнарының аңлашулары һәм куллану чаралары булган тел — халыкның бердәмлеген саклый. Аңлашу, куллану чарасы йөкләмәсен үти алмаган тел — халыкның бердәмлеген саклый алмый. Халык язмышы турында уйлаучы галимнәрнең беренче бурычы — үз телләрен киңәйтүне кайгырту. Тел мәсьәләсен кайгыртучы ана телен үстерергә, үз телләре сүзләре генә җитмәсә, үз телләре белән бәйләнешле башка телләрдән ихтыяҗ зарурлык сораган сүзләрне табып алырга, башка чара булмаса, чит телләрдән кирәк булган сүзләрне алу юлына басарга киңәш итә. Фәкать ул сүзләрне үз телләре киеменә урау шарттыр. Шулкадәр үз теленең киемнәренә сарырга ки, чит тел сүзе икәне сизелмәслек булсын».* Күренә ки, төрекчелек хәрәкәтенең соңгы этабында, төрек теле ислахы мәсьәләсе кузгалганда язылган фикерләренең күбесендә проблема тирән сиземләнгән, эчтәлек тирән, тыгыз фикерле. Ниһаять, шәех Җәмалетдин: «Дөньяда бәхет дип кабул ителүче барлык нәрсәләргә ирешү» — «вәхдәт-и җенсия»нең («милли бердәмлек»нең) яңа миллият үсү һәм камилләшү аша булуы белән килешә.

Тикшерелгән бу мөһим мәкаләнең беренче бүлеге шундый гомуми эчтәлекле кыйммәтле күзәтүләрдән тора. Икенче бүлек тулысынча һиндларга адресланган. Аерым һәм гомуми күренештән соң, тәнкыйтькә һәм махсус нәсихәтләргә керешә. Һиндлыларга нәсыйхәтләре арасында, аерым басым ясап, «ватан теле» дип атаган урду телен үстерү һәм ныгыту-камилләштерү беренче зарур бурыч дип күрсәтә. Гадәттән тыш, сиземлелек белән, соңгы сүзләрендә пәйгамбәрлек күрсәтеп: *«Кайбер тар карашлыларны бу язмам гаҗәпләндереп борчуга саласын беләм. Әмма үткен күзлеләр бу сүзләрнең никадәр дөрес икәнен расларлар»*, — дип яза.

Шагыйрь Мөхмәт Әмин бәйгә сөйләгән сүзләрендә дә югарыда язган төп фикерләр чагылыш таба. Милли шагыйребез яшь чагында шәех Җәмалетдин әфәнденең өенә нәсыйхәтләрен тыңларга йөргән. Шәех яшь шагыйрьгә без тикшергән мәкаләсе рухында байтак нәсыйхәтләр һәм киңәшләр биргән. Ул нәсыйхәт һәм киңәшләр эчтәлегенә милли шагыйрьләребезгә багышланган башка язмабызда җентеклерәк тукталырбыз.

Искәрмәләр

1. Әхмәт Җәүдәт пашаның 1885 елда Истанбулда басылган «Тәртип-и җәдит-и тарих-и» китабы күз алдында тотыла.
2. Төрек йорты. — 6 җилд. — Б.2263-2267.
3. Төрек йорты. — 3 җилд. — Б.45. ■

Төрек теленнән
***Мәсгуд Гайнетдин** тәрҗемәсе* ■

ИСКЕ РӘҖӘП АВЫЛЫ ЗИРАТЫНЫҢ КАБЕР ТАШЛАРЫ

Җәмил Мөхәммәтшин

Спас районының Иске Рәҗәп авылы – Кама аръягында урнашкан иң борынгы татар авылларыннан берсе. Аның тирәсендә Болгар һәм Алтын Урда чорына караган берничә авыл урыны һәм шәһәрлек бар. Авыл эчендә борынгы авыл урыны һәм зират урнашкан. Ул җирле халык арасында Ташбилге исеме белән билгеле.

Зираттагы кабер ташлары Гайнетдин Әхмәрев, Равил Фәхретдинов, Һарун Йосыпов, Фәрит Хәкимҗанов тарафыннан тикшерелгән. Бу юлларның авторы да ул ташларны берничә мәртәбә зиярат кылды. Иске Рәҗәп кабер ташлары, стиле буенча Болгар шәһәре ташларыннан аерылмаса да, язуы, теле буенча үзенчәлекле. Шунысы кызыклы, зираттагы бер ташта Рәҗәп исеме укыла. Җирле халык авылның килеп чыгышын да Рәҗәп бабай исеме белән бәйли.

Тарихи чыганакларда Рәҗәп авылы исеме Бәрән дип атала [Насыров, приложение 9, 12]. Танылган эпиграфист һәм этнограф Һарун Йосыпов «Бәрән» атамасын Әхмәт ибне Фадлан искә алган бәрәнҗар кабиләләре белән бәйли. Ул Иске Рәҗәп авылында «беренче төбәк» топонимы булуын[2] һәм аның борынгы болгар кабиләләренең беренче килеп урнашкан урыны булырга мөмкинлеген искәртеп үтә [Юсупов, 1971. – С.228].

Алтын Урда таркалгач, Казан ханлыгы чорында, авылның яшәү-яшәмәве турында тарихи документлар сакланмаган. Бу бөтен татар авыллары өчен хас күренеш. Татар авылларының XV-XVI йөз тарихын ачыклауга археология материаллары да ярдәм итә алыр иде. Әмма ул чорның керамикасы һәм көнкүреш әйберләре русларныкыннан аерылмый диярлек. Ә инде XVII йөзгә нисбәтле тарихи документлар бар. 1675 елда Иске Рәҗәптә мәчет булуы билгеле. XVIII йөз башында беренче мәчет имамы Кадыйрмөхәммәт Сүнчәләй Болгарда Пётр Іне каршы ала һәм аны шәһәрлектәге тарихи һәйкәлләр белән таныштыра, Йосыф Ижбулат белән бергә шундагы мөселман кабер ташларын тәрҗемә итә.

Пётр I чорына караган тагын бер документка игътибар итми мөмкин түгел. Иске Рәҗәп авылы имамы Зәйнелгабидин Габделкәрим углы тәрҗемәи хәленә теркәлгән 1696 елгы документта авылның умартачылык чикләре, иген, печән басулары турында сүз бара [Мәрҗани. – Б.8]. Сәет Вахиди Шиһабетдин Мәрҗанинең Иске

[1] Иске Бәрән авылы исеме 1991 елда Иске Рәҗәп дип үзгәртелә.

Рәҗәп авылында булып кулъязма китаплар, тарихи материаллар җыюы, кабер ташларының язуларын тәрҗемә итүе турында яза [Вахиди. — Б.102].

Рәфикъ Насыйров Иске Рәҗәпне Казан ханлыгы авыллары исемлегенә кертми. Әмма авылның Иделдән 70 чакрым читтә урнашкан булуын искә алсак, аңа Иван Грозный указлары кагылмаган һәм XVII-XVIII йөзләрдә шөһрәт казанган Пәрәү, Рәҗәп авыллары болгар чорыннан башлап, хәзерге көнгәчә тоташ яшәгәннәр, дип уйларга була. XVIII-XIX йөзләрдә Иске Рәҗәп — берничә мәчете, мәдрәсәсе булган иң зур авыллардан берсе.

Октябрь революциясенә кадәр Иске Рәҗәп Нәкышбәндия тарикате тарафдарлары белән бәйләнгән суфичылык үзәкләреннән санала. Нәкышбәндия тарикате силсиләсе авыл имамы Әсгать әфәнде Нугаевта саклана. Силсиләдә 396 исем бар. Шәҗәрәнең башы, Мөхәммәт пәйгамбәр һәм беренче хәлифәләрнең исемнәре булган өлеше ертып алынган. Әсгать хәзрәтнең әйтүенә караганда, шәҗәрәнең соңгы өлеше 1960 елларда совет хөкүмәтенең дин белән көрәшүенең көчәюе чорында юкка чыгарылган[2]. Анда аның әтисе (Иске Кандал авылыннан) һәм әнисе (Кизләү авылыннан) ягыннан туганнарының исемнәре дә булган. Силсиләнең танылган Кизләү мәдрәсәсендә күчерелгән булуы мөмкин. Риваятьләргә караганда, силсилә Әсгать хәзрәтнең әнисенең бабасы Габделваһаб хәзрәтнеке була[3]. Әсгать хәзрәтнең әйтүенчә, шәҗәрәнең соңгы өлеше авыл зиратындагы кабер ташы язуы белән туры килгән. Шуларны ачыклау максатыннан, без, Иске Рәҗәп зиратында булып, ташъязмаларны тикшереп чыктык. Чынлап та, зиратта сакланып калган җиде таш, бер агач һәйкәлнең барысы да беренче һәйкәлдә искә алынган мулла Лотфулла

№ 1. Лотфулла Габделваһаб улына куелган таш. 1910 ел

Габделваһаб улы һәм аның туганы Габделгафур хәзрәт исеме белән бәйләнгән. Димәк, болар барысы да бер гаилә әһелләре һәм Иске Рәҗәп тарихында тирән эз калдырган, силсиләдә урын алган нәселдән була. Бүген сезгә шул һәйкәлләрнең сурәтен һәм язуларының укылышын тәкъдим итәбез.

ИСКЕ РӘҖӘП АВЫЛЫ ЗИРАТЫ

№ 1. Лотфулла Габделваһаб улына куелган таш. 1910 ел.

Үлчәмнәре: 12х24х80см. Алгы ягында:

1. Лилләһил Алла
2. мулла Лотфулла
3. ибне Габделваһаб
4. ибне Имамкол ибне Мансур
5. ибне Нурҗәлил
6. 64 йәшендә
7. сәнәи 1910 октябрь
8. 14ендә мәдфүн

[2] Куркуның нигезе дә бар, чөнки аның әтисе Нугаев Хөсәен Әхмәт улы 1937 елны кулга алына һәм 1938 елны атып үтерелә.

[3] Габделваһаб Имамкол улы 1794 елдан башлап, Иске Рәҗәп авылының беренче мәхәллә мәчете имамы.

№ 2. Әхмәтрәшит Әхмәтгата улына куелган таш. 1920 ел

9. рәхмәт Аллаһы Тәгалә

Уң ягында: гафәрә Аллаһы зөнубәһу

Сул ягында: нәүвәрә Аллаһы мәркадәһу

Арткы ягында:

1. Галәмәдин морадым бер догадыр
2. кыйбла тарафында бер кабер аркылы
3. Фатыйма
4. мулла Лотфулла
5. кызы 21 йәшендә
6. 1928 сәнәи март
7. 20 ндә вафат
8. Алла рәхмәт
9. кыйлсын.

Искәрмә. Таш тимер чардуган эчендә таштан эшләнгән нигезгә куелган. Язуы: Нугаева Рәшидәнең атасы Лотфулла мулла.

№ 2. Әхмәтрәшит Әхмәтгата улына куелган таш. 1920 ел.

Үлчәмнәре: 9х29х100. Ракушечник. Ян якларында һәм арткы ягында язу юк.

1. Әлмәүте гыйбрәт
2. бу кабердә мәдфүн
3. Әхмәтрәшит
4. мулла Әхмәтгата
5. хәзрәт углы
6. 24 йәшендә
7. 1920 нче елда март
8. 17-ндә рәҗәб
9. 13-ндә урыны
10. җәннәттә булсын.

№ 3. Хайрелниса Җәләлетдин кызына куелган таш. 1904 ел.

Үлчәмнәре: 18х32х110. Ракушечник. Ян якларында һәм арткы ягында язу юк.

1. Лилләһир — мөҗакәр
2. Хайрелниса остазбикә
3. Габделгафур мулла җәүзәсе Җәләлетдин мулла
4. кызы 82 йәшендә ахирәткә күчте
5. кабре … әл-җәннәт улсын
6. 1904 миладия ноябрьнең … сендә.

№ 3. Хайрелниса Җәләлетдин кызына куелган таш. 1904 ел

№ 4. Габделвавһаб хәзрәткә куелган таш. 188? ел

№ 6. Габделгафур ишанга куелган таш. 1913 ел

№ 4. *Габделваһаб хәзрәткә куелган таш.*

Үлчәмнәре: 20х41х120. Известняк таш.

1.

2.

3. … әт-тарих

4.

5. әл-газам бәгъзе салавател — җәмәгать

6.

Уң ягында: … рухын шат кыйлсын .

Сул ягында: …улса 1304 тарих миладия 188? йылда февраль 24ндә тәваффа

Искәрмә. Таш тимер чардуган эчендә. Язуы: Нугаева Рәшидәнең бабасы Габделваһаб хәзрәт.

№ 5. Таш ватыклары

Искәрмә. Таш ватыклары тимер чардуган эчендә. Язуы: Нугаева Рәшидәнең Мансур бабасының әтисе Нурҗәлил баба.

№ 6. Габделгафур ишанга куелган таш. 1913 ел.

Үлчәмнәре: 20х40х120. Ак известняк.

1. Лә иләһә иллә Аллаһы Мөхәммәд рәсүлуллаһ

2. Тарих һиҗрия илән мең дә ике

3. йөз бишенче йылда рәбигуләүвәл 30

4. ндә Иске Рәҗәб карьясында имам

5. вә мөдәррис Әлмәт карьясында Хәйрулла

6. ишан хәзрәт Х…. мулла

7. … хәзрәт Габделгафур хәзрәт

Уң ягындагы язу:?

Искәрмә. Таш тимер чардуган эчендә. Язуы: Габделгафур ишан хәзрәт.

№ 7. Гайнелҗамал Габделгафур кызына куелган таш. 1913 ел.

Үлчәмнәре: 17х30х100см. Ракушечник.

№ 7. Гайнелҗамал Габделгафур кызына куелган таш. 1913 ел

№ 8. Хәйрелбәрия Лотфулла кызына куелган һәйкәл. 1959 ел

1. Әл кабре гыйбрәт
2. Гайнелҗамал мулла Габделгафур кызы
3. мулла Җәләлетдин җәүзәсе
4. 66 йәшендә вафат
5. бу кабергә керде миладия
6. 1913 сәнә.

№ 8. Хәйрелбәрия Лотфулла кызына куелган һәйкәл. 1959 ел.

Үлчәмнәре: 8х40х115см. Агач.

1. Агузе билләһи минәш-шайтанир—раҗим бисмилләһир-рахманир-рахим
2. иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун
3. лә иләһә иллә Аллаһы Мөхәммәд рәсүл
4. уллаһ вафат булды
5. Хәйрелбәрия Лотфулла
6. баба кызы 76 йәшендә
7. 1959 елда декабрь
8. Зендә
9. Бәрия

Искәрмә. Тугызынчы юл кириллицада язылган.

Чыганаклар

1. Әхмәров Г. Болгар тарихы. – Казан: 1908.
2. Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар. II том.
3.Мәрҗани китапханәсе: фәнни-библиографик җыентык // Төз. Р.Ф.Мәрданов – Казан: Милли китап, 2004. – 122 б.
4. Мөхәммәтшин Җ. Бер шәҗәрәнең сере // Яңа тормыш. – 2007 ел. – 30 май.
5. Насыров Р.Г. Сельское расселение в Западном Закамье (вторая половина XVI-начало XVIII вв.). – Казань: Институт истории АН РТ, 2007.
6. Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. – Казань: Татарское книжное издательство, 1975.
7. Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. – Москва: «Наука», 1987.
8. Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. – Москва. Издательство «Наука», 1978.
9. Юсупов Г.В. Булгаро-татарская эпиграфика и топонимика, как источник исследования этногенеза казанских татар // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Археология и этнография Татарии. Выпуск I. – Казань, 1971. ■

«НОКРАТКА БАРДЫК БЕЗ…»

Айдар Гайнетдинов

Безгә һәрвакыт төрле фәнни экспедицияләрдә йөрергә туры килә. Җәй җиту белән, илебезнең татарлар яшәгән төрле почмакларына чыгып, әби-бабалардан калган борынгы язма истәлекләрне эзләп йөрибез. Эзләгән тапкан, ташка кадак каккан, дигәндәй, археографик материал, төгәлрәк әйткәндә, инкыйлабка кадәр язылган борынгы кулъязмалар һәм сирәк китаплар, кая гына барсак та, әле һаман табылып тора.



«Нократ бәете»ннән сәхифә

2012 елда без, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, Удмуртия Республикасына экспедиция оештырдык. Анда татарлар күпләп яшәгән Балезино, Юкамен, Глазов районнарында булып, шактый гына кулъязма мирас табып алып кайта алдык. Удмуртиядә археографик материал эзләп йөргәндә, кайбер авылда яшәүчеләр безгә Пучинкә авылына барырга киңәш иттеләр. Анда, янәсе, бик күп борынгы кулъязмалар табарга мөмкин икән. Инде вакыт кичкә таба якынлашса да, без башка экспедиция әгъзаларыннан аерылып, шул Пучинкә авылына киттек. Авылга килеп керүгә, мәчете игътибарны җәлеп итте. Авыл имамы Надир хәзрәт Бузанаков безне якты йөз белән каршы алып, мәчеттә сакланучы борынгы кулъязмалар һәм сирәк китаплар белән таныш-

тырды. Соңыннан, бик үтенеп сорагач, ул аларның бер өлешен Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Мирасханә»сенә тапшырырга риза булды, гәрчә, мәчеттә бу материаллар белән китап музее оештырырга теләге булса да. Казанда алар күбрәк файда китерер, дип уйлап бер дә ялгышмады хәзрәт, чөнки аларны анда Казан галимнәре тикшереп, өйрәнеп, шулар нигезендә күпме фәнни хезмәтләр, диссертацияләр, монографияләр, мәкаләләр, китаплар яза бит.

Пучинкә авылында табылган кулъязмаларның берсе аеруча игътибарны җәлеп итте. Анда Нократ хакында озын бер бәет урын алган. Ул XX гасыр башында гарәп графикасында язылган, эчтәлеге белән тормыш-көнкүреш хәлләренә бәйле. Бәетнең исеме күрсәтелмәгән. Бәлки ул бөтенләй булмагандыр да, шуңа күрә шартлы рәвештә генә «Нократ бәете» дип куйдык. Биредә сүз Вятка губернасы Слободской өязенең Ярослав волостында (хәзерге Киров өлкәсенең Слободской районы) урнашкан Нократ авылы турында сүз бара булса кирәк. Әлеге бәетнең кыскача эчтәлеге болай: Глазов өязеннән бер фәкыйрь кеше, Нократ авылына сәфәргә чыга, барып җиткәч, моңа хәтле таныш та булмаган бер Һади исемле мулланы күрергә була. Мулла өйдә булмаса да, абыстае аны бик хөрмәтләп кунак итә. Аннан соң башка муллалар да бер-бер артлы бу кешене кунакка чакыра башлый. Муллалардан Һади, Салах, Таһир, Нәҗип, Әхмәдсиддыйк, Зариф, Гариф хәзрәтләрнең исемнәре телгә алына, аларга бераз характеристика бирелә. Шулай ук зур кибетләр тотучы, сәүдәгәр Бородин хакында да сөйләнелә. Нинди генә ризыклардан авыз итмичә калмый фәкыйрь мосафир, хәтта киткәндә үзенә бик күп итеп сәдакалар, бүләкләр биреп кайтаралар. Үзенең күргәннәрен бу фәкыйрь кеше лирик герой исеменнән юмор-сатира һәм төрле сәнгать чаралары ярдәмендә тасвирлап, шигъри юлларга салган һәм бәет формасындагы менә дигән әсәр барлыкка килгән. Кызганыч ки, автор үзенең исемен бер җирдә дә күрсәтмәгән, язып калдырмаган, шуңа күрә аның турында бер мәгълүмат та юк. Күп кенә халык авыз иҗаты әсәрләре, кем тарафыннан чыгарылганы онытылып, гомумхалык иҗатына әверелгән. Шул сәбәпле, бу әсәрне дә халык иҗаты әсәре итеп карарга кирәк.

«Нократ бәете» язылган кулъязма китапның үлчәме: 18х11, текстның үлчәме: 16,5х10. Күчерүченең исеме, күчерү вакыты һәм урыны күрсәтелмәгән. Кәгазе безнең илдә эшләнелгән булган, чөнки анда кысу юлы белән төшерелгән бизәкле штемпель эзе бар: «Фабрики / Платунова / № 7». Шуннан чыгып, ышанычлы рәвештә, кәгазе Вятка губернасының Слободской өязе Урта волостына урнашкан Платунов фабриксында җитештерелгән, дип әйтә алабыз. Библиограф, тарихчы С.А.Клепиков фикеренчә, әлеге фабрика штемпеле 1914 елда чыккан кәгазьләргә куелган. Димәк, кулыбыздагы кулъязма китап та шул дәвергә карый булып чыга. Текстлары заводта җитештерелгән шәмәхә төстәге каралар белән язылган. Кустодлары куелмаган, шулай ук пагинациясе, тышлыгы да юк. Кәгазьләр, кулдан ефәк җеп белән бераз тупас рәвештә тегелеп, китап формасына китерелгән. Сакланылышы уртача, дип әйтергә мөмкин. Шулай да, бөкләнеп ятканлыктан, кайбер битләре урталай ертылган, дымлы урында ятканлыктан, төрле кечкенә саргылт кара таплар барлыкка килгән.

Укучыларга бәетнең тулы текстын тәкъдим итәбез, аңларга уңайлы булсын өчен кайбер архаик грамматик формалар хәзерге әдәби тел нормаларына салынды, кулланылыштан төшеп калган лексик берәмлекләр астөшермәләрдә аңлатылып барылды.

[1] Клепиков С.А. Филиграни и штемпели на бумаге русского и иностранного производства XVII-XX вв.— М.: Изд-во Всесоюзной Книжной палаты, 1959. — С.107.

НОКРАТ БӘЕТЕ

Бисмилла дип чыгып киттем
Нократка[2] барырга,
Нократка баргачтын[3],
Хәйран булып торырга.
Бисмилла, дип чыгып киттем
Иртә торып таң берлән[4],
Нократтан барып кайттым
Әлхәмделилләһ[5], мал берлән.
Нократның атлары
Юлга чыккач, һич армый,
Нократны күрергә
Безнеңише кем бармый.
Нократка без бардык,
Хәйран булып без тордык,
Нократка баргачтын,
Кунак булып без йөрдек.
Машинада[6] баргачтын,
Төшеп калдым Ардаштан[7],
Бер муллада кунак булдым
Килеп кергәч бер баштан.
Машинадан төшкәчтен,
Бардым инде җәяүләп,
Нократка баргачтын,
Кердем аулак җир сайлап.
Нократның мулласының
Күңелләре шат икән,
Нократта Һади мулла
Кунак өчен ялт икән.
Бу Лүкмидә без торабыз
Кара өйдә буялып,
Һади муллага барып кердем
Йөзем кызарып, оялып.
Һади мулла өйдә юк,
Ашка киткән ашыгып,
Бибифәрбиза алып керде
Йон шәленәябынып.
Чүпчи суның буеннан
Ата куян тотканнар,
Абыстасы юмарт икән —
Пешереп җиткерде бөкканнәр.
Бибифәрбиза кизүлидер[8]
Күгәрчен күк гөрелтәп,
Чалт-чалт итеп басып йөри,
Кала идәннәр дерелдәп.
Бибифәрбиза чәй китерә
Подносларын күтәреп,
Алдан нигъмәт китерде
Күңелләрне юатып.
Су буенда су сары,
Барып ничек тотарым[9],
Һич исемдә юк иде
Бу кадәр кунак буларым[10].
Югары өйдә чәй эчтем,
Күңелләрем йомшап,
Юмарт икән абыстайлары,
Мактасаң да, хәер, шәп.
Һади мулла кайтып керде
Кояш кебек ялтырап,
Һади мулла кергән чакта
Мин торамын калтырап.
Күңел берлән кунак итте
Һади мулла тартынмый,
Унике көн кунак булдым
Нократтан артынмый[11].
Сагынганда без йөрибез
Лүкми буенда җыр җырлап,
Барган көнне дүрт мулласы
Кунак кылды бик зурлап.
Нократтагы муллаларның
Ахун мулла атасы (ягъни зур мулла).
Нократка баргачтын,
Һич килмидер кайтасы.
Бу Лүкминең фетнәсе
Бетәсе юк үлгәнче,
Җәннәткә кергәчтен,
Кемнең килсен чыгасы.
Нократка баргачтын,
Сыйлагачтын[12], куандым,
Һәр муллада кунак булып,
Бик күп көннәр юандым.
Ахун мулла безне сыйлый,
Безне сыйлау зур эштән,
Ахун мулла сәдака бирде

[2] Текстта Нохрат дип бирелгән.
[3] Баргачтын (диал.) — баргач.
[4] Берлән — белән.
[5] Әлхәмделилләһ — Аллага мактау булсын.
[6] Бирелдә сүз поезд турында бара.
[7] Ардаш станциясе.
[8] Кизүлидер (диал.) — аш-су пешерәдер.
[9] Тотарым (диал.) — тотармын.
[10] Буларым (диал.) — булуым.
[11] Артынмый (диал.) — артмый.
[12] Сыйлагачтын (диал.) — сыйлагач.

Егерме тиен көмештән.
Салах муллага ашка бардык.
Кич атна кич[13] җыелып,
Бер өстәлгә утырдык
Утыз кеше җыелып.
Салах мулла аш китерә
Алдан төрле нигъмәт,
Һәр кешегә егермешәр тиен,
Сәдака бирде бик юмарт.
Оренбурның арасы,
Казакъ чәчкән тарысы,
Нократның мулласы,
Кунак итте барысы.
Бу язуны яздым бән[14]
Йөргәнемне исәпләп,
Нократта йөргәнне
Кайчан бетерерсең хитаблап.
Нәҗип хәзрәт чакырып алды,
Чыгарбыз, дип болынга,
Рәхәтләнеп утырып бардым
Тимер арба турында.
Су буеннан барганда
Чыланды читек, олтаннар,
Чәй эчкәндә китереп бирде
Урыс бик зур чуртаннар.
Таһир мулла мөәзин берлән,
Без утырабыз сыйланып,
Су буеннан абыстайлар
Йөриләрдер бизәнеп.
Хәзрәт алды чуртаннарны
Акча биреп бәйләнеп,
Чуртаннарны пешерделәр
Казан тулы май салып.

[13] Кич атна кич — кич пәнҗешәмбе.
[14] Бән — мин.
[15] Җәмыгы — бөтен.
[16] Тәрәккый — прогрессив.
[17] Гулянья — гуляние.
[18] Хуб — яхшы.
[19] Безләр — без.

Хәмит Латыйф рәсемнәре

Болын буенда йөргәндә
Һәвәс килә курадай,
Су буенда без йөрибез
Казаннан килгән түрәдәй.
Су буенда абыстайлар
Йөриләрдер бизәнеп.
Хәзрәт берлән чәй эчәбез
Су буенда тезләнеп.
Су буенда кошлар сайрый,
Талдан талларга кунып,
Җәмыгы[15] көнне хозур кылдык
Ерак җирләргә барып.
Нәҗип хәзрәт тәрәккый[16],
Эчмидер ул аракы,
Алты төрле гәзит ала,
Һәрбер эше яраклы.
Шәмсекамәр абыстай
Килә суның буеннан,
Гуляньяда[17] йөргәнем
Чыгасы юк уемнан.
Нократта бакча хуб[18],
Байларында акча күп,
Гуляньяда без йөрибез
Кечкенәрәк патша күк.
Гуляньяда күрелде,
Төрле нигъмәт җыелды,
Шәмсекамәр абыстайдан
Егерме биш тиен бирелде.
Нәҗип мулла хәзрәт
Җигеп җибәрде бер кара ат,
Үз өлешне биш сум биргәч,
Миннән бетте хәсрәт.
Нәҗип мулла хәзрәт
Бал әзерли хәзерләп,
Җыен мулла ашадык
Ул балны без кадерләп.
Нәҗип мулла малы бар,
Поднос тулы балы бар,
Нәҗип мулла юмарт дип,
Нократта даны бар.
Нәҗип мулла манарасын
Өрәнгедән ясата,
Манараны карaганда
Таһир хәзрәт ашата.
Манарага ай салганда
Безләр[19] бардык җыелып,
Таһир мулла чакыргачтын,
Безләр кердек сыенып.
Таһир хәзрәт бар икән,
Абыстасы пар икән,
Күп мулланы сыйларга
Юмартлыгы бар икән.

Әхмәдсиддыйк чакырды
Күңеле берлән раслап,
Безгә килми калсаң инде
Җибәрермен, ди, тотып.
Әхмәдсиддыйк йортының
Түбәләре тимердән,
Әхмәдсиддыйкка без бардык
Кичкә таба эңгердән.
Әхмәдсиддыйк йортларының
Әйләнәсе яшел бакча икән,
Җәйге асыл матур көннәрдә
Чәй эчәргә яхшы икән.
Әхмәдсиддыйк корты бар,
Яшел түбәле йорты бар,
Без фәкыйрьне кунак итте,
Алты төрле балы бар.
Өе тулы сәгатьтер,
Бер арганчы санап тор,
Өе тулы җиһаздыр,
Хәйран калып карап тор.
Әхмәдсиддыйк кортларын...
Барысыны[20] күрсәтә,
Безнең ише ишәккә дә
Корт гыйлемне өйрәтә.
Әхмәдсиддыйк кортларының,
Яшникләре[21] өлгедән,
Әхмәдсиддыйк абыстае
Бүләк бирде сөлгедән.
Әхмәдсиддыйк йөрмидер
Көн дә саен байлардан,
Әхмәдсиддыйк абыстае
Бүләк бирде шәлләрдән.
Әхмәдсиддыйк китабын,
Кемнәр белсен хисабын,
Әхмәдсиддыйк муллага
Байлык бирсен күп тагын.
Әхмәдсиддыйк кортларының,
Яшникләре саплы ул,
Әхмәдсиддыйк кортларын,
Җәй көн булса, саклый ул.
Әхмәдсиддыйк сәгате
Кәк-күк диеп кычкыра,
Әхмәдсиддыйк кортлары
Җәй көне бал эчтерә.
Әхмәдсиддыйк кортлары,
Мисле җәннәт йортлары[22],
Иртә-кич сүнмидер
Яна торган утлары.
Әхмәдсиддыйк бакчасында
Бер дә юктыр таллары,
Әхмәдсиддыйк бал ашатты,
Әле дә бетми тәмнәре.
Һади мулла бирде безгә
Чәч алырдай бритва,
Һади мулладай юмарт кеше
Бу дөньяда аз туа.
Һади мулла бирде безгә
Сиксән тиенлек түбәтәй,
Һади мулла озатты безне
Прогон хакын түләтми.
Һади мулла абыстае
Бирде зәңгәрле яулык,
Һади мулла абыстаена
Алла бирсен бик саулык.
Һади мулла абыстае
Бирде күлмәклек ситсы,
Һади мулла биргән нәрсә
Барысы да бик истә.
Һади мулла абыстае
Бирде безгә күмәчләр,
Һади мулла, юлда эч, дип
Бирде безгә чын чәйләр.
Бу дөнья фани торыр,
Миннән кемнәр үтмиләр,
Юлда аша, дип инде
Бирде инде күкәйләр.
Һади мулла килми монда,
Ашка йөридер анда,
Һади мулла бәхете булса,
Син дә йөрерсең көн дә.
Һади мулла бирде безгә
Бүләк итеп күп китап,
Хак Тәгалә, кыямәт көн
Әҗерене кыл бихисап.
Һади мулла бирде безгә
Юлга чыгарга акча,
Һади мулла бирде безгә
Китап йөртергә букча.
Һади мулла бирде безгә
Укымага күп китап,
Һади мулла биргән нәрсәне
Кемнәр бетерсен чутлап.
Безнең кияү бик уяу,
Яшь матур кызны йомдырды,
Безнең Идрис мулланың
Кызын алып тондырды.
Гариф мулла уяу кеше,
Махы бирмидер яшьләргә,
Мулла кызы Гайшәне
Үзе тырыша башларга.
Гариф мулла бик юмарт,
Яшь кыз алды — күңеле шат,

[20] Барысыны — барысын.
[21] Яшникләре — ящиклары.
[22] Мисле җәннәт йортлары — җәннәт йортлары кебек.

Безгә әгәр менмәсәң,
Кылыч җибәрермен, карап ят!
Гариф мулла үзе бар,
Төрле нәсыйхәт сүзе бар,
Бер җария кызы бар,
Бирәм, дигән сүзе бар.
Гариф мулла сөендерде,
Ике кичне кундырды,
Бер күлмәклек ситсы биреп,
Безнең күңелне тондырды.
Язгы көндә безнең монда
Ватык була киртәләр,
Нократка баргачтын,
Бородинга кертәләр.
Бородинның кибетендә
Ислемайлары тулыдыр,
Бородинда бик күп нигъмәт,
Өстәлләре тулыдыр.
Бородинның Сабирын
Ходай кылган сабырлы,
Сатуларын кыйбат бирми,
Очсыз бирә әйберне.
Бородинның кибетеннән
Бар да сату алалар,
Муллага кыз бирәләр,
Мулладан кыз алалар.
Бородинның кызлары
Йолдыздаен[23] күзләре,
Бородинның кызлары
Алпавыттай үзләре.
Бородинның бакчасы,
Бакчасында мунчасы,
Мунчасына су китерә
Житкән өчәү духтыры[24].
Бородинның арбасының
Күннән япкан көймәсе.
Бородинның татлы икән
Майда пешкән күмәче.
Бородинның йортлары,
Яшел, кызыл сыртлары,
Бородинның, бик сөйлиләр,
Симез икән итләре.
Бородинның бакчасы,
Бакчасында кайсысы,
Су китерергә якын,
Бакчасында мунчасы.
Бородинның йортлары,
Берсе-берсе мең сумлык,
Бородиннан бүләк булды
Безгә дигән өч сумлык.
Зариф мулла ашлыдыр,
Кече түгел, яшьлидер,
Нократка баргачтын,
Ашка чакыра башлыйдыр.
Зариф мулла чакырды
Без фәкыйрьне икедән,
Хак Тәгалә аермасын
Ахыр дәмдә ипидән.
Стойлада пар аргамак
Җикдем сыңар тәртәгә,
Олуг кешенең чакыруы
Без ишәккә мәртәбә.
Нәҗип хәзрәт чакырды
Мәҗлескә дип, хат берлән,
Зариф мулланың кече углы
Яратты мине ат берлән.
Безнең Глаз өязендә
Барысы да братлар,
Салах берлән Юныслар —
Өчесе дә егетләр.
Салахетдин сатуны
Китерәдер Казаннан,
Кече энесе сатуны
Бирәдер лә арзаннан.
Безнең ише фәкыйрьне
Ашатмыйлар күп якта,
Салахетдин бик юмарт,
Чакырып алды кунакка.
Нократка баргачтын,
Күрдем биек тауларын,
Салахетдиндә бар икән,
Белмәдем һич гәүһәрен.
Чыгып бардым сәфәргә,
Нократ дигән шәһәргә,
Бу Салахта кунак булдым,
Мөмкин түгел сөйләргә.
Тимер тарантас арба,
Җигеп куйганнар бармага,
Өчесе дә сәдака бирделәр,
Оят инде алмага.
Кичкә таба яндырадыр
Гелән[25] иске лампасын,
Болар кебек юмартны
Бик күп җирдә тапмассың.
Җылы җилләр исәдер
Язгы көнне кичләрдән,
Нократка барганым
Чыгасы юк исләрдән.

Текстны басмага
***Айдар Гайнетдинов** әзерләде.* ■

[23] Йолдыздаен (диал.) — йолдыздай.
[24] Духтыры — докторы.
[25] Гелән — гел.



АРХЕОГРАФИК КӨНДӘЛЕК

Миркасыйм Госманов

(Казан университетының археографик экспедицияләр юлъязмасы)

23.09.63. Кайту булгач — кайту. Юнәлдек. Каргалыга килеп, кайбер кешеләрне күрдек. Р. Фәхреддиннең «Сәет касабәсе»н укып утырдык (ул Казанда сакланмаган).

Зиратка кереп, Хәялиннарның берсенә куелган кабер ташын таптык. Минем өметем акланды бугай! Ташның тексты:

«Мостафа бине Мөхәммәд бине Әбел-Бәкер бине Әхмәд бине Хәсән бине Сәгыйдь бине Гайед Хәялин ушбу 1745 нче ел. Шаһ хәзрәтеннән Каргалыга изен вирелеп, 8 агысда әүвәл кадәм куймыш. Сәгыйдь Хәялин — нәүвәрә-Ллаһе мәркадиһима! — 22 яшендә 3 нче октябрьдә 1901 нче елда.

Кабернең артында: «Килеп каберем зиярәт идән ихвандин, сахибенә уласыз изгелекле дога илә могыйн».

Табылган документлар арасында иң әһәмиятлесе, бәлки, шушы кабер ташыдыр...

Көндезге икеләрдә Башкортстан ягына юл тотабыз. Көн бик салкын. Барлык булган киемнәрне кию өстенә, одеялларга төренеп утырабыз — сөяккә үтәрлек җил.

Кичке 5тә Башкортстан чигенә килеп җиттек. Ләкин үтеп булмый. Нәкъ чит ил чиге сыман: шлагбаум, милиционер. Юл ябык. Бер җан иясе дә Уфа

рөхсәтеннән башка үтәргә тиеш түгел. Менә сиңа мә! Ялынып карадык, ялварып карадык — булмады, — чик ябык. Әлбәттә, Зәки Вәлиди килеп ханлык игълан итмәгән, юк, сәбәп бик гади: Оренбург өлкәсендә терлектә үләт бар икән. Менә шул гына, шуңа күрә чикне карантинга япканнар…

Көлә-көлә кире борылдык. Октябрьск дигән шәһәр кисәгенә килдек. Тик монда да уңмадык: гостиницасында урын юк. Эзли торгач, бер карт марҗаның өенә фатирга кердек. Менә сиңа гыйльми экспедиция: тар гына сәке, өстендә бер ертык киез кисәге, әйдәгез, шунда ятыгыз, түшәгегез шул. Нишләргә? Яттык. Докторы да, ассистенты да, доценты да, шофёры да — барысы да «әлиф булып», тезелеп яттылар… Бүлмәдә бер эт тә йоклады. Чоланда бозау. Ә почмакта тәре белән образ…

....

24.09.63. Шунысы хак: контрабанда булмаса, законлы юл белән Башкортстанга үтеп булмаячак. Һәм без «контрабанда» юлына бастык. Олы юлдан чыгып, Сырт тавының эченә кереп киттек. Яңгыр, җир юеш, балчык булса да, ике көпчәктә тарта торган булгач, машинабыз, нинди генә әшәке юл булса да, мышный-мышный алга чапты. Тау сыртына менеп тә чапкаладык. Манзара бик матур иде! Тау битләре калын бөдрә урман, чак кына бакырлана төшкән… Көн җылы. Шуңа күрә күңелләр күтәрелә төште. Башкорт булып кыланган Альбертны үчеклибез.

Чикне уздык бугай. Ниһаять, сакчы-мазарга юлыкмадык. Уф! Кичке дүрттә генә Күмертау тирәсендә якты юлга — асфальтка чыктык. Әйдә, куала Җиргән авылына!…

Кичке сәгать 6ларда гына тамак ялгап алдык. Җиргәнгә күз бәйләнер чакта гына килдек. Бикташиров Фәхри дигән 75 яшьлек бабайга туктадык. Ялындырып тормыйча сөйләшә һәм җитди генә тыкылдый. Аның риваятенчә, авылның исеме элек «Җир-кан» булган, имеш. Һәй, әкият!..

Тезелешеп кенә идәнгә яттык. Ләкин чиста юрган, йомшак мендәрләргә. Болары булгач, кровать юклыгы гаеп түгел.

....

25.09.63. Иртән эшкә башладык. Берничә көн каты яңгыр яуган урамнар бик пычрак иде. Берара үзебез кунган бабайны чормасына меңгереп төшердек. Берничә кулъязма алып төште. Әһәмиятсез. Берничә бабай белән әбине җырлатып карадык. Әллә ни искитәрлек нәрсәләре юк. Шулай да Хатип ага бик ләззәтләнеп язып алды. Рәфифә әби дигән берәүне җырлатып маташтык. Тырышып караса да, җырларын исенә төшерә алмады. Чыгып киттек. Бер бабайны сөйләтеп утыра идек, әлеге Рәфифә әби үзе килеп чыкты: «Балакайларым, җырым искә төште» — дип үзенең бәетләрен җырлап чыкты. Бу иске бәетләрнең өзекләреннән гыйбарәт иде.

Төштән соң Җамак, Канбулат ягына киттек. Җамакта мин ботак очы кодаларымны таптым (Магатның ерак бер апасының кызы ире белән — иренең исеме Булат). Бик якты чырай белән кабул иттеләр. Шамил абый, Ренарт, мин шунда калдык. Башкалар Канбулат авылына киттеләр. Алар нәрсә кырып йөргәннәрдер — безгә билгесез (җүнле һичнәрсә алып кайтмадылар), ә без өчәү бик шәпләп кунак булдык.

Кичке тугызда тегеләр дә кайттылар. Алар чәй эчеп алгач, Иделне кичеп, Җиргәнгә кайттык.

....

26.09.63. Салаваткa юнәлдек. Магатларга килеп төштек. Көтүебез белән. Ике-өч сәгать анда «мәш» килеп, каймаклап чәй эчтек. Ваннада юындык (әлбәттә, Альберттан башкаларыбыз…). Стәрлебаш ягына юнәлдек. Стәрлебашта төшләнеп алгач, Тәтре-Арсланны узып, Кыргыз-Миякәсенә килдек. Район мосафирханәсенә төштек. Бу тирәдә нефть юк. Шуңа

күрә ярлылык күзгә күренеп тора. Кая Җиргән белән чагыштыру!

....

27.09.63. Ашханәдә кымыз бар икән (әлбәттә, сыер сөтеннән — көне буе җил чыгарып йөрдем...). Ләкин миңа ите бик ошады. Күптән мондый мул ашханәне күргән юк иде.

Әллә кайлардан уратып, Аксаково, Бәләбәйләрне узып, Октябрьск шәһәренә килдек.

Ләкин юл искитмәле иде: юл читен сырып алган бөдрә урманнарда нинди генә төс юк: яшелдән алып кызылга хәтле. Менә бер төше күгелҗем яшел, икенче җире сап-сары, ә өченчесе исә, ут кебек... Бер рәссам да болай ясый алмастыр...

Октябрьск шәһәре бик матур икән. Ашханәсенә кергән идек: халык үлеп сыра эчә (гомумән, Башкортстанда сыра дисәң, — үләләр...). Ә шәһәр ярыйсы. Мактасаң да лаек. Гостиницасы дә шәп иде: һәр кешегә бер бәләкәй бүлмә. Күпме газаплардан соң, ниһаять! Иркен ванна. Сәгатьләр буе яттым...

Кичен М.Зәкиевнең сабакташы булган бер хатынның өенә кунакка бардык (Сәлимә Газизова, ире Әнвәр Абдуллин).

....

28.09.63. Татарстанга чыктык. Урыссуга, дөресрәге Әпсәләмгә килеп, шифер заводындагы кәгазьләр арасында гарәпчә китаплар булу-булмавын анықладык. Хәзер юк. Элек булгалаган. Кулъязмалар да күп килгән. Шулай итеп кемнәрдер әллә кайларда кулъязма эзлиләр, ә монда аларны йөзәрләп яндырганнар... Чып-чыннан крематорий. Безнең түрәләр киләчәктә мондагы кулъязмаларны караячакбызфәлән, дип йөриләр.... Кем белә. Ә кәгазь эретү ходка салынган иде.

Юлда Бәйрәкәгә туктадык. Кәшиф ага Рәхимнән Бәйрәкә тарихын сөйләтеп, магнитофонга яздырган булдык.

Кичен Бөгелмәдә идек. «Нефтяник» гостиницасы.

....

29.09.63. Бик кызу бардык. Хәттә бик зур авыл Каргалыга да (Чистай Каргалысы) ярты сәгатькә генә туктадык. Кичен Чистайга җиттек. Колхозник йортында кундык. Әшәке, сасы йорт, кердән каешланган простыня...

....

30.09.63. Иртән колхоз базарына барып, бераз суган-бәрәңге алдык. Имештер, Казанда бик хөрти... Капчыклап алалар. Мин алмадым. Нәрсәгә? Көн яңгырлы. Салкын. Көндезге 2дә Казанга җиттек.

Ә кызым шактый үскән!..

Йомгак

1. Археографик яктан рәт булмаса да, бу сәфәр безгә киң регион, төрле җир тормышын белергә ярдәм итте. Кайберләребезнең күзләре дә ачыла төште.

2. Кулъязма җыюны ашыктырырга кирәк: ул бетә бара. 20-30 еллар бик күпне харап иткән. Хәзер дә дәвам итә... Кулъязмалар арасында «Мәҗмәгъ әр-рәсаиль» (юридик әсәр) бик әһәмиятле.

3. Әзерлек бөтенләй башкача булырга тиеш. Состав турында да нык уйларга. Түрәләрдән ерак бул. Әз кеше белән, төпченеп, эзләргә кирәк. Безнең кебек «Ходайның кашка тәкәләре дә», машинада чапкалау да археографик экспедиция өчен яраксыз. Булдыра алсаң — җәяү йөр! Һәм ике-өч кеше белән генә.

4. 25 кулъязма, 20 басма китап.

5. Бик акыллы кыяфәт белән юлга чыккан идек, тәмам акылсыз эш йөртүебезне аңлап, кире кайттык...

Дәвамы бар ■

ГАМЬЛЕ СӘФӘР ХАТИРӘСЕ

Гомәр Даутов

Дөнья матур, дөнья киң һәм менә бүген дә кояш безнең өчен генә яктырта сыман! Без, ягъни татар филологиясе, тарихы һәм шәрык телләре факультетының тарих бүлегеннән берничә студент, Җәүдәт Миңнуллин белән Искәндәр Гыйләҗев җитәкчелегендә археографик экспедициягә әзерләнәбез.

Гомумән, уку-укыту программасында берничә — археологик, археографик һәм фольклор экспедицияләре каралган, әмма без төркемдәшем, Сарман районы егете Рамил Миңнуллин белән археографик экспедицияне сайладык. Моңа, мөгаен, беренче чиратта, Миркасыйм абый Госмановның кызыклы лекцияләре сәбәпче булгандыр. Аннан соң археологларның кайнар кояш астында җир казу перспективасы да, дөресен генә әйткәндә, бик үк кызыктыра торган нәрсә түгел иде.

Автобуска палатка, азык-төлек төялде, кирәкле документлар имзаланды, төркем җыелып бетте... Юл алды ыгы-зыгысы, ниһаять, тәмам, һәм без маҗаралы зәңгәр болытлар артына сузылган, буеннан-буена салават күпере яткан җәйге юлга кузгалдык.

Дөрес, озак бара алмадык, чөнки юлга чыгуыбыз кичке якта гына булганлыктан, Мари-Иле Республикасында ук кичке эңгер куып җитте һәм без, аулаграк урын сайлап, кунарга тукталдык. Ләкин җәйнең искиткеч күңелсез, котылгысыз бер детале бар икән шул — озынборыннар, черкиләр һәм шуның ише кан эчүче бөҗәкләр. Әллә мари урманнарында кеше аз йөри, шуңа күрә сусаганнар, әллә мари черкиләренә татарларның тәме ошады, белмим, нәрсә булгандыр, ләкин һәрберебезгә болыт булып ябырылды бу афәт. Тиз-тиз генә палаткаларны

корып куйдык та, бөтен тишек-тошыкларны каплап, кичке ашсыз гына кереп яттык. Палаткалар ике кешелек, без тарих факультетыннан Алмаз исемле егет белән бергә. Аның Казаннан, беренче курсны тәмамлаган егет икәне кереп урнашкач, гәпләшеп киткәч тә беленде. Иртә ятылгач, йокы да килми, ятабыз шунда юк-барны сөйләнеп. Мин, булачак татар мәдәнияте, тарихы белгече буларак, әдәбият тарихы, бүгенге әдәбият турында фикерләремне сөйлим. Шигърият корифейлары белән таныш икәнлегемне күрсәтәсе килеп, Нияз Акмал белән сөйләшкәнемне, Равил Фәйзуллинны күргәнем барлыгын әйтеп мактанам. Алмаз шыпырт, күбрәк тыңлый, минем кебек эчендәгесен чыгарып салмый. Казанга кайткач кына мин юлдашымның тулы исеме Фәйзуллин Алмаз Равил улы икәнен белдем.

Икенче көнне инде без Түбән Новгород төбәгендә идек. Бормаланып-бормаланып аккан Пьяна елгасы… Ә авыллары, авыллары, кешеләре! Үзе бер дөнья. Калкулыкка менәсең, аста татар авылы, күз чагыла — түбәләре ап-ак калайдан. Йортлар зур, халкы искиткеч тере, ашыгып-кабаланып яши, умырып эшли. Сөйләмнәре тиз, аңлап өлгерсәң — өлгерәсең, өлгермәсәң — юк: «г», «гъ» авазларын әйтеп тору юк, «Али», «Үмәр», дип кенә җибәрәләр. Күбесе, үзләре әйтмешли, мәскәүчеләр, «дирижёр» булып эшлиләр. Ягъни татар әдәби теленә күчерсәң, Мәскәүдә яшиләр, дворник булып эшлиләр. Безнең максат: өйдән өйгә кереп, әбибабай, абый-апалардан, гарәпчә язылган китап, газета-журналлар, метрика кәгазьләре сакланып калмаганмы, дип сорап, әгәр булса, аларга күз салып, инде нинди дә булса фәнни кыйммәте булса, үзебез белән алырга рөхсәт сораудан гыйбарәт. Ул, гадәттә, болайрак була. Капканы ачып керәсең, ишегалдында олы яшьтәге апа тавык чебиләре, каз бәбкәләре белән мәш килеп йөри.

— Исәнме, апа!

— Исәнме, каным.

— Апа, без Казаннан, тарихчылар, арабча китаплар багып йөрибез. Шундыйлар сездә дә юкмы, дип кергән идек…

— И, каным, син каян арабча укыйсың ди?

— Беләбез апа, беләбез, безне шуңа үрәтәләр.

— Әнә, цормага цорнап бәргән идек. Ркача ки дә, коцерга белән тартып бак. Аруга такалгандыр ул. Укып алмассың син аны…

Авыл буйлап йөргәндә төрле кешегә тап буласың. Дөресрәге, һәр йорт — үзе бер дөнья. Бер нәрсәгә игътибар иттем: бу як халкында тарих буенча мәгълүмат ачлыгы. Бик күбесе Казан университеты студентлары икәнлегебезне белгәч, «Без кемнәр?», «Татарлар каян чыккан, нинди халык?» дигән сорауларга бездән җавап көтәләр. Белгәнне сөйлибез, белмәгәнне дә белгән итеп шомартып бирәбез.

Ул елны мин үземә яңа дөнья ачтым. Ул дөнья тарих, гарәп язулы кулъязма китапларда сакланып калган татар тормышы, кичке учак буендагы гамьле вә фәнни әңгәмәләрдән гыйбарәт иде. Ул елны мин халкым яшәешенең бик зур географик киңлекләргә таралганын, тел бизәкләренең искиткеч бай, тормышка омтылышының гаять көчле икәнен аңладым. Елга буендагы сүнәр-сүнмәс учак янында яткандә әрәмәлектән атлар пошкыруы, кыр уеннарына чыккан татар яугирләренең тын гына сөйләшүләре ишетелгәндәй була иде. Камыр белән кәгазьне катырып ясалган тышлык эчендәге шәкерт дәфтәрләре, «Йосыф-Зөләйха» нөсхәләре, «Шура» журналы, «Вакыт» газетасы төпләмәләре — һәммәсе дә данлы һәм шанлы вакытлар турында сөйлиләр иде.

Кайткач, Казан миңа тар тоелды. Мин инде бөтен дөньяга җәелгән татар дөньясы барлыгын, үземнең исә шул дөньяның бер кисәге икәнемне аңлый башлаган идем. ■

БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ

Эльвира Ихсанова*,
Азнакай районының Урманай урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Сурәтнең артына түбәндәге сүзләр язылган: «Гариф! Дусларны, туганнарны теләп йөргән чакта туган итеп сине очраттым. Җылы булды күңелгә. Бу рәсемдә — минем копиям. Син аны — теләсәң нишләт. Ә оригиналы турындагы истәлекне сакла. Мин сине әдип итеп тә, дус итеп тә яраттым. Исән бул. Бәхетле бул, туган. Үлеп калсам, искә еш төшер. Гаделең». Димәк, ул гади түгел, ә татар әдәбиятының олпат әдипләре булган Гариф Галиев һәм Гадел Кутуйларның кул җылысын саклый. Шушы уйлар белән мин әлеге фотосурәт турындагы тикшеренүләрне башладым. Мәктәп музеенда саклануччы материалларны, Бөек Ватан сугышы турындагы матур әдәбиятны, публицистик материалларны, интернеттагы чыганакларны, ресурсларны өйрәндем. Гариф Галиев белән Гадел Кутуйның фронт юлларын, дуслык җепләрен өйрәнгән вакытта мин Розалия Нуруллинаның «Гадел Кутуй турында истәлекләр» китабы белән таныштым. Әлеге җыентыкка кергән Гариф Галиевнең «Безнең Кутуй» исемле истәлеген укып чыкканнан соң, бирeдә сүз нәкъ менә безнең музейда саклануччы фоторәсем турында барганлыгын ачыкладым. Гариф Галиев әлеге истәлектә менә нәрсәләр яза: «Гадел Кутуй белән Бөек Ватан сугышы елларында бергә булган чакларым хәтеремдә шулкадәр калган ки, ул менә бүген дә каршымда басып тора, мин бүген дә вакыт-вакыт аның үзенә бертөрле тавыш белән: «Гариф!» — дип дәшкәнен ишеткәндәй булам. Минем алдымда аның менә бер рәсеме ята. Бу Гадел Кутуйның фронтта бөек Ленин партиясе сафына кабул ителгән вакытында төшерелгән рәсеме». Шушы тантаналы вакытта төшкән фотосурәтен Кутуй дусты Гарифка бүләк итә. Гариф ага фотосурәтне гомере буе саклый.

Фоторәсемдә Гадел Кутуйга партия билеты тапшырган мизгелләр сурәтләнгән. Кутуй, чын күңеленнән куанып, сул кулына партия билетын тоткан. Аңа билет тапшырган бригада командиры гвардия подполковнигы А.В.Михайловның йөзе шулай ук шат. Ул бик теләп, аталарча бер җылылык белән, Кутуйның кулын кыса. Уртада утыручы кеше исә — Самсон За-

*Азнакайда үткәрелгән «Туган ягым — яшел бишек» төбәкара фәнни-гамәли укытучылар конференциясендә бу хезмәт 2 нче урынны яулады. Язма кыскартып бирелә.



кладный, гвардия подполковнигы, политбүлек начальнигы. Вакыйга 1943 елның гыйнвар ахырында була. Бу — Бөек Ватан сугышының иң авыр еллары. Гадел Кутуй хезмәт иткән 3 нче гвардия авыр миномёт бригадасы Дон фронты командующие боерыгы нигезендә генерал Батов командалыгындагы 65 нче Армия карамагына тапшырыла һәм, дошманның бик яхшы ныгытылган оборона ныгытмасын өзеп, Сталинградка таба китә. Әнә шул дәһшәтле көннәрдә Кутуй Коммунистлар партиясенә алуларын үтенеп, политбүлеккә гариза яза. «ВКП(б)га член итеп алуыгызны үтенәм. Ленин эшенә, партия эшенә һәрвакыт тугрылыклы булырга сүз бирәм. Дошманны җиңү өчен көчемне дә, гомеремне дә кызганмам», — дип яза ул гаризасында. Утырышта Кутуй бертавыштан партия сафына кабул ителә. «Берничә көннән соң партиягә яңа алынган иптәшләргә билетлар тапшыру тантанасы булды», — дип искә ала Самсон Закладный үзенең истәлекләрендә.



Искәрмәләр

1. Розалия Нуруллина. «Гадел Кутуй турында истәлекләр». — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1984. — 131-139 б.
2. Розалия Нуруллина. «Гадел Кутуй турында истәлекләр». — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1984. — 100-113 б.



ҖӘЛӘЛЕТДИН ӘТИ

хикәя

Мостай Кәрим
(1919-2005)

М.А.Зайцевка багышлана

Минем бер дустым бар. Хөрмәтле кеше. Зур кеше. Исеме Михаил. Фамилиясе Куянов. Зур кешеләр дә кайчандыр бәләкәй булганнар. Бала булганнар. Минем дустым да бала, җитмәсә, детдом баласы булган. Сугыш аны тиз үк ятим калдырган. Куяновның табигатендә тәү карауга бер-берсеннән ерак торган ике сыйфат бар: тартынучанлык һәм тәвәккәллек. Ә асылда аның кыюлыгы инсафлы, әдәплелеге батыр. Нәкъ шулай. Сүзгә юмарт ук булмаган бу кешенең сагынып сөйләгән нәрсәсе — шул детдом хәлләре — аның тамашалары, маҗаралары, хикмәтләре. Алда бәян ителәчәк әңгәмә аның авызыннан бәйнә-бәйнә чыккан сүз.

— Көз башында безнең классның тәрбиячесе «камыш сыйрак, җиз чукыш» Федора Тихоновнаны кайдадыр бүтән җиргә җибәрделәр. Азып, шаярып киткән чагыбызда безне кычкырып тыңлата алмаса, ул, утырып, шым гына елый иде. «Нигә сез, ятимкәйләрем, шулхәтле аяусызсыз? Мин дә ятим үстем, ә күңелем катмады…» — дип зарын түгә. Унөч-ундүрт яшьлек малайларны, бигрәк тә детдом шайтаннарын күз яше белән җиңү мөмкин түгел. Бик теләсәң дә, булмаган эш. Чөнки йомшак күңеллелек анда бәгырьсезлеккә буйсына. Киресенчә килеп чыкмый. Без Федора Тихоновна артыннан, тел чыгарып, танау тартып озатып калдык.

Атна да үтмәде, безгә яңа тәрбияче килде. Тәрбияче түгел, кәртинкә, бер тамаша. Күргәч тә шаккаттык. Гәүдәсе белән торуы ук — пәһлеван! Калын кара мыегы, танау астыннан чыгып, ярты битен каплаган. Будённыйныкыннан да хәтәррәк. Түбәсендә — арттан ике тасмасы асылынып төшкән матрос кәпәче, өстендә — җиз төймәләре җемелдәп торган постау бушлат. Түшендә бер медале дә бар. Кара чалбарының яман киң уң балагы җиргә тиеп-тиеп кала. Шул балак читеннән кара ботинка борыны ялтырап күренә. Сул балагы, бик пөхтә төрелеп, агач аякка кыстырылган. Әүвәлрәк, яңа укытучы яки тәрбияче килсә, аны йә директор, йә бүтән берәү кертеп, мактыймактый безнең белән таныштыра иде. Бу юлы бүтәнчә булып чыкты. Безнең класс, көндезге дәресләр беткәч, алга бирелгән сабакларны әзерләп утыра иде. Шулчак ул ялгызы килеп керде. Тәүдә без, күзебез белән йотардай булып, моңа карап каттык. Шуннан берәм-берәм аягүрә бастык. Шушындый гыйфрит каршында басмый чыдап кара. Ул да эндәшми, без дә шымдык. Байтак вакыт үтте.

— Утырыгыз, егетләр, — диде ул, калын тавышы дөңгер-дөңгер килеп чыкты.

Ул әйткәч тә, утырышырга тиз үк базнат итмәдек, «егетләр» булсак та.

— Утырышыгыз. Мин сезнең яңа тәрбиячегез. Исемем Җәләлетдин. Фамилиям Кулыев. Җәләлетдин Кулыев булам. Сыңар аякка калган матрос. Севастопольдә мина өзде. Яшем кырыкта. Сезнең барыгызга да әти булыр яшьтәмен. Миңа «Җәләлетдин абый» дисәгез дә, «әти» дисәгез дә була. Кабул итәм. Өлкән улым Вәлетдин язын Берлинны алды да хәзер шунда хезмәт итә. Ул сездән чак кына олырак.

Моңа да хәйран калдык. «Их, Вәлетдин кебек, бәхетең булып, фашистларны кырып, Берлинны алсаң иде», — дип көнләштем мин. Байтак кына торгач, яңа тәрбияче өстәп куйды:

— Яхшы кылыкларыгыз өчен мактармын, яманы өчен әрләрмен.

Моңача безгә яхшысы өчен дә, начары өчен дә бер үк нәрсә — әрләү эләгә иде. Чөнки еш кына әйбәт эшебез дә аламалык белән бетә иде.

Ул тәрәзә янында торган артсыз утыргычка узып утырды.

— Мин шушында шым гына утырып торам: сез ашыкмый-кабаланмый дәресләрегезне әзерләгез. Эшегезне җиренә җиткереп башкарсагыз, бер тәкъдимем булачак. Әлегә әйтмим. Сер.

Без эшкә керештек. «Камыш сыйрак, җиз чукыш» булса, шунда ук берәр кызыклы китапка ябышыр иде. Бу тик утыра бирә. Ара-тирә генә безгә күз ташлый. Сөзелеп күзәтми, болай гына карап ала. Ашыкмау кыен булса да, түзәбез, сер бирмибез.

Класс атаманы кылый Гарибальди арабызда иң усалы. Чын исеме Мөхтәр аның. Ул безне йодрык эчендә кысып тота. Эш беткәнне аңлатып, без кыймылдаша, шылыша башлагач та, кымшанмый утыра. Этләшә, явыз. Безнең чыдамлыкны чыныктыра. Шул һөнәрне ярата ул. Үзе башлы малай. Дәресләрен «ә» дигәнче әзерләп ташлый.

Кылый Гарибальди аягүрә басып, утыз ике такыр баштан торган классны байкап чыкты.

— Әзер, — диде ул, — сезгә күрсәтергәме?

— Әзер булгач, әйбәт. Бүгенгә болай да ышанам.

— Алдашу юк. Алдакчының колагы кызара,— дип кырт кисте Мөхтәр, янәсе, кинаяләп.

— Флотта да шулай. Ялганчының күмәкләп колагын уалар, — дип куәтләде пәһлеван. — Ярый. Мондый җәзаны кулланырга безгә туры килмәс... Ә бая әйткәнем шул. Көн чуак, җылы. Әнә, һавада сузылып-сузылып үрмәкүч дебетләре йөзә. — Ул тәрәзәгә күз ташлап алды. — Кичке ашка хәтле әле вакыт күп. Теләсәгез, әйдәгез, урманга чыгабыз. Ризамы?

Урманга түгел, әле безне урамга да чыгармыйлар. Өлкән класс укучысы кайдадыр тәртип бозган да, шуның бәласе барыбызга да тиде. Тәрбиячене сүзләренә без тәүдә ышанып та җитмәдек. Беренче булып яшел тавышлы Айтимер сөрәнләде.

— Ур-ра, урман! Ур-ра! — Ул урманлы мари ягыннан иде.

Шуннан барысы да гөж килде.

— Ярый алайса, әйберләрегезне җыештырыгыз да, кузгалыйк.

Ул елларда шәһәр тирәсендә имән катыш юкә урманнары, чокырларда шырлыклар бар иде. Безгә якын гына шундый урманга юнәйладык. Көн чалт аяз. Саргылт үлән өстендә сыек нурлар җемелдәп уйный. Җилнең әсәре дә юк. Күктә бая тәрбияче әйткән үрмәкүч җепләре бәвелеп тора. Аксак баһадир, агач аягын селти салып, салмак кына атлый. Без аның бер алдына, бер уңына, бер сулына чыгабыз. Аңа сүз кушасы, күңеленә ятарлык нәрсәдер әйтәсе килә. Тик ничек, кем дип эндәшергә?

Мин мондагы ятимнәрнең иң бәләкәчемен. Шулай да сугышка киткән әтиемне бик яхшы хәтерлим. «Әти» сүзе тел очында гына, ычкынырга гына тора. Ычкыныр да иде, Гарибальдидан узып, әйтергә батырчылык җитми. Чак түзәм.

Урман читенә җиткәч, матрос безгә болай диде:

— Бер-берегезгә күз-колак булыгыз. — Ул Мөхтәргә аерым эндәште. — Исемфамилияң кем әле синең?

— Мөхтәр Ишбулдин-Гарибальди. Кушымтасы китап исеменнән күчте.

— Ә син, Мөхтәр Ишбулдин-Гарибальди, барысын да канат астыңа ал. Ризамы шуңа?

— Ярый, риза, Җәләлетдин эти, алырмын, — диде теге кыяр-кыймас кына.

Чирканчык алынды! Китте шунан «Җәләлетдин эти». Кирәксә-кирәкмәсә дә әйтергә тырышабыз: «Җәләлетдин эти», «Җәләлетдин эти». Әйтерсең, әле генә телебез чыкты.

Урман буенда озак булдык, йөгерештек, сикерештек, көрәштек, тәкмәч аттык, шап-шакыр, күз бәйләш уйнадык, туйганчы туп типтек. Биек агач ботагына атланып, таган атындык. Айтимер куак арасыннан кечкенә кош оясы табып чыкты. Кесә тутырып имән чикләвеге җыйдык. Шырлыкка кереп, миләш чүпләдек. Нәрсә теләсәк, шуны эшләдек. «Чү!», «Ярамый!» дигән сүз ишетмәдек. Җәләлетдин эти, ауган имәнгә утырып, безнең рәхәткә чыгуыбызга куанып, тик елмаеп торды. Мин аннан бит күземне дә алмыйм. Шул матур көндә мин генә зур бәлагә тарыдым. Агач башыннан сикергәндә, коры ботакка эләгеп, күлмәк итәгем ертылды. Елардай булып, Җәләлетдин этигә килдем. Мондый зыян өчен бездә нык әрлиләр. Ул минем такыр башымнан сыйпады да:

— Син кем әле? — диде.

— Миша Куянов, —дидем дә елап җибәрдем.

— Җебеп төшмә, Миша Куянов. Син әле берзаман ир арысланы булырсың. Күлмәкне без аны синең белән тегеп кенә түгел, хәзер коеп куябыз.

Ул, матрос кәпәчен салып, аның кайсы җиреннәндер кара җепкә сапланган юан гына энә китереп чыгарды, исән аягын алга сузды. Йомшак кына тавыш белән:

— Сал күлмәгеңне, — диде.

Утырган җирендә ертыкны тегеп тә бирде.

— Әнә, элеккедән дә купшырак килеп чыкты. Ә син балавыз сыгасың.

Чынлап та, җөе дә беленми бит.

Минем казадан башка, барысы да әйбәт булды, йөгерә-сикерә уйнап кайттык.

Иртәгәсен алама хәбәр ишеттек. Директор, имештер, башбаштаклык күрсәтеп, безне урманга алып чыккан өчен Җәләлетдин этигә шелтә биргән. Теге ыжламаган да. Чикерткә хәтле генә директорга исе китте ди шушындый геройның. Чиртте очырды булыр. Ятар аннан чикылдап.

Кич яткач, озак йоклый алмадык. Бик кирәкле эшне тикшердек. Җәләлетдин этиебез рядовой матрос булып йөри. Алай йөрмәсен, аңа зур звание бирергә кирәк.

— Ә ниндине?

— Китаптанмы, әллә чынныммы?

— Түлке чынны!

— Алайса ни, генерал инде.

Юләр, генерал коры җирдә генә командовать итә ул.

— Ә агач аяклыга зур звание ярый микән? — Моны һәрчак икеләнүчән Изя дигән малай әйтте.

— Аның бердәнбер аягы ике, хәтта өч аякка торырлык, агачын да кушсаң... — дигән төзәтмә кертте кушбаш Сабир.

Мөһерне Мөхтәр сугып куйды:

— Аңа адмирал тиешле. Коры гына адмирал түгел, ә адмирал Нахимов. Медальгә төшкән Нахимов.

— Берчак ул да Севастопольдә каты сугышкан. О-һ-о! — дип мин дә белемемне күрсәтеп алдым.

Бу, әлбәттә, бик каты, бик зур сер булырга тиеш. Аны бездән башка берәү дә, хәтта Җәләлетдин эти үзе дә белмәячәк. Мөхтәр пәкесенең корычын үбеп, рыцарьларча ант бирдек. Серне чишкән адәм гомерлек кызыл колакка әйләнәчәк.

Фәрит Муллахмәт рәсеме

Тәүге көндә үк такыр башлы утыз ике малайны әүрәтте дә куйды Җәләлетдин әти. Өстәвенә, шушы ике-өч сәгать эчендә байтагыбызның исемен, хәтта фамилиясен отып алды. Кайтыр юлда әле беребезне, әле икенчебезне исемләп атап, янына чакырды, сүз кушты, сорашты, бәләкәйгә-зурга, көчлегә-көчсезгә аермады.

Иртәгәсен дә ул төштән соң керде. Бу юлы матрос формасында түгел, таушала төшкән соры костюмда иде. Тиз генә танымый тордык, ләкин аптырамадык. Көн дә бәйрәм, көн дә туй булмый да. Агач аягы гына элекке иде. Шакылдатып басып, ул тәрәзә янына узды да кичәге утыргычка утырды. Класс озак басып калды. «Адмирал әти» (әчемнән мин аны шулай дип атыйсым килде) елмаеп, кулы белән ишарә ясады.

Утырышып, дәрескә керештек.

— Бүген нәрсәдән бирделәр? — диде ул.

Атаман җавап кайтарды:

— Алгебрадан, янә химиядән язма эш. Күп түгел.

— Ярый, алгебра хикмәтле фән ул. Эшләп беткәч, староста әйтер.

Ашыкмасам да, сабагымны тиз бетердем. Бүтәннәр дә шулай. Баш үзеннән-үзе эшли. Күңелдә шундый җиңеллек, яктылык. Рәхәт. Авылдагы картәнием бу хәлне: «Күкрәгеңдә синең тәңре нуры балкый», — дияр иде. Мин бит эшемне үзем өчен эшләмәдем, Җәләлетдин әти хакына башкардым.

Эшебез беткәч, бер-бер артлы килеп, дәфтәребезне адмирал әтигә күрсәттек. Ул берәүнең дә дәфтәрен кулына алмады. Мөхтәрнең генә ачык дәфтәр битенә имән бармагы белән төртеп сорады:

— Кара әле, Мөхтәр, шушы җирдә хата юкмы?

— Юк! — Күзен кыйшайтып карап алды Гарибальди. — Хата юк!

— Син әйбәтләбрәк кара.

— Әй, бар икән дә. Азагына нокта куелмаган.

— Сиңа аеруча җыйнак булырга кирәк, Ишбулдин. Сиңа бүтәннәр иярә. Ә калганы бик яхшы. Молодец! Ярый.

«Ярый» сүзен яратып әйтә ул.

Миңа чират җиткәч, шундый искәртү ясады:

— Эчтәлеге яхшы, формасы шәп түгел, Миша Куянов. Ягъни хәрефләрең тигез тезелмәгән. Музыка язуы сыман. Тырышсаң, коеп куярсың, син булдыклы егет.

«Музыка язуы» нәрсә икәнен мин үсә биргәчрәк кенә аңладым. Нота була икән ул. Язуым минем тора-бара төзәлде.

Дәресләр әзерләүгә кире әйләнеп кайтмас өчен, шунысын әйтеп бетерим. Ары-

табан ул эшләребезгә сирәк күз салды, ә аларны үзара тикшертте: син — минекен, мин — синекен. Әлбәттә, бер-береңнең хаталарын чүпләү әйбәт үк нәрсә булмагандыр — әлегечә, өлкәннәрчә уйлаганда. Ләкин Җәләлетдин әти кушкач, без аны гамәлгә санадык, иптәшләреңә ихлас ярдәм итү дип аңладык. Үчекләшмәдек тә.

— Бүген шимбә. Сезгә кино күрсәтәчәкләр. «Салават Юлаев»ны.

Без шауларга, чәбәкәй итәргә керештек.

— Туктагыз әле, әйтеп бетермәдем. — Аның калын, көр тавышы безне тиз басты. — Минем шундый ниятем бар. Һәр якшәмбе саен арагыздан дүртәвегезне кунакка чакырмакчымын. Сыем сыек, түрем иркен. Хатыным да риза, сез шуңа ничек карыйсыз?

Ничек карыйк инде? Безнең ни, беребезнең дә һичкайчан кунакта булганыбыз юк. Нәрсә икән ул «сыем сыек, түрем иркен»?

— Ярый, каршы килүче юк?

«Детдом балалары» дигән исем усаллык, чаялык төшенчәсе йөретсә дә, эчтән алар кыюсыз, оялчан булалар. Шуңадыр инде бу хәбәргә дә аптырабрак калдык.

— Каршы булмагач, тәүге дүртәүне тәгаенләп куегыз. Шобага салыпмы анда... Иртәнге аштан соң килеп алырмын, кире якка озатып куярмын.

Менә бер тамаша! Кемнәр генә бәхетенә эләгер икән бу «кунак»? Мин арада иң бәләкәчемен, җитмәсә, юашмын.

Кайчан җитә әле миңа ул бәхетле чират? Исәпне шәп беләм — сигезенче атнада гына.

Адмирал Җәләлетдин әти класстан чыгып китү белән, кылый Гарибальди алга килеп басты:

— Әлегесенә шобага тотып маташмыйбыз. Монысы — разведка. Команданы үзем тәгаенлим. Дөресме?

— Дөрес, — диде кемдер ишетелер-ишетелмәс кенә.

— Дөрес шул! — дип раслады атаман. — Миша Куян — бер. Ул буйга бәләкәй булса да, математикадан шәп белә. Урал Урманов — ике. Җыр җырларга туры килсә — моңы бар. Кунак җыр-биюсез булмый ул. Хәнҗәр танау Хачим Пшимах — өч. Бөек чиркәс халкының атаклы улы. Элгәшүе чамалы булса да, биюе дәртле. Дүртенчесен үзегез сайлагыз.

— Мөхтәр Ишбулдин Гарибальди — генералиссмус! — дип бу юлы икеләнүсез кычкырды Изя. Бер уңайдан яңа кушамат да туды.

— Каршылыгым юк, — диде яңа «генералиссмус». Ризамын. Хәзер барысын да дөресләп, кул күтәрәбез.

Кул күтәрдек. Эше дә бетте.

***

Ул безне башта трамвай белән алып барды. Ниндидер тукталышта төштек тә җәяү киттек. Почмактагы язуны укыйм: Чернышевский урамы. Ике катлы бер биек таш йортның капкасына кердек. Мөгаен, Җәләлетдин абыйның «иркен түре» шушы биек өйнең икенче катындадыр. Юк, булмады. Ары киттек. Иң төптәге тәбәшәк кирпеч бинага якынлаштык.

— Минем сараем шушы инде, — диде ул. — Элек монда бер бай сатучының икмәк салу урыны, ягъни пекарнясы булган. Хәзер без торабыз.

Тышкы ишектән кергәч, ике баскыч түбән төштек. Адмирал әти шунда ук эчкесен ачты да тавыш бирде:

— Рөхсәтме, Кәлби-ну-ур?!

Эчтән ягымлы тавыш яңгырады:

— Рәхим итегез, кунаклар!

Була бит шундый тавышлар. Сүз сөйләве дә җыр җырлаган шикелле.

Без ифрат зур сәер бүлмәгә килеп кердек. Узарга кыймыйрак торганда, Кәлбинур апаның тавышы дәрт бирде.

— Узыгыз, уз, тартынмагыз, — дип җырлады ул. Шунда гына Мөхтәр Гарибальди, кәпәчен салып, исәнләште:

— Саумысыз, Кәлбинур апа!

Без дә шулай иттек. Ул арада безнең чама ике малай килеп олыларча кул сузды. Икесе дә бертөсле. Күрештек.

— Игезәкләребез, Җиһангир белән Зөфәр, — дип таныштырды әниләре.

Стена буендагы озын эскәмиягә тезелешеп утырдык. Кызык йорт бу. Кешегә сиздерми генә аны карап чыгам. Галәмәт дәү бүлмәнең яртысын диярлек киң авызлы тәбәшәк мич алган. Уртада юан аяклы калын өстәл. Аргы почмакта матур корама юрган ябылган зур тимер караватъ. Юрган өстенә кабартылган әллә ничә аллыгөлле мендәр катлы-катлы өелгән. Кәбәркәдә киң генә сәке. Ул чүпрәк палас белән капланган. Түр стенаның ике җирендә башлары кызыллы-зәңгәрле дебет белән чигелгән сөлгеләр эленеп тора (Боголюбовкадагы картәниемнең дә шушындый тастымаллары бар, аны бездә «рушник» диләр). Өч тәрәзә төбендә дә яссы балчык чүлмәкләрдә гөлләр кызыл чәчкә атып утыра. Дүртенчесендә эре билчәнгә охшаган чүп үләне савыт биләп утыра. Нәрсәгә кирәк икән инде ансы? (Картәниемнең дә шундый гөлләре бар. Билчәне генә юк...) Эленмәле киштәгә байтак кына китаплар тезелгән. Шундый ук киштәгә минем картәниемнең иконалары куелган. Кайсычак шунда сукыр лапма да яна. Гел яндырыр иде дә, керосин кайдан җиткермәк кирәк.

«Мә, кодагый, сиңа хәзергә бер төймә» дигәндәй, искәрмәстән Хачим телгә килде:

— Бездә, Кавказда да, хатын-кыз кул эшенә бик оста. — Күрәсең, минем ише, ул да үзенекен уйлап утыргандыр.

— Бездә андый осталык юктыр ул. Кавказ — Кавказ инде. Юкны бар итеп кулдан килгәнчә маташам шунда, кичләрен абыегыз кәрзинкә үргәндә.

— Мин сиңа әйтмәдем бугай, Кәлбинур, алар бит мине абый дип түгел, «Җәләлетдин әти» дип атадылар. Безнең өч улыбыз бар иде, хәзер утыз биш булды, — дип хәбәр салды адмирал.

— Үтә әй-бә-әт, — дип моң сузды хатыны. Хачимнан калмыйм дипме, Урал да мактанып алды:

— Минем дәү әниемнең үлемтек сандыгы бар. Шунда чиккән сөлге, кушъяулык, ашъяулык, мондый яулык, кашмау кебек нәрсәләр тулып ята иде. Үзе исән булмагач, хәзер бар микән, белмим...

— Бардыр, бардыр, — дип юатты Кәлбинур апа. Мин, сүз әйтмәсәм дә, уйлап утырдым. Ә Гарибальди бөтенләй эндәшмәде. Үзе башлаган сүз булмаса, кешенекенә ияреп бармый ул.

Алай-болай сөйләшкән арада Җәләлетдин әти өстәлгә сары клеёнка ашъяулык җәйде, аның өстенә кеше башына зур гына икешәр телем икмәк, берәр тозлы кыяр, җыеныбызга бер тустакта көнбагыш мае китереп куйды.

— Самаварым да кайнады, бәрәңгем дә пеште! — дип сайрады Кәлбинур апа. — Бәрәңгем симез, кисәр карасы юк. Җитмәсә, әнә көнбагыш маена манарсыз. Я, кул чайкагыз да утырыгыз, алайса.

Бер якка озын эскәмияне, җитмәгәненә утыргычлар куеп, өстәлне сырып алдык. Апа киң авызлы мич эченнән, ухват белән эләктереп, галәмәт зур кара чуен сөйрәп чыгарды. Аннан бөркелеп бәрәңге исе килде. Чуен эчендәгене апа зур табакка аударды. Буланып торган бәрәңге өеме безнең алга килеп басты. Әйтерсең, ул пыскып торган янар тау.

— Җитешегез, — дип кыстады хуҗа.

Беренче булып бәрәңгегә Зөфәр кул сузды. Ни арада күреп, әтисе аның сузылган кулына чак кына сугып алды:

— Моннан ары ятимнәрдән алда ризыкка үреләсе булма. Җиһангир, ишетсен колагың, синә да фәһем бу, — диде ул, ачуланмый гына. — Үрел, Миша, син беренче үрел. Үрелегез. Әрчеп тормасагыз да ярый. Таза юылган.

Икмәк, кыяр, бәрәңге... Өстәвенә — май. Теләсәң күпме ман.

Мандык, кыстатмадык. Ашап туйгысыз. Икмәк белән кыярын калдыруны килештермәдек, ә бәрәңгенең төбенә үк төшмәдек.

Тәүдә Мөхтәр туктады. Дөрес эшләде. Азагына хәтле ябырылмадык. Бүселгәнче бер ашаудан барыбер мәңге тук булып булмый. Намус саклау да кирәк.

— Бә-әй, нишләп туктадыгыз? — дип сузды Кәлбинур апа. — Шөкер, алай өзек үк тормыйбыз. Абыегызның... этиегезнең кулы һөнәрле.

— Рәхмәт, апа, нык хушландык, — диде Гарибальди. Ничегрәк әйтә, «нык хушландык», ди. Дөнья күргән шул. Колониядә бөтенләй төзәлеп, юкка гына безгә килмәгән ул.

Чәй эчкәндә дүртәвебезгә чын чынаяк, үзләренә таш купылар куйдылар. Без тегендә калай крүшкәләрдән салкын чәй генә эчәбез. Ничек әйбәт икән ул эссе чәй! Кәгазьсез кәнфит тә тешләп җибәрсәң, тел рәхәтләнеп китә.

— Чынаякларымны кунаклар өчен генә тотам, — дип аңлатты апа.

Сый-хөрмәттән соң игезәкләр уен күтәрделәр. Иң кызыгы «кем сукты» булды. Артка куелган кулына кем сукканны белә алмаган кеше отыла. Отылган кеше шунда ук һөнәр күрсәтә. Отылмаган кеше калмады, һөнәрләр төрле булды. Урал Урманов, сизгәнсездер инде, «һайт, кара юрга!»ны җырлады. Гарибальди әтәч булып кычкырды, кәҗә булып бакырды. Хачим «асса» дип, үзе сызгырып, үзе биеде. Җиһангир кызык шигырь укыды. Зөфәр сул кулының имән бармагын сындырып, күз буды. Мин, бүтән нәрсә белмәгәч, күземне йомып, колагымны уйнаттым. Битем ябык булгач, минем колакларым үзләре биеп тора. Мин аларны парлап та, ялгыз да биеттем. Егылып көлделәр. Бигрәк тә Кәлбинур апа белән Җәләлетдин әти яшь койганчы хахылдадылар. Тансыклары кансын дип, озак биеттем.

Аннан соң Җиһангир үзе төшергән сурәтләрне күрсәтте. Чос төшерә икән. Издан кайтыш түгел. Китәргә җыенгач, Җәләлетдин әти безне чоланга алып чыкты. Анда эреле-ваклы матур кәрзинкәләр тезелгән. Бер җирдә тал чыбыклары өелгән.

— Менә, егетләр, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, диләр. Рас ул. Кичләрен мин үрәм, шимбә көн апагыз аларны базарга чыгара. Чыбыкны Дим тамагыннан улларым ташый. Ярый. Бу авыр заманда иш янына куш. Язга чыккач, таллыкка алып барып, сезне дә өйрәтермен, һөнәрнең зуры, бәләкәе юк.

Миңа кыен булып китте. Адмирал башы белән шушы кеше кәрзинкә үреп утырсын инде. (Боголюбовкада аны бөкре Санька гына эшли.) Ә аның матур матрос формасы чалбары-ние белән өйдә эленеп тора. Шунда ук идәндә бер пар кара ботинка ялтырый.

Түгәрәк йөзле, куе кара кашлы, зифа гәүдәле Кәлбинур апа һәрберебезне аркабыздан сөеп озатты. «Әни куллары дигән нәрсә шушы буладыр инде», — дип уйладым мин.

— Онытмагыз, монда сезнең ике туганыгыз бар, — дип көйләп калды. Җәләлетдин әти безне детдом капкасына хәтле озатты да, керми, китеп барды. Бүлмәгә килеп кергәч тә, малайлар ябырылды.

— Ничек булды?

— Нәрсә эшләдегез?

— Нәрсә ашаттылар?

Гарибальди җавапны кыска тотты:

— Барырсыз, күрерсез, белерсез. — Үзенең танау канатлары сикерә. Кәефе шәп чакта шулай була.

Ике-өч көн үтте. Тәрбиячебезнең хәтәр калын кара мыегына иш килмәгән соры костюмына да күнектек. Ә менә сугыш хәлләре хакында, ул күрсәткән батырлыклар турында сорашырга базнат итмибез. «Батырлык өчен» медален бушка гына бирмиләр аны. Батырлык күрсәткән өчен бирәләр. Теңкәсенә тими торабыз. Җае бер чыгар әле. Шулай да теге кичтә, дәресләрне әзерләп бетергәч, хәнҗәр танау Хачим сорый салды:

— Диңгездә үлгән морякларны кайда күмәләр, Җәләлетдин әти?

— Ярда, җирдә, — диде ул.

Бер данлыклы адмиралны ничек җирләүләре турында сөйләде. Пушка лафетына күпертеп чәчкә өйгәннәр, чәчкә өеменә аның табутын куйганнар, табут өстенә бөтен орденнарын тезгәннәр. Лафетка дүрт кара айгыр җиккәннәр. Алда оркестр кайгы маршын уйнап бара, артта, автоматларын күкрәкләренә кысып, матрослар туп-туры басып килә. Диңгездәге хәрби кораблар гөп-гөп салют бирә... Шулай хушлашканнар диңгез батыры белән.

Бу турыда ул матур итеп, дәртле итеп, хәсрәтле итеп сөйләде.

— Сез дә диңгез батыры инде. Сез дә адмирал... адмирал ише... — дип тотлыга-тотлыга ычкындыра язды Айтимер, ярый, тыелып калды. — Сезне дә, картаеп үлгәч, лафетка салырлар әле, чәчкәләргә күмеп...

— Соңгы юлны туп арбаларында ятып узу теләсә кемгә эләкми ул. Ярый. Хәзергә яшик әле, улларым.

Барыбызга да ямансу булып китте.

— Бүген кичке аштан соң курай тартып күрсәтермен. Теләүчеләр булса, бергәләп өйрәнербез.

Курай булмады. Директор бөтен детдомны йорт тирәсен җыештырырга чыгарды. Комиссия дигән нindидер куркыныч бернәрсә килә икән. Барысы да кан калтырады. Ә ул килмәде дә куйды. Килсә, күрер идек. Тагы бер атна узды. Шушы якшәмбедә дә шобагалары чыккан дүрт малай безнең арттан кунакта булып кайтты. Алары мактанып туя алмады. Мактанчык булмасалар да.

Өченче шимбәдә Җәләлетдин әти, нәкъ теге тәү көндәге шикелле, киенеп-ясанып килде. Түшендә — медале. Без нык куандык. Мөгаен, берәр әйбәт нәрсә булыр. Аның белән бергә класска бәйрәм килеп керде. Тик, нишләптер, елмаюы тонык. Бүтән чакта аның елмаюы ике мыек очыннан, нур булып, сулкылдап тама иде.

— Егетләр, улларым! — диде ул. Калын тавышы калтырабрак куйды. Безнең кечкенә йөрәкләребез нindидер бәла сизеп, жу итеп китте. — Улларым! — дип кабатлады. Тавышы урынына утыра төште. — Дөнья без уйлаганча гына бармый. Миңа иртәгә иртән үк авылга китәргә кирәк. Бөтенләйгә. Бөтен өй эчебез белән. Сәбәбе бик зур. Мин сезнең белән хушлашырга килдем. Бергә яшәргә насыйп булмады. Барыгызны да кунакка чакырган идем, күбегезне ымсындырып калдырдым. Гафу итегез.

Шулай дип сөйләде Җәләлетдин әти. Мин чыдый алмадым, танау тарта башладым.

— Миша! Балалар! Морякларча, ирләрчә, елашмый гына аерылышыйк. Моряклар еламый.

Без барыбыз да, гөр килеп, парталар артыннан чыктык. Гулливерга ябырылган лилипутлар сыман, аны сырып алдык, бушлатына, чалбарына, бескозырка тасмаларына кагылып иркәләндек. Мин, ятып, аның агач аягын кочакладым. Кулы белән ул беребезгә дә кагылмады. Басып тик торды. Безне тыймады да, кумады да.

— Ярый! Җитте! — Тавышында тәү тапкыр боерык ишетелде. — Зур булып үсегез. Кеше булып үсегез. Елан чакканда да еламаслык чыдам булыгыз. Еланнар бар. Еланнар чага ул... Кире урыннарыгызга утырыгыз. Тәртип кирәк!

Без парталар артына барып бастык.

— Менә шулай. Хәзер бөтенләйгә хушыгыз. Озата чыкмагыз. Мин киттем.

Ул, капыл борылып, чыгып китте. Класс шомга чумды. Коридорда аның агач аягының тукылдавы озак ишетелде: тук, тук, тук...

Гомер буе шул тавыш минем колагымнан китмәде: тук... тук... тук...

***

Әңгәмәнең әле азагы бар. Утыз елдан ашу вакыт үтеп китте. Мин шәһәрнең бер районында совет рәисе булып эшли идем инде. Заводларга, оешмаларга йөрүне үзем өчен бер кагыйдә итеп куйдым. Җитәкчеләргә әйтеп-нитеп тормыйм, барам да керәм. Документ сораган җирдә документ күрсәтәм. Беркөн төштән соң районның иң читендәге фабрикага киттем. Эшчеләрдән шикаятьләр бар иде. Әйләнмәле тимер киртә тышында «Пропуски» дип язылган будканың кечкенә генә тәрәзәсенә танытмамны суздым. Танытмамны җыерчыклы зур кул алды. Озак кайтармады. Мин, аптырап, тәрәзәгә төбәлдем. Аннан зур ак мыеклы, киң маңгайлы, ап-ак чәчле баш сузылды. Чак кына карлыга төшкән тавыш гөрселдәп ишетелде:

— Миша! Миша Куянов! Синме?

— Мин! Мин, Җәләлетдин әти!

Чал баһадир, аксый-аксый, будкасыннан килеп чыкты. Өненнән чыккан аюмыни! Өстендә иске, әмма таза, пөхтә матрос формасы.

— Улым!

Ул мине кочаклап алды. Ә мин ятим баланың гомерлек хыялына ирештем: сакаллы сабый булгач, ата күкрәгенә сыендым.

— Әти, әти... — дидем.

Әлегә башка сүз дә табып булмый. Башыма бер уй килде дә, сорадым:

— Эшең кайчан бетә?

— Биштә. Аннан соң профсоюз җыелышы. Шуңа бит менә ыспайланып килдем. — Ул медален сыйпап куйды.

Кыскасы, бишкә хәтле мин үз эшләрем белән булдым да, аннан соң, завком председателеннән рөхсәт сорап, Җәләлетдин әтине өемә алып киттем.

Машинага утыргач:

— Кара бушлатта бик күп йөрдем, кара машинага утырганым юк иде әле, — дип көлде ул. Әллә куанып, әллә хәйләләп.

Юлда барганда ул минем колакны сыйпап алды:

— Һаман да биетәсеңме?

— Хәзер сүлпән кыймылдыйлар, яңакларны ит-май басты...

— Сине тәү күргәндә, бу сабыйның сөякләре таралып төшмәсә ярар иде, дип курыккан идем. Хәзер түл җыйгансың... — Ул аркамнан сөеп куйды.

— Бар шул. Җәяү аз йөреләә.

— Теге чакта сине шулай сөясем килгән иде, тик, бүтәннәрдән аерырга ярамас, дип тыелдым. Кеше алдында мин аерып сөйсәм, бүтәннәр азактан кагар иде. Көнчелек аркасында...

Өйдә ул артык ашыкмады да, сүлпәнләмәде дә. Җайлап кына чәй эчтек. Хәмердән баш тартты: «Минем яшьтәге кешегә килешә торган эш түгел», — диде. Хәлләрен сораштым. Кәлбинур апа былтыр вафат булган икән. Бик кайгыра бугай, сиздермәскә генә тырыша. Мөгаен, ул үз хәсрәтен кешегә аудармый, үзе генә

күтәрә торган заттандыр. Бездән соң туган кызында тора икән. Өч малае төрлесе төрле җирдә дөнья көтә, ди.

— Ни мохтаҗың бар, әти, әйт? Кулдан килгән ярдәмне күрсәтермен. Зур булмасам да, власть кешесемен.

— Юк, улым, юк. Рәхмәт. Бер мохтаҗлыгым да юк. Дөньям имин. Шушы яшемдә читтән ярдәм көтәрлек булгач, нәрсәгә үстердек соң ул дүрт баланы? Шөкер, балаларыбыз иманлы, итагатьле. Алар имансыз булсалар, син түгел, Брежнев та ярдәм итә алмас иде миңа.

— Җәләлетдин әти, мин дә бит чит түгел. Оланнарыңның берсе. Шулай булгач…

— Сиңа бер генә үтенечем бар. Җеназама кил. Ярый.

— Әле аңа хәтле…

— Килә дә җитә ул. Берәүне дә читләтеп үтми. Әнә, Кәлбинур түтәң дүрт яшькә кече иде дә, китеп барды. Рухына фәрештә мөһере сугылган дан бичә иде. Кайсычак миннән: «Хатының акыллы идеме? Хатының чибәр идеме? Хатының уңган идеме?» — дип сорыйлар. Ә мин шулай җавап бирәм: «Минем хатыным Кәлбинур иде»,— дим.

Минем күз алдыма түгәрәк йөзле, куе кара кашлы сылу хатын килеп баса. Хәтта мин аның моңлы тавышын да ишетәм сыман.

Ә сорар соравым хәтеремне бимазалый, тел очымнан китми:

— Теге вакыт, Җәләлетдин әти, капыл гына китеп бардыгыз. Авылыгызда бәла-каза булдымы әллә?

— Булмады. Мин бер җиргә дә китмәдем. Утыз өченче ел инде син күргән будканы каравыллыйм.

— Ничек инде?

— Шулай. Сәбәбен яшердем. Ирексездән сез сабыйларны алдадым.

— Ни өчен әйтмәдегез?

— Белсәгез, сез, утыз ике сугыш чукмары, дөнья кыйратырсыз, дип курыктым. Сез бит миңа бик тиз ияләшеп алдыгыз. Мин дә сезгә…

Чыдамлыгым чигенә җиткәнен ул да сизде, әлбәттә. Тамагын кырып куйды:

— Алайса, сөйлим. Мине сезгә РОНО җибәрде. Күрше йортта торучы бик әйбәт кеше эшли иде анда. «Син бала җанлысың, бар, эшлә шунда», — диде. «Белемем аз» дигәнгә, «акылың бар», дип майлады. Кулга кәгазь тоттырды. Директор ике атна сынау шарты белән алды. Миңа өстән аска карый алмавына ул тәүдә үк кимсенде, ахрысы. Шулай сиздем. Хәтерлисеңдер, ул чибек кенә бер кәрлә иде.

— Ислим. «Чикерткә» кушаматлы. Хәзер дә исән.

— Ике атна узгач, ул чакырып кертте. Утырырга кушты. Мин утырдым, ул басты. Тигезләштек. «Гаепләштән булмасын, матрос иптәш, сынау чоры үтте. Сез безгә бөтенләй килешмисез, ягъни яраксыз булып чыктыгыз. Ни өченме? Төшендерәм. Сез педагогиканы, тәрбия эшен, детдомның үзенчәлекләрен, нечкәлекләрен белмисез, детдом балаларының психологиясен, әйе, психологиясен бөтенләй аңламыйсыз. Ләм-мим… Нигә сез аларны өегезгә йөртеп күңелләрен аздырасыз, чыгырыннан чыгарасыз, туган детдомнарыннан биздерәсез? Анда нинди аерым тәрбия бирәсез тагы? Сез урнашкан гомум тәртипне какшатасыз. Бу минем шәхси фикерем генә түгел, педсовет фикере! Әйе, әнә тәүге көндә үк рөхсәтсез-нисез ярты көн урманга китеп олагуыгызны ничек аңларга?! Мин бит аларны урманга түгел, урамга чыгудан да тыйдым. Ә сез башбаштаклык күрсәттегез. Әмеремне үтәмәдегез. Но! (Ул имән бармагын өскә чөйде.) Мәсьәләнең төп үзәге бу түгел. Үрдә саналган хаталарыгызны выговор биреп тә төзәтеп булыр иде. Мәсьәләнең төп үзәге шунда — белемегез түбән. Түбән генә түгел, юк. Белемегез юк. Монысын инде, биш

выговорны берьюлы бирсәң дә, төзәтеп булмый...» Әле килеп иң дөресен әйтте. Бөтен белемемне мин авылда өч кышта алып бетергән идем. Исеңдәдер, мин бит сезнең дәфтәрләрне кулга тотмадым диярлек. Чөнки мин сез белгәнне белми идем, әмма күзләрегезгә карап төсмерләдем: сез мине бер тапкыр да алдамадыгыз... Ә директор тагы шулай диде икән: «Гариза язып тормагыз, болай да бушатам. Ике атналык эш хакы алып китегез. Гаепләштән булмасын, моряк иптәш».

Мин урынымнан тордым, ул түбәндә торып калды.

— Ярый,—дидем тыныч кына. Ул миңа бармаклары тырпайган тавык тәпие зурлыгы кулын сузды. Күрмәмешкә салыштым, алмадым, җирәндем. Шушы кул бит миннән утыз ике хәйләсез җан иясен тартып алды.

Җәләлетдин Кулыевның сөйләгәне минем өчен гаепләү хөкеме кебек ишетелде. Кемгә, нәрсәгә бу хөкем? Мөгаен, ахмаклык белән бәгырьсезлеккәдер.

— Нәрсә бөтенләй таралып төштең, Миша Куянов — ир арысланы? Булмаса, колакларыңны бер биетеп ал.

— Юк, әти, булдыра алмыйм, гафу ит. Моннан ары алар бервакытта да биемәсләр инде. Бүген мин, балалыктан чыгып, ирләр корына уздым, акылга утырдым.

— Әйттең тагы. Үзең хәзер балалар атасы. Акылым чамалы булса, шундый урынга куймаслар иде, куйсалар да, озак тотмаслар иде.

— Мин бүтән акыл турында әйтәм. Синеке ише сабыр акыл турында әйтәм.

Үз чамасын белеп, кунагым кузгалырга рөхсәт сорады. Мин аны фатирына илтеп куйдым. Машинага кергәч, ул тагы шаяртып алды:

— Мин сине трамвайда җилдергән идем, син дә бурычлы булып калмадың, кайтардың болай булгач.

Бүтәнчә ул өемә килмәде. Телефон аша чакырганда, ниндидер сәбәпләре чыгып торды. Эшемә ике-өч тапкыр сугылып китте. Анда да көн азагында гына килә дә алгы бүлмәдә көтеп утыра. Секретарь керергә кушса, әйтә икән:

— Ярый, ярый, минем йомышым юк. Йомышы барлар керсен. Мин болай гына, хәл белергә генә килдем. Бушагач, үзе чыгар әле.

Күрешкәч тә, озак тормый, китәргә ашыга.

— Сагындым, менә үзеңне күргәч, күңелем тынычланды. Мазаңны күп алмыйм. Бүген болай да йончу күренәсең. Кайт, ял ит.

Мин сорамый чыдый алмыйм:

— Берәр төрле хәстәр-мәшәкатең юкмы, әти?

— Шөкер, дөньям түгәл, фатирым иркен. Дүрт җанга ике бүлмә. Җылы суы агып тора. Тамагым тук, өстем бөтен. Хезмәтем бара. Анда да хөрмәт итәләр. Өстәвенә телевизорыбыз бар.

— Агач аягың урынына, бәлки, протез эшләтергәдер?

— Эшләткән идем, чыдамады. Монысы, ичмасам, гомерлек. Нык, ышанычлы басыла.

Әйткәндәй, берничә ел әүвәл мин Чернышевский урамындагы теге тәбәшәк йортка күз салып киткән идем. Анда кеше тормый иде. Ниндидер склад ясаганнар. Күңелгә шыксыз булып китте.

Һәр килгәндә мин аны шофёрдан гына озаттырмадым, үзем илтеп куйдым, сизгән кебек...

Август азаклары иде бугай. Сигез тулуга эшкә килсәм, алгы бүлмәдә Җәләлетдин әти утыра. Ул баштанаяк матрос формасында. Түшендә — наградалары. Эчкә уздык. Күңелдә ниндидер шик яралды.

— Чәй эчәбезме? Гөлнур хәзер әзерләп кертер, — дигән булдым.

— Юк. Эчеп кенә килдем. Син курыкма, берни дә булмады.

— Мин курыкмыйм да, — дидем. Үземнең йөрәк урыныннан купты.

— Төш юрый беләсеңме?

— Бик юраганым юк та... сөйлә. Бергәләп юрарбыз.

— Бер төш күрдем. Ярый. Башы дан, тамаша иде. Имеш, ап-ак лафетка күпертеп ак чәчкә өйгәннәр, чәчкә өстенә ак табут салганнар, табут эчендә, матрос формасы киеп, мин ятам. Лафетка дүрт ап-ак ат җигелгән. Юлның ике ягында халык яр кебек. Барысы да шат, барысы да бәйрәмчә киенгән. Тик нигәдер музыка уйнамый. Ныгытып колак салам. Юк. Уйнамый. Табут артыннан тик бер генә кеше бара. Ул — син. Бәләкәй чагың. Күбәләк кебек кенәсең. Һәммәсе куана, бер син үксеп-үксеп елыйсың. Үзең яланаяксың. Төшнең азагы шулай күңелсез булды. Менә, эчем кырып, килеп чыктым. Ярый. Имин-аман икәнсең. Дөнья бит ул. Ниләр генә булмый. — Ул көрсенеп куйды. — Ак атлар белән ак табут ул өннән төшкә килеп кергән нәрсә. Шушы арада гына бер китап укыган идем. Анда язылган: кытайлар мәрхүмне ак табутта, ак атлар җигеп, ахирәткә озаталар. Чөнки кеше якты дөньядан да шәбрәк дөньяга китә. Бу зур шатлык санала. Ярый. Монысы шулай. Ә ни өчен син бер ялгызың артта елап барасың? Шуңа пошынып килдем.

— Ни дип юрыйк икән соң? Төш ул барысын да тискәре итеп күрсәтә, ди, бит.

— Ничек тискәре?

— Әйтик, төшеңдә тизәккә батсаң, өнеңдә акча керә.

— Монда бит мәсьәлә тирәнрәк, улым.

— Монда да гап-гади. Төшеңдә син үлгәнсең, димәк, әле озак яшәячәксең. Төшеңдә мин елаганмын икән, димәк, өнемдә мине шатлык көтә.

— Кара әле. Бик әйбәт юрадың лабаса. Ярый. Тынычландым. Китим инде.

Мин аны алгы бүлмәгә озатып чыктым. Шофёрга кунакны өенә илтеп куярга куштым.

— Син, Михаил, хафаланма. Эшеңне кара. Мин чак кына утырып торам әле. — Ул йомшак диванга арка сөяп утырды.

Кабул итүне көткән кешеләр бар иде. Мин аларны чакырып керттем. Ун минут үтмәгәндер, секретарь Гөлнур төсе качып, йөгереп керде.

— Тизрәк! Тизрәк! Җәләлетдин әтигә әллә нәрсә булды...

Атылып чыктым. Башын тоттым, беләген капшадым. Җәләлетдин әти җан биргән иде инде.

...Безнең районда хәрби часть тора иде. Пушкалары да бар. Командир белән сөйләшеп, без мәңгелек ярына чыгарылган рядовой матрос Җәләлетдин Гыйльметдин улы Кулыевны хәрби ритуал буенча олылап, соңгы юлга озаттык. Пушка лафетына күп итеп чәчкәләр өйдек, чәчкә өстенә табутны куйдык, табут өстенә батырның бескозыркасы белән наградаларын салдык. Лафетка пар кара ат җиктек. Алдан оркестр уйнап барды, арттан солдатлар, автоматларын күкрәкләренә кысып, дөп-дөп басып озатты. Ул көнне ярты фабрика эшләмәде. Җеназада булды. Мәрхүмне туфракка тапшырганда, автоматлардан салют бирделәр.

Балалары, оныклары гына түгел, күп кешеләр бөгелеп елады. Мин озак тыела алмый үкседем. Элек түгелми калган күз яшьләремне дә түктем. «Елан чакса да елама», — дигән иде дә бит. Бу әрнү елан чагу ише генәмени?..

***

Михаил Куяновның сөйләгәннәрен кәгазьгә төшерүемнең төп сәбәбе — Җәләлетдин Кулыевның авызыннан чыккан бер кәлимә сүз булды: «Моннан ары ятимнәрдән алда ризыкка үреләсе булма!» Үземнән янә шуны өстәр идем:

— Ятимнәр ризыгына бервакытта да кул сузасы булма... ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Кара халык шунда кол булыр аңар.
Шундый бий теләккә ирешер, уңар.

Кырыс йөз, эре сүз, горурлы булу
Кешене биздерер, ара бозылыр.

Түбәнлек, шашкынлык, җиңел кыланыш —
Кара халык холкы, ташла син аны.

Кара халыкчалык бийгә тыела,
Карача кыланган бий арзан була.

Каралык ул коллык, биләр ак була.
Кара һәм ак булу тәңредән килә.

Кямил бий булыймчы, дисәң, билгеле,
Бий сыйфатын сакла, и, асыл егет!

Заты бий булса, ә холкы — карача,
«Карадан да түбән ул», — дип карала.

Бийнең йөзе матур, сафчырае ак,
Буе урта булса, булыр данлырак.

Бик озын буйлыны китап мактамый,
Тәбәнәк булу да абруй өстәми.

Шулай икән, бийгә урта буй кирәк:
Урта буйлы кеше була иплерәк.

Ни ди, ишет, күпне сынамыш кеше,
Башыннан кичермеш, яшәмеш яшен:

«Буе кыска — кызу, ачучан булыр,
Низаг, җәнҗал, бәхәс ачучан булыр».

Буе урта булса, холкы да ипле.
Эшеңне уртача тот, и белеклем.

Бийнең йөзен күреп кеше сөенсен,
Иле-халкы «һай, шәп биебез», — дисен.

Дошманга карата аяусыз булсын,
Ә халык күзендә якын, үз булсын.

Бий эчмәсен хәмер, фәсәт[1] кылмасын:
Шул җуяр ил ямен, котсызлык башы.

Сөчеккә сөченсә[2], ил тоткан бәкләр,
Ил-көннең язмышы билгеле, мәгәр.

**«Буе кыска — кызу, ачучан булыр,
Низаг, җәнҗал, бәхәс ачучан булыр».**

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.
[1] Фәсәт (фискы-фәсәт) — бозыклык.
[2] Сөчеккә сөченү — эчкечелек белән мавыгу (борынгы тәгъбирне саклыйбыз).

Уенга мавыкса дәүләт тәргә,
Илен боза, үзе була теләнче.

Ычкындырса дәүләт башы форсатны,
Кош булып очса да, куып тотмастыр.

Ни ди, ишет, әнә белек бирүче —
Наданны хәтәрдән тыеп торучы:

«Хәмер эчмә, булма исреклек колы,
Эчтеңме — ачыла ярлылык юлы.

Эчкече булдыңмы — малың җил булыр!
Ханы-бийе эчкән илгә ни булыр?

Хәмер — дошман, җуя алтын-көмешне,
Китереп чыгара җәнҗал-сугышны,

Исергән бий — тилбә, хан — мондыз[3] булыр,
Исерекнең эше кайчан төз булыр».

Ни ди аек кеше — юньле, акыллы
(Сүзен от, эшкә тот, и буза колы):

«Азмы эшлисе эш эшләнмәс, эчсәң?
Азмы килеп чыгар кирәкмәс эшләр?

Эчеп, гыйш-гашрәткә бирелсә бийләр,
Ничек ил-көн өчен акылы җитәр?

Юньсезлек өстенә, ничәмә-ничә
Эш кала әгәр бий исереп йөрсә.

Бола булган илдән кот кача тиз үк,
Болачы һәрвакыт йөрер ил бозып.

Бәхет-кот пакь нәрсә, килә пакьлеккә,
Дәүләтчелек ота сөзген-сафлыктан.

Бийе эчкече һәм бер утын[4] икән,
Аның илаты[5] да шул юлдан китәр.

Илнең каралыгын бийләр төзәтә;
Бий дә юньсез булса, өмет юк хәтта.

«Хәмер эчмә, булма исреклек колы,
Эчтеңме – ачыла ярлылык юлы.

Арусыз әйберне юалар суда.
Су пычранса, суның үзен ни юар?

Кеше хасталанса, табиб им бирер,
Табиб хастасына имне кем бирер?

Бийләр була тугры, үрнәк холыклы,
Ил бийдән өйрәнә төз юл-юрыкны.

Менә әйтелгәнгә исбат бу сүздер
(Игътибар итегез, мәгънәсе төздер):

«Биләр сайласалар ниндирәк юллар,
Аларның эзеннән баралар коллар».

Бийе иге булса, юрыгы[6] туры,
Аннан да игерәк буладыр колы.
Кирәксезгә көяз, күңеле горур,
Үзен дә, илен дә юлдан яздырыр.

Олуг бийләр иге, тыйнаклы булса,
Кече тотып күңлен, олы эш кыла.

Ишет, әнә, ушлы затлар ни диләр
(Халыкка абруйлы, белдекле ирләр):

«Бийләр бик югары тотсалар күңлен,
Егылганда ныграк авыртыр, углым».

Көязләнеп күккә ашалмас кеше,
Тыйнак кына йөрсә, бозылмас эше.

Горур зат кешенең күңлен туңдыра,
Югарыга тыйнак булу мендерә.

Бийдә булсын йомшак һәм алчак күңел,
Югыйсә аңардан өмет аз, түңел[7].

«Бийләр сайласалар ниндирәк юллар,
Аларның эзеннән баралар коллар».

[3] Мондыз — «ярсулы, болганчык ташкын» (татар әдәби телендә дә бар).
[4] Утын — «ахмак, явыз надан» мәгънәсендә оригиналда еш очрый.
[5] Илат — халык.
[6] Юрык — юралышы, киләчәккә планнар.
[7] Түңелү — баш тарту, кул селтәп китү.

**Һиммәт белән бергә сәясәт кирәк,
Идарә итәргә зур сәләт кирәк.**

Бийләр ачык йөзле, мөлаем булсын,
Кешенең языгын кичерә белсен.

Шундый булса, ил-көн ышаныч баглар,
Кеше үз хезмәтен кызганмас аңар.

Илбашы бәкләрдә һиммәт бик кыйммәт,
Тик һиммәт өстенә әдәп тә кирәк.

Һиммәт әдәп белән йөрсә әгәр дә,
Уңыш-табыш бийгә килер тәгәрәп.

Һиммәт белән бергә сәясәт кирәк,
Идарә итәргә зур сәләт кирәк.

Бий илен төзәтер сәясәт белән,
Кара халык юньгә керә рәт белән.

Бу сүз дөреслеген бу бәйт таныклар
(Таныклык мәгънәне ачар, аныклар):

«Бийләрнең капкасын сәясәт бизәр,
Сәясәт илә бий дәүләтен төзер.
Исәрлеккә каршы сәясәт кирәк,
Болганган ил-көнне сәясәт сөзәр».

Ил ил булсын дисәң, нык булсын төбе.
Мөһим ике нәрсә, ике көрчеге[8]:

Берсе халаекка тәртип булдыру,
Икенчесе гаскәр-сү рәтен кору.

Халык гадел заңга сөенсен генә,
Ә гаскәр акчага тиенсен генә!

Бу ике төрне бий канәгать итсә,
Ил һәм бийнең күңле болганмас һич тә.

Каю бәк халыкка тынгы бирмичә,
Аны якламастан, тик талап йөрсә,

Утын өя үзенең тәмугына ул,
Дәүләтен дөрләтер тиздән җил-давыл.

Яугирләрен бийләр шатландырмаса,
Ир-атлар коралын кулга алмаслар.

Кылыч тоткан бийнең кулы югары,
Кылычсыз абруе бик тиз югалыр.

Һәр илнең сакчысы кылыч һәм балта,
Илгә кылычлы бий баш була ала.

Ни ди бар җиһанны кулда тотучы,
Җәңне[9] кылыч-балта илә отучы:

«И илләр алучы һәм ил саклаучы!
Гафиллек ул агу, шуннан саклан син».

И углан, бар булса кылыч һәм балтаң,
Эшең алга барыр тыныч бер юлдан.

Кылыч кулда булса, дошман азынмас,
Кылыч кында булса, тыныч көн булмас.

Кылыч ияләрен, илбик, шат кылсаң,
Үзең шат булырсың, идарәң ансат».

Һәм Үгделмеш әйтте: «И котлы илбик,
Ил эшләре изге, бий аты биек.

Халыкка баш булу, бөек, авыр эш:
Һәрвакытта чыга мәшәкать, тәшвиш.

Көек, кайгысы күп, аз сөенечле,
Мактаучан күбрәк булыр сүгүче.

Кая карасаң да, болытлар бик күп:
Сөенеч яктысы биләми күкне.

Үз иткәннәр азрак, сөймәүче сансыз,
Рәхәт, тынычлыктан күбрәк гаугасы.
Күңелең һичкайчан канәгать булмый,
Һәм эчке хисләрдә моң күп, рәт булмый.

Күрсәң — һәр эштә бар бер хәвеф-хәтәр,
Эченә кергәндә кәефең китә.

**Кылыч кулда булса, дошман азынмас,
Кылыч кында булса, тыныч көн булмас.**

[8] Көрчеге – монда «терәк баганасы, бүкәне».
[9] Җәң — бер тапкыр сугышу, бәрелеш (шуннан — җәнҗал).

Ни ди, ишет, әнә ушлы кешеләр
(«Галим сүзе — энҗе тезе»[10] дә диләр):

«Муены кыл, башы гөмбәз илбикнең»,
Әгәр уйлый баксаң, бу сүз хикмәтле.

Бөтен ил хәстәре илбик башында,
Муены өзелә, ялгышса шунда.

Менә шулай тора илбик эшләре:
Ул йә тантаналы, йә фаҗигале.

Җитеш булсын дисәң тормышның-дөньяң,
Эшеңне калдырма, бул тырыш, уяу.

Күңел-тел азмасын, Аллага сыгын,
Ходай кушканына яшә буйсынып.

Ходайдан ни килсә, риза бул, риза,
Ризалык ул савап, Алла боерса.

Халыкка мәхәббәт сакласа күңел,
Игелеккә булсаң, игелек килер.

Халыкка файда кыл, китермә зыян,
Һәр эшен уңайла, сакла явыздан.

Шулай итсәң, якты дөнья синеке,
Гомер насыйп булса, күп сөенече.

Өметеңне киң тот, бетсә дә гомер,
Игелегең өчен Хак әҗер бирер.

Әйтер сүзләремне ишеттең, илбик,
Шулдыр илбикләргә кирәкле белек.

Бу белеккә ия булса кем дә кем,
Аны илгә бий дип куярга мөмкин.

Халык юлбашчысы шундый ир булыр —
Һәрбер гарызлыга[11] ул ярдәм кылыр.

Ни ди бер белекле инсан — бер зирәк
(Андыйның белеме ил өчен бизәк):

**Җитеш булсын дисәң тормышның-дөньяң,
Эшеңне калдырма, бул тырыш, уяу.**

**Халык юлбашчысы шундый ир булыр —
Һәрбер гарызлыга ул ярдәм кылыр.**

«Бий белекле булсын һәм дә намуслы
Йөрәкле, акыллы, үсешкән, ушлы,

Юмарт, тәрбияле, ачык зиһенле,
Рәхимле булсын һәм сакласын илне.

Ач күз булмасын һәм кайбер гаепне
Кичерерлек булсын — кешегә ипле».

Барча фазыйләттә ул булсын өстен,
Халыкка файдалы кануннар бирсен.

Каю ил илбиге шундыйрак икән,
Ул ил һәр ярадан төзәлеп китәр.

Илдә котлы, тыныч тормыш төзерләр,
Кызганыч ки, шундый илбик тиз үләр.

Менә шул хакта бар минем белгәнем,
Үзем аңлаганча сиңа сөйләдем».

ИЛБИКНЕҢ ТАГЫН БЕР СОРАВЫ

Илбик әйтте: «Дөрес, яхшы аңладым,
Шунсы мөһим — сүздә юлдан язмадың.

Тагын бер әйтәсе сүзем бар сиңа.
Шуны да ачыклап сөйләп бир миңа:

Шул фазыйләтләргә ирешсә илбик,
Вазифасын вәзир үтәсен ничек?

Күбәеп казнада алтын-көмешең,
Авыл-шәһәр артса, үрчесә кешең.

Төз вә дөрес булса канун, идарә,
Һәм канәгать икән гаскәри ир-ат.

Көрчекләр, фетнәләр булмаса һич тә,
Канәгать булса бар халык илбиктән.

Дәвамы бар ■

[10] Бу мәкаль татарда да бар; тезе — кыйммәтле муенса.
[11] Гарызлы — үтенеч белән килгән кеше.

ЙӨРӘК КАНЫ БЕЛӘН ЯЗЫЛГАН...

Әнвәр Шәрипов

Бүгенге буын укучысы шагыйрь Сириннең иҗаты һәм шәхесе белән бөтенләй диярлек таныш түгел. Әмма архивта сакланып калган материаллардан аның тормыш юлы һәм күпкырлы иҗаты безнең күз алдына түбәндәгечә килеп баса.

Шагыйрь Сирин (үз исеме Батыршин Мөхәммәтсәйрин Мөхәммәтхәниф улы) — әдәбиятка 1920 нче елларда килеп кергән, 1920-30 нчы елларның давыллы-дәһшәтле вакыйгаларын үзенең сизгер йөрәге аша үткәреп, революцион эчтәлекле әсәрләр тудырган күренекле әдип. 1930 нчы еллар совет җәмгыятендәге кычкырып торган гаделсезлекләрне, сабын куыгы кебек кабартылган «сыйнфый көрәшнең көчәюе» дигән фикернең гади бер кеше тормышына алып килгән фаҗигави хәлләрен әдәби образларда сурәтләп биргәне өчен гаепләнеп репрессияләнгәннән соң (1935-1940 елларда ул кеше ышанмаслык вәхшилек хөкем сөргән СИБЛАГ лагерьларында тоткын була), аның шигъри иҗаты киң катлам укучыларның да, әдәби тәнкыйтьчеләрнең дә күз уңыннан төшеп кала. Ә инде биш еллык срогын тутырып кайтканнан соң, Ватан сугышында катнашкан, соңыннан колхозда умартачы булып эшләгән һәм авырып яткан елларда иҗат ителгән әсәрләренең күпчелеге киң катлам укучылар хозурына барып җитә алмыйча, кульязмада гына калган. Нәтиҗәдә, Сирин иҗаты хәтта галимнәр тарафыннан хәзерләнгән алты томлык «Татар әдәбияты тарихы» җыентыкларында да тиешенчә бәяләнмичә кала килде.

Ютазы районының Кәрәкәшле авылында 1896 елның 14 декабрендә туган Сирин башта үз авылында, аннан атаклы Бәйрәкә мәдрәсәсендә белем ала. Аның архивында үз кулы белән түгел, башка кеше тарафыннан карандаш белән язылган «Автобиографиясе» саклана (ул аны 1960 нчы елларда, авырган көннәрендә кемгәдер әйтеп яздырган булса кирәк). Анда болай диелә: «Мин, Батыршин Сирин Мөхәммәтхәниф улы, 1896 елда Ютазы районы Кәрәкәшле авылында ярлы семьяда туганмын. Әтием һәм әнием Октябрь революциясенә кадәр үзләренең гомерләрендә байларга хезмәт иткәннәр. Әтием Мөхәммәтхәнифне аклар белән кызыллар сугышы елларында аклар бик каты кыйнаганнар, коммунистлар

ягында булганы өчен; шул кыйнаудан әтием үлеп киткән. Әнием Батыршина Хөсникамал 1921 елларда, колчаклар белән Кызыл Армия сугышы елларында, ачлыктан һәм күзән җыеру авыруы белән үлә.

Мин үзем (укырга-язарга) 1908-10 елларда Кәрәкәшле мәктәбендә Гали Гайсин хәлфәсенә йөреп өйрәндем. 1911 елдан 1915 елга тикле Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыдым. 1915-17 елларда Кәрәкәшле авылында укытучы булып эшләдем» (*Мәгъсум Латыйфуллинның «Сирин һәм аның поэзиясе» хезмәтендә (1961 ел) Сириннең бу елларда Кәрәкәшледә генә түгел, ә Кәрәкәшле, Әсәй, Азнакай авылларында укытучы булып эшләве әйтелә. — Ә.Ш.*).

1918 елда Сирин Бөгелмәдәге өчьеллык «Тәгълим-тәрбия курслары»на, ягъни укытучылар һәм тәрбиячеләр әзерләү семинариясенә укырга керә. Монда ул Һади Атласи, Фазыл Туйкин кебек күренекле шәхесләрдән белем ала. 1920 елда комсомолга керә. Бөгелмә өязендәге давыллы вакыйгаларның үзәгендә кайный. 1920 елда, корал тотып, сәнәкчеләр фетнәсен бастыруда катнаша. Шушы елларда аның революцион романтика белән сугарылган шигырьләре Бөгелмәдәге «Юксыл», Самарадагы «Яңа көч», Казандагы «Кызыл Шәрык» газеталарында басылып чыга.

1921 елда ул Казанга килеп, Татрабфакка укырга керә. Әдәби тормышта актив катнаша: Һ.Такташ, Г.Кутуй, Ә.Исхак, М.Җәлил, Х.Туфан кебек шагыйрьләр белән аралаша, үзе дә шигырьләр яза. Үзенең автобиографиясендә күрсәткәнчә, ул рабфакта 1923 елга кадәр укый. 1924-26 елларда Бөгелмәдәге «Сабанчы» газетасында секретарь булып эшли. 1927 елда Сирин яңадан Казанга килеп, Көнчыгыш педагогия институтының Тел һәм әдәбият бүлегендә укый башлый һәм анда 1930 елга кадәр белем ала. Институтны тәмамлагач, 1930 елда Казанның Мулланур Вахитов исемендәге мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләп тә ала.

Бу елларда аның иҗаты тагын да активлаша. Вакытлы матбугатта даими рәвештә шигырьләре басылып тора. 1929 елда аның балаларга атап язган «Көз», «Кыш», «Яз», «Җәй» дигән шигырьләре, рәсемнәр белән бизәлеп, аерым китапчыклар булып басылып чыга. Ә 1931 елда «Тамчылар» исемле чагыштырмача зур җыентыгы дөнья күрә. Шулай итеп, 1920-30 еллардагы күренекле татар шагыйрьләре төркеменә үзенчәлекле тавышлы, оригиналь шагыйрь Сирин исеме дә килеп кушыла.

1931-35 елларда Сирин Татарстан китап нәшриятында авыл хуҗалыгы бүлегендә редактор булып эшли. Ләкин бу елларда инде шагыйрь шәхесе өстендә кара болытлар куера башлый. Рафаэль Мостафин күрсәткәнчә, инде 1933 елдан алып, Сирин һәм Әсгать Айдар, Габдулла Ризванов, Ибраһим Кулиевлар өстеннән НКВД яшерен агентларының күзәтүе оештырыла («Мәдәни җомга», 1996 ел, 3 май саны). Булат Солтанбәков үзенең «Сереӊ ач, Сирин!» мәкаләсендә («Мәдәни җомга», 1995 ел, 21 июль саны) Сириннең Казанда Һади Атласов фатирында советка каршы язылган «Ана» поэмасын, «Анама», «Күтәрик бокалларны» дигән шигырьләрен, Сталинга багышланган эпиграммасын укыганлыгы һәм шушы факт буенча НКВД вәкилләренең тикшерү уздырулары турында яза. «1935 елның августында Казанда бер төркем әдәбият әһелләре кулга алына, — дип дәвам итә Б.Солтанбәков. — Алар Сирин, Әсгать Айдар, Г.Ризванов, И.Кулиевлар була, соңрак аларга тагын Хәкимов Исмәгыйль-Энгельс белән Якубов Әхмәтне өстиләр. Баштагы материаллар нигезендә, аларны советка каршы коткы таратуда, советка каршы әдәбият һәм порнографик әсәрләр язып, шуларны таратуда гаеплиләр. Гаепләүнең

соңгы өлеше ачыктан-ачык ясалма булганлыктан, соңыннан төшереп үк калдырыла.

Бу төркемдә, иң зур һәм иң абруйлы фигура буларак, төп гаеп Сирин өстенә ташлана. Шаһитларның берсе Сиринне Тукайның, Әмирхан, Исхакый һәм Дәрдмәнднең турыдан-туры варисы дип атый. Такташтан кала, барлык шагыйрьләр, Сирин белән чагыштырганда, барысы да икенче сортлы шагыйрьләр икән. Һәм бу, дип өстәгән әләкче, башкаларда көнчелек хисе һәм үч алу нияте уята» («Мәдәни җомга», 1995 ел, 21 июль).

1936 елның 31 гыйнварында Сирин белән Исмәгыйль Хәкимовны — бишәр елга, калган өчесен өчәр елга иректән мәхрүм итәләр. Сиринне СИБЛАГка озаталар. Һәм ул, инде алда әйтелгәнчә, кеше ышанмаслык авыр шартларда биш ел буе (1935-1940 еллар) тоткын булып яшәргә мәҗбүр ителә.

1941 елда Сирин, сөрген срогын тутырып, иреккә чыгарыла. Әмма сөргеннән ул тәмам бетеренеп, хәлсезләнеп, ябыгып кайткан. Аның киемнәре дә череп-теткәләнеп, сәләмәләнеп беткән була. «Күз күне, минем өс-баш бик начар, йөзләр дә кабердән кайткан кеше кебек — шул сәбәпле күз күргән, белгән кешеләр дә мине танымыйлар иде», — дип тасвирлый Сирин үз-үзен «Син сөйләмә әле, мин сөйлим» дигән истәлегендә. Ул бу кыяфәттә туган авылына кайтып керергә оялган. Һәм ул, әлеге истәлектә язылганча, кайтышлый Бөгелмәдәге энесе Шамилгә керә. Бераз хәл алгач, кеше күзенә күренерлек өс-баш юнәткәч, Кәрәкәшлегә юл тота.

Бераз торгач, Сирин үзе теләп фронтка китә, сугышларда катнаша. 1942 елның көзендә ул, контузия алып, Кәрәкәшлегә кайта. 1942-1943 елның кышын авылда үткәрә, сәламәтләнә төшкәч, колхоз эшенә йөри башлый. 1943 елның язында, бераз хәл алгач, яңадан сугышка китә. Шул ук елны, авыр яраланып, Ташкент шәһәренә госпитальгә озатыла. Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен Сирин Батыршин ике тапкыр медаль белән бүләкләнә: 1) «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.» медале (СССР Верховный Советы Президиумының 1945 елның 9 май указы. Удостоверение Ш № 0296796). Бу медальне Сирингә 1946 елның 25 нче июлендә Ютазы районы военкомы тапшыра. 2) «Двадцать лет Победы в Великой Отечественной войне 1942-1945 гг.» медале (СССР Верховный Советы Президиумының 1965 елның 7 май указы. Удостоверение А № 9085408.). Бу медаль Сирингә 1966 елның 4 августында Баулы райвоенкомы подполковник Давыдов кулы белән тапшырыла.

Бераз сәламәтләнгәч, Сирин Ташкенттан Кәрәкәшлегә кайта. Яңадан колхозда эшли башлый. Ул һәр эштә тырышып, яхшы эшләргә ярата. Аны колхозчылар да хөрмәт итәләр, зурлап карыйлар. Сугыш вакытында колхозда тырышып эшләгән өчен Сирин Батыршин «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.» медале белән бүләкләнә (СССР Верховный Советы Президиумының 1945 елның 6 июнь указы. Удостоверение Щ № 166368). Сирингә бу медальне 1947 елның 11 августында хезмәт ияләренең Ютазы район Башкарма комитеты рәисе Идрисов тапшыра.

1946 елны Сирин Баулы районы Акбуа посёлогына килеп урнаша. Колхоз аны берьеллык умартачылар курсына җибәрә. Курсны тәмамлап кайткач, Сирин колхозда умартачы булып эшли башлый. Ул монда да бик тырышып эшли, башкаларга үрнәк булып тора.

Сирин 1956 елда реабилитацияләнә.

Сөргеннән кайткач та, Сирин иҗатын дәвам иттергән. 1960 елда аның тормышында бер шатлыклы вакыйга да булып ала: шул елның 1 сентябрендә Сирин белән Фәһимә Вәли кызы гаилә корып яши башлыйлар. Бу вакыйга шагыйрь иҗатына да

уңай йогынты ясый. Ул берара, 1920 нче еллардагы кебек, илдәге вакыйгалар белән кызыксынып, иҗаты белән аларга үз мөнәсәбәтен белдереп яши башлый: аның архивында 1960 елларда язылган дистәләрчә әсәре саклана. Әмма бу озакка бармый: аның иҗаты, безнең мәгълүматлар буенча, 1962 елда кинәттән туктап кала. Бу аның каты авырып, урынга ятуы белән бәйле булса кирәк. Ул озак еллар Баулыдагы туберкулёз шифаханәсендә дәваланырга мәҗбүр була.

Шагыйрь Сирин озак һәм каты авырудан соң, 1969 елның 23 ноябрендә Акбуада вафат була һәм шунда посёлок эчендәге татар зиратына җирләнә. Шагыйрьнең тууына 90 ел тулуны билгеләп үткән вакытта, аның каберенә Баулы районы хакимияте тарафыннан барельефы төшерелгән истәлекле таш куелды.

Шагыйрьнең архивында аның Ватан сугышында катнашуы хакында тагын бер документ сакланган. Без аны тулысы белән китерәбез: «Свидетельство №25 (бессрочное). Об освобождении от воинской обязанности. Выдано настоящее свидетельство Ютазинским РВК Т.Р. военнообязанному 1896 года рождения Батыршин Сирин К. рядового состава запаса категории ВУС №1, уроженцу Тат.АССР Ютазинского района д.Каракашлы в том, что он по освидетельствовании 26 июня 1946 года комиссией при Ютазинский РВК признан негодным к несению воинской обязанности с исключением с учёта по гр.I, ст.11а расписания болезней приказа НКО СССР 1942 г. №336 и снят с воинского учёта. Районный военный комиссар, капитан (подпись). 29.06.1946». Шунда ук болай дип тә язылган: «С 1942 по 1943 служил в 207 стрелковом полку и уволен по контузии, участвовал в бою под Москвой». Бу материалларны безгә Сириннең хатыны Фәһимәнең кызы Илгизә тапшырды.

Шулай итеп, Сирин Батыршин бик авыр, катлаулы һәм газаплы, тулы бер гомер кичергән. Бүгенге көнгә шагыйрьнең архивы әле тулысынча җыелып бетмәгән; безгә билгеле булганнары аның тормышын һәм иҗатын тулысы белән колачлап ала алмыйлар. Аның турындагы материаллар әле хәзер дә төрле урыннарда, төрле кешеләр карамагында сакланырга мөмкин. Ләбиб Лерон тапкан хатларны Сирин турында моңа кадәр билгесез булып кала килгән шундый материалларның бер өлеше итеп карарга кирәк.

МИН КАЙДА БУЛДЫМ? — МИН ШУНДА БУЛДЫМ!

Сирин

— Сөйләшер сүзләр,
Эшләр күп иде,
Мин югалттым сине, эзләдем.
Беркем дә белми,
Йөрәгем түзми,
Ничек уйларга да белмәдем.
Әллә соң авырып,
Шифаханәдә
Яттыңмы, дус, кайда кундың син?
Сулган чәчәктәй
Сулган йөзләрең,

Кайда йөрдең, кайда булдың син? —
Мин булдым шунда,
Кайдадыр шунда, —
Сандугачлар оя ясамый.
Мин булдым шунда..
Кайдадыр шунда, —
Чыпчыклар да килеп сайрамый.
Мин булдым шунда,
Кайдадыр шунда, —
Гөлсириннәр, гөлләр үсмиләр.
Мин булдым шунда,
Кайдадыр шунда, —
Җәйге җылы җилләр исмиләр.
Булды көннәрем,
Бетте өннәрем,
Бер сүз сөйләшергә җөдәдем.
Иректә йөргән,

Матур көн күргән
Чебеннәрнең көнен көнләдем.
Азмы кимсенде
Кимле йөрәгем,
Үзгәләнде шигъри хисләрем.
Белмимен нигә,
Гаепсез көйгә
Яшькә әйләнде көндез-кичләрем.

Алтай

«КИЛӘ»ЛӘР

Яңгыр булып
явасым,
Тамчы булып
тамасым,
Сулар булып
агасым,
Трамвай булып
чабасым килә.
Җилләр булып
исәсем,
Гөлләр булып
үсәсем,
Чәч булып
бәйләнәсем,
Тәгәрмәч булып
әйләнәсем килә.
Тагын килә…
Бу «килә»ләр
килә,
килә,
күп килә.
Аңлап җиткермим
Үзем дә:
бу «килә»ләр
ник килә?
Зәйнәпне бик күрәсем,
Гөлсем өчен үләсем,
(Күрми ничек түзәсең?) —
Икесен дә үбәсем килә.
Пуля булып
очасым,
Дошманнарны
тотасым,
Бомба булып
шартлыйсым,
Револьвер булып
атыласым килә.
Утлар булып
гөрлисем,
Күкләр булып
күкрисем,
Икейөзле кешенең
Битенә төкерәсем килә.
Тагын килә…
бу «килә»ләр
килә,
килә,
күп килә.
Бер-бер артлы
Бу «килә»ләр
ник болай
тезелеп килә?
Тәнгә тәңкә
тезәсем,
Балык булып
йөзәсем,
Бөтен җирне
гизәсем,
Сабый булып
уйныйсым,
көләсем килә.
Тормышны яктыртасым,
Айны җиргә тартасым,
Әйләндереп аркасын,
Бик нык ватасым килә.
Юлларымның
иркенлеген,
Өстем-башым
бөтенлеген,
Бүгенгенең
чибәрлеген,
Иртәгәнең
гүзәлләрдән-гүзәллеген
җырлыйсым килә.
Тагын килә…
Бу «килә»ләр
килә,
килә,
күп килә.
Аңлап җиткермим
үзем дә:
бу «килә»ләр
ник килә?..

1930 ■

ҮТКӘННӘН ХАТЛАР

(Соры тышлы папкадан)

....

БЕРЕНЧЕ ХАТ

Х.Г.Рәфыйковтан — Л.С.Соболевка

1961 елда, көннәр язга таба авышкан бер вакытта, Х.Г.Рәфыйков дигән бер милләттәшебез РСФСР Язучылар союзы рәисе Л.С.Соболев (1898-1971) исеменә эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт булган мондый хат (*әлбәттә, ул хат тулаем рус телендә язылган. — Л.Л.*) юллый:

«Хөрмәтле Леонид Леонидович (*хат юллаучы ялгыш язган, дөресе — Леонид Сергеевич. — Л.Л.*)!

Минем мөрәҗәгать итүем, бәлкем, Сезне беркадәр гаҗәпләндерер дә, чөнки мин әдәбияттан читтәге кешемен, шулай да, әйтергә кирәк, совет әдәбиятын бик яратам.

Эш менә нәрсәдә, ип.Соболев, Татарстанның нефть промышленносте үзәге булган Баулыда совет поэзиясенең башында торучыларның берсе булган Сирин дигән карт бер шагыйрь яши.

Ул — бик үзенчәлекле, талантлы, язу алымы буенча новатор шагыйрь. Сирин — халык арасында зур популярлык казанган каләм иясе. Ни кызганыч, утызынчы елларда ул бәлагә тарыды — репрессиягә эләгеп, туган җиреннән мәхрүм булып яшәргә дучар ителде. Бары тик партиянең XX съезды гына аны чын мәгънәсендә тормышка кайтарды. Ләкин алдагы елларда ясалган күңел җәрәхәтләре тиз генә төзәлерлек түгел кебек әле — шагыйрь бүген дә матдикөнкүреш кыенлыклары кичереп, гомер сөрергә мәҗбүр: ул хатыны белән бергә 5 квадрат метрлы бүлмәчектә интегеп яши, инвалид буларак, 281 сум пенсия ала.

Яшәүмени инде бу? Яшәү түгел, әлбәттә, ә ихтирамга лаек шагыйрьне мәсхәрәләү. Көлке һәм аяныч бит: Татарстанның индустриаль төбәгендә яшәүче карт әдипкә иҗади тормыш алып барырлык яхшы гына бер бүлмә яисә фатир табылмасын инде.

Теләсәләр, ярдәм итә алалар бит югыйсә. Әмма җирле төбәктәге чиновниклар кеше хәлен аңларга теләми. Кешеләргә ленинчыл кайгыртучанлык күрсәтү юк.

Иптәш Соболев, кешене бу мәхшәр чокырыннан чыгарасы, аңа ярдәм кулы сузасы иде. Сез, бүгенге көннең кайбер Фамусовлары кебек, бу мәсьәләгә җиңел карамассыз, ә бәлки моңа җитди игътибар биреп, уңай хәл кылырсыз дип ышанам.

Сәлам белән, 1919 елдан КПСС әгъзасы, пенсионер Х.Г.Рәфыйков.
Минем адресым: Г-165, Студентлар урамы, 28 нче йорт, 20 нче корпус, 150 нче фатир.
Иптәш Сирин Батыршинның адресы: Татарстан АССР, Баулы районы, Баулы авылы, СМУ-4 бистәсе, 5 нче барак».

(*Хатның язылу вакыты күрсәтелмәгән: якынча 1961 елның март ахыры-февраль башларында адресатка юлланган булырга тиеш. — Л.Л.*).

....

ИКЕНЧЕ ХАТ

В.Н.Шишовтан — Афзал Шамовка

Күп тә үтми Мәскәүдән, РСФСР Язучылар союзыннан — идарә сәркатибе урынбасары В.Н.Шишов дигән иптәштән Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе А.Ш.Шамовка (1901-1990) хат (№ 489) килеп ирешә:

«Кадерле Афзал Шиһабетдинович!

КПСС әгъзасы иптәш Х.Г.Рәфыйковның Татарстанның аксакал шагыйре Сирин Батыршинга ярдәм итү мәсьәләсе турындагы хатының күчерелмәсен Сезгә юллыйбыз.


СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ РСФСР
ПРАВЛЕНИЕ

Куда Казань
ул. Баумана д. № 19
Союз советск. писателей татарии
Кому Шамову Афзалу

Хатта күтәрелгән мәсьәләне ачыклавыгыз һәм нинди нәтиҗәгә килүегез хакында РСФСР Язучылар берлеге идарәсе секретариатына хәбәр итүегезне сорыйбыз.

Ихтирам белән, В.Шишов.
13 февраль, 1961 ел».

....

ӨЧЕНЧЕ ХАТ

Сирин Батыршиннан — Афзал Шамовка

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең Мәскәүдән килгән хатка җавабы сакланмаган (*һәрхәлдә, архивымдагы «1961ел: Язучылар хатлары һәм аларга җаваплар» дигән папкада ул юк. — Л.Л.*). Җитәкчелек (әйтик, Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе Афзал Шамов шәхсән үзе) тарафыннан шагыйрь Сирингә берәр төрле җавап бирелгәндерме, юктырмы, бу хакта да тарих әлегә дәшми. Вәләкин безгә үткән еллар аша мәгълүм булганы шул: 1961 елның июнь аенда Афзал Шамовка (1958-1961 елларда Татарстан Язучылар Союзы идарәсе рәисе) Сирин Батыршин үзе хат яза. Сүзне озакка сузмыйча, шагыйрьнең әллә ни төчеләнеп-нитеп тормыйча гына язган шул хатына (*хаттагы кайбер ялгыш язылган сүзләр һәм орфографик хаталар төзәтелеп бирелә. — Л.Л.*) күз салыйк әле:

«Афзал Шамов!

Бу хатны сиңа Сирин яза. Сезгә сәлам. Үзем исән, сезгә дә исәнлек, саулык телим.

Мин сезгә күптән хат язарга уйлап йөрсәм дә, сезнең вакытыгызның бик кадерле, эшләрегезнең бик җаваплы булуын игътибарга алып, үземне хат язудан тыеп килдем. Бәлки синең бу хатны укып торырга вакытың да булмас, шәхси тормышым турында язу минем үзем өчен дә җиңел нәрсә түгел, шулай да мин бу хатны язарга тотындым, кыска язарга тырышам.

Миңа бүген Бөгелмәдән берничә иптәшем килеп чыктылар. Алар 1919 еллардан бирле күп урыннарда эшләгән карт пенсионер иптәшләр. Алар минем тормыш хәлем белән танышкач: «Син Афзал Шамовка хат язып кара әле, без синең бу тормышың белән риза түгел, моның өчен без бик борчылабыз...» диделәр. Мин үзем өчен борчыла торганнардан түгел, шулай да аларның борчылуы мине борчыды. Минем башкаларны борчыйсым килми. Менә шулардан чыгып, мин бу хатны язарга уйладым.

Мин — 2 нче группа сугыш инвалиды. 33 сум пенсия алам. Бу сүзләрне Колчак сугышы вакытында бер мәртәбә, соңгы сугышта 2 мәртәбә контузия алган, 2 мәртәбә парализовать ителгән, 2 мәртәбә җиңел формада «паралич головного мозга» белән, 2 мәртәбә үлеп терелгән, шуның өстенә бераз шигырьләр дә сырлаган куллар яза.

Тормыш иптәшем белән шул 33 сум хисабына яшибез. Үзем беркайда эшләмим. Газета-журналларга язылып укып барырга материаль мөмкинлегем юк. Бу шиксез авыр хәл. Сөйләп торуның кирәге юк. Саулыгым да начар.

Бервакыт Гали Хуҗиев килгәч, әдәби утырышта «Без Сиринне Язучылар союзына член итеп алабыз, без бу турыда сөйләштек», дип мине шатландырып киткән иде. Шуннан соң бернәрсә дә ачык түгел. Әгәр мөмкин булса, минем Язучылар союзында член булу мәсьәләсен хәл кыласы иде. Аннан соң пенсия мәсьәләсен хәл кылып булмасмы? *(Соңгы ике җөмләнең астына кемдер карандаш белән сызган. — Л.Л.)*

Минем җыентыкны чыгару турында. Мин аларны Мәгъсум Латыйфуллинга тапшырган идем. Ул аны һаман тапшыралмый үзендә тота *(беләсе, табасы иде — бу кульязма кайларда тузан җыеп ята икән? Хәер, бәлкем, ул юкка чыккандыр да инде. — Л.Л.)*.

Димәк: өч мәсьәлә тора, менә шуларны хәл кыласы иде. Менә шул турыда син нәрсәләр әйтерсең, мин синең киңәшеңне көтәм. Мин үзем, бердән — саулыгым, икенчедән — материаль мөмкинлекләрем булмау аркасында, Казанга бара алмадым.

Хәзер җәй көне. Сез ялга китә торгансыздыр. Шул сәбәпле минем бу хат, бәлки, сезнең кулга да ирешмәс. А.Гомәргә *(Абдулла Гомәр (1906-1974), тәрҗемәче, мөхәррир-журналист, 1958-1963 елларда Татарстан Язучылар Союзында яшь язучылар белән эшләү буенча әдәби консультант вазифасын башкара. — Л.Л.)* берничә шигырь җибәрәм, анысы аерым хат белән булыр.

Эшләрегездә зур уңышлар теләп, хөрмәт белән: Сирин. Баулы, СМУ-4, 5 нче барак. 9 июнь, 1961 ел.» *(Әлеге хат астына кемдер — бәлки Афзал Шамов үзе?! — «Җавап бирелде. 28.06.61», дип язып куйган. — Л.Л.)*

....

ДҮРТЕНЧЕ ХАТ
Афзал Шамовтан — Сирин Батыршинга

Сирин Батыршинның кулдан язылган хатына Афзал Шамовның машинкада бастырылган җавабы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Хөрмәтле Сирин дускай!

Бер бит кәгазьнең ике ягын да вак кына хәрефләр белән тутырып язган хатыгызны моннан ун көннәр элек алган булсам да, бүген генә җавап язарга вакыт таптым. Бу арада чит республикалардан килгән кунаклар күп булды, алар белән төрле кичәләр, очрашулар һәм киңәшмәләр үткәрергә, барлык вакытны диярлек аларга багышларга туры килде.

Инде хатыгызда язылган мәсьәләләргә килик. Башта җыентык мәсьәләсе. Моннан бер-ике ел элек сезнең бер җыентыгыгыз чыккан иде *(1959 елда Татарстан китап нәшриятында басылган, редакторы — Зыя Мансур һәм тышлык рәссамы Л.П.Анисимов булган, 18 шигырь басылган 56 битле, яфрак хәтле яшел «дәфтәр» турында сүз бара. — Л.Л.)*. Анда барлык әсәрләрегез дә кереп бетмәгәндер, дип уйлыйм. Әгәр шулай икән, иң яхшы шигырьләрегезне туплап, зуррак бер китап чыгарылса яхшы булыр иде, билгеле. Моның өчен Таткнигоиздатка заявка бирергә һәм аларның ризалыгын алганнан соң кульязманы тапшырырга кирәк. Хәзер алар 1963 ел планын төзү белән шөгыльләнәләр. 1962 ел планы инде күптән төзелеп беткән, тиешле оешмалар тарафыннан расланган. Бастырырга теләгегез булса, бары 1963 елда гына бастырырга мөмкин. Бу турыда нәшрият белән бәйләнешкә керегез. Планны караган вакытта без үзебезнең уңай фикеребезне әйтербез.

Союзга член итеп алу мәсьәләсенә килгәндә, язучылар Союзга бары яңа әсәрләре белән генә алыналар. Әгәр яңа әсәрләрегез бар икән, алар басы-

лып чыкканнан һәм халык тарафыннан кабул ителгәннән соң Союзга алу мәсьәләсен куярга мөмкин.

Пенсияне хезмәт хакыннан чыгып билгеләгәннәрен белә торгансыздыр. Әгәр пенсиягезне билгеләгән вакытта дөрес санамаган булсалар, урындагы социаль тәэминат бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Алар шул гариза буенча пенсиягезнең күләмен яңадан карарлар, дөресләрләр. Без Сезгә карата нинди генә яхшы нияттә булсак та, пенсиягезнең күләмен берничек тә үзгәртә алмыйбыз. Ул бары хөкүмәт тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә генә хәл ителә.

Иҗат эшләрегез турында сорашасы килә. Нәрсә эшлисез? Нинди иҗат планнарыгыз бар? Мөмкин булса, кыска гына итеп язып җибәрсәгез яхшы булыр иде.

Иптәшләрчә сәлам белән:
А.Шамов. 28.06.61 ел».

Сирин Батыршин (1896-1969) Афзал Шамовка җавап хаты язганмы, юкмы — бу хакта да безгә әлегә нәмәгълүм.

*Хатларны **Л.Лерон** әзерләде.*

....

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕК
Рәшит Әхмәтҗанов

Бераү көлә,
Синең көлүеңне көлә;
Бераү кия,
Сине үз өстенә кия.
Сирин

Әкиятләрнең серле урманыннан
Килеп чыгып безнең яннарга,
Таш тутырып тирән казанына
Шулпа куйган кебек кайнарга,
Утыра ул...
Салам эшләпәсе
Йөзен каплап тора кояштан.
Эндәшмәсәң, шулай утырачак,
Утырачак өч көн тоташтан.

Безнең коенганга сокланып ул
Утырса да елга ярында,
Киләчәккә нидер озаткандыр
Мәңгелеккә аккан агымда.

— Әйдә, бабай, су коен, — дим аңа.
— Булмый, булмый, — ди ул, —
юк, балам,
Җырлап торган гомеремне эзлим,
Аны эзләп юлга кузгалам.

«Әле генә бирედә иде бит,
Әле генә кулда уйнаттым.
Әле генә арлы-бирле килде,
*Әллә кайсы алды, югалттым...»**

Кузгалды да кара урманына
Кереп китте дәшеп кунакка.
Әкрен генә дулкыннарны борып,
Җилләр исте сыман шул якка.

Әкият карты. Умартачы бабай...
Аның шагыйрь Сирин икәнен
Соңлап белдем, —
Безнең көймәләрнең
Җил киергәч кенә җилкәнен.

Ә калганын инде, ә калганын
Давылларда йөреп аңладым.
Үкенечкә калды: бер кабат та
Аны куандыра алмадым.

Юлчы булып һаман ишек шакый,
Уза-уза узган елларга, —
Карлы бураннардан арынып бер,
Бераз гына җылынып чыгарга...

Баулыңдагы гөлләр сине эзли,
Җылы хәзер монда һәр көнең,
Җыры белән Галәм киңлегенә
Күтәрелә җаны кешенең.

Җыры китә... җанын нур итә ул, —
Шулай яши илне сөйгәннәр...
Ә соң нишли, көлүеңне көлеп,
Өсләренә сине кигәннәр?! ■

*Сирин шигыреннән.

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

БИКТИМЕРОВ ШӘҮКӘТ ХӘСӘН УЛЫ (1928-2012) — драма актёры, СССРның халык артисты (1977), РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1979). 1986 елда Ш.Биктимеров, Г.Тукайның тууына 100 ел тулуга багышлап, Г.Камал исемендәге театрда драматург Т.Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» драмасы буенча режиссёр М.Сәлимҗанов куйган спектакльдә Хәсән Акчурин образын иҗат итә. Аталы татар эшмәкәрләре Акчуриннарның Сембер өязенә урнашкан утарында шагыйрьнең 1909 елда бер атна чамасы кунак булу чорын эченә алган драмада Ш.Биктимеровның герое мөһим урын тота. Ул — Тукай һәм бертуган Акчуриннар арасында барган кискен фикер көрәшенең актив лидеры. Акыллы, хәйләкәр, яхшы ук укымышлы Хәсән шагыйрьнең иҗатын яхшы белә, аның халык алдындагы абруен үз мәнфәгатьләрендә файдаланырга омтыла. Шуңа күрә дә ул үзен Тукай белән итагатьле тота, хөрмәт, ихтирам күрсәтә, кешелекле һәм кайгыртучан булып күренергә тырыша. Тик шагыйрь аның кемлеген, максатларын яхшы аңлый. Нәтиҗәдә, халык вәкиле һәм бай фабрикант арасында планлаштырылган союз төзелми кала.

1967 елда Ш.Биктимеров Чыңгыз Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» спектаклендәге Байтимер ролен башкарганы өчен ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Әдәбият

Мөхәммәдиев Р. Сәхнә түрендә — Тукай // Соц.Татарстан. — 1986, — 14 июль; Илялова И. Шәүкәт Биктимеров. Казан, 1993.

ГАФУРОВ ИБРАҺИМ (ИБРАҺИМ НАСЫЙР УЛЫ ГАФУРОВ, 1910-1972) — ТАССРның халык артисты (1970). Лирик-драматик пландагы, романтик төсмерләр дә чит булмаган артист тамашачы күңелендә иң әүвәл Ә.Фәйзинең «Тукай» пьесасы буенча куелган спектакльдә Тукай образын тудыруы белән урын алды. Бу образ татар милли театр сәнгатенең җитди казанышларыннан санала. Сәхнә сәнгатебез тарихында беренчеләрдән булган тарихи-биографик жанрга караган спектакль үзәгендәге шагыйрь образын режиссёр Ш.Сарымсаков һәм башкаручы үсеш-үзгәрештә күрсәтергә тырыша. Шуңа күрә дә Тукай-Гафуров тамашаның һәр күренешендә үзенең яңадан-яңа яклары, холык-сыйфатлары белән ачыла бара. Әйтик, Җаектагы типография күренешендә ул инде тормышта үз урынын тапкан, бәясен белгән, үз-үзенә ышанган туры сүзле, куркусыз көрәшче буларак гәүдәләнсә, Казанга килүенең тәүге сәгатьләрендә бераз югалып калган, үзенең шәкертлегеннән, провинциальлегеннән ояла торган тартынучан егет итеп бирелә.

Тукай образы өстендә эшләгәндә (репетициядән соң) аны Ә.Фәйзи үзенә чакырып алган һәм уенында «Тукай образына хас булган контраст моментларга әһәмият биреп җиткермәвен» әйткән, Тукайның нечкә хисле шагыйрь икәнлеген онытмаска киңәш биргән. И.Гафуров драматургның бу киңәшләрен күңел түренә салып куюын һәм хәлдән килгәнчә эшләргә тырышачагын яза.

Халыкның Тукай кебек бөек улы образын иҗат итүнең авырлыгын аңлаган театр тәнкыйтьчеләре И.Гафуров тудырган шагыйрь образын югары бәяли, аның яшьлеген, җитезлеген, гадилеген билгеләп үтә.

Әсәр

Гафуров И. Йөрәгемдә урын алган ул. Соц. // Татарстан. — 1966. — 25 июнь.

Әдәбият

Кутуй Г. Тукай //Кызыл Татарстан. — 1939. — 23 сентябрь; Алиш А. Безнең Тукай / Кыз. Татарстан. — 1939. — 18 сентябрь; Гильдеев К. Тукай // Кр.Татария. — 1939. — 28 сентябрь.

Гали Арсланов,
сәнгать фәннәре докторы

КИТКӘН КЕБЕК ТӘ ТҮГЕЛ...

Сәмига Сәүбанова



Кызык кеше иде Рәшит Әхмәтҗанов дигән шагыйрь. Бер дә борынын күтәреп йөрмәде. Мәйданнарга чыгып та шәрран кычкырмады. Ачлык мәйданында республикабызның мөстәкыйльлеге өчен милләтпәрвәрләр белән бергә сафка басканда да авызыннан бер сүз чыкмады, соңрак бу вакыйгага багышланган «Ачлык мәйданы» китабына кергән шигырьләре исә меңләгән рупордан кычкырганга караганда көчлерәк яңгыраш алды.

Бүтәннәргә охшамаган башка сәер якларын күп сөйләргә булыр иде.

...Ничек шулай килеп чыккандыр — безнең гаилә тормышыбыз Рәшит Әхмәтҗанов гаиләсе белән гел янәшә барды.

Башта аның белән Бауман урамындагы нәшрият бинасында, мин — бишенче, ул — дүртенче катта, соңыннан исә Декабристлар урамындагы газета-журналлар нәшрияты бинасында — бер редакциядә — «Казан утлары» журналында озак еллар бергә эшләдек, бергә-бергә бәйрәмнәр үткәрдек, бер өстәл артына утырып тәгам җыйдык.

Яшь гаилә булып яши башлагач, без Рәшитләрдән бушап калган фатирга (Чернышевский урамында — тимер юл вокзалы каршында иде ул йорт) күчендек. Ирем белән бу фатирны карарга баргач, хатыны Луиза ханым табын әзерләп, алар яңа йорттагы фатирга күчү, ә без исә үз куышыбыз булуы куанычын бергә билгеләп тә алдык. Олы кызы Ләйләгә өч яшь, ә Айдарының туарына бер ай гына калган иде.

Улының дөньяга килү куанычын да, кереп, безнең белән уртаклашты һәм:

— Гадәт буенча үз өемә кайтам, дип уйлаганмын, — дип көлдереп алды.

Яңадан алган фатирларыбыз да күрше йортларда булгач, бәйрәмнәрдә гаилә табыннарын берләштердек. Рәшитнең улы Айдар белән минем кызым бер мәктәптә, бер сыйныфта, бер парта артында утырды...

Язучылар берлегенең бакча ширкәтендә салган йортларыбыз да бер-беребездән ерак түгел иде, яккан мунчабыздан бер-беребезне калдырмадык.

Ялгыз калуны яратмый торган иде ул.

Җәйге яллары вакытында хатыны, балаларын алып, Азнакайда яшәүче әтисе белән әнисе янына киткәч, Рәшитнең бик күңелсезләнеп, үзен-үзе кая куярга белми йөрүенә аптырап:

— Иҗат итәреңә җай чыккан, рәхәтләнеп шигырь генә язасы бит инде, — дигәч: «Берүзең язып буламыни?» — ди торган иде.

«Сезнең өчен шуны эшлим», — дип, ул гаиләсен алдан булыр-булмастай вәгъдәләр белән өметләндермәде. Хатынын, балаларын уйламаганда куандыра, уйламаганда шаккаттыра белде. Бервакытны әйбәт кенә гонорар алгач, өйгә кайтышлый гына очраган, бергә эшли торган хатынны юл уңаеннан киемнәр кибетенә алып кереп:

— Минем хатынның гәүдәсе синеке шикелле, әйдә әле, менә шушы пәлтәне киеп кара әле, — дип, аңарда үлчәгәч, хатынына алып кайтты. Кызы Ләйләне дә кышкы тун белән шулай сөендерде ул.

Мондый гамәлләре күп булды.

Бүтәннәр хатыннарының булганлыгы белән мактанганда, ул үзенекеннән бераз зарланырга яратты.

Бергә аралашып яшәгәнгә, гаилә эчендәге мохитне яхшы белгәнгә күрә, аптырап:

— Кеше өйдәге чүпне чыгармаска тырыша, нишләп син юкны бар итеп сөйлисең, — дигәч:

— Иҗатташ дусларым әз генә берәр хатын-кызны мактаганымны ишетсә дә, шуңа багышлап шигырь яза, ә минем хатынны үзең беләсең, тәмле сүзгә ярты дөньясын бирергә әзер, болай да инде бар дус-ишем, хезмәттәшләрем теше сызлаганга гына түгел, берәр җире тырт итсә дә аңа йөгерә, авырга туры килмәсен дип тырышам, — дип җавап кайтарган иде. Аннан соң шаркылдап көлде дә:

— Хатынсыз да калуың бар, юньле хатын аяк астында аунап ятмый ул! — дип өстәде.

Чынлап та, Луиза теш табибы булгач, Рәшитнең дуслары да, хезмәттәшләре дә хатынының киң күңеллелегеннән рәхәтләнеп файдаланды.

Күрше-күләнгә, дус-ишкә генә

түгел, Рәшитнең үзенә дә ашыгыч ярдәм булды Луиза. Ничә тапкыр ирен каты авырудан аякка бастырды, ничә тапкыр әҗәл тырнагыннан тартып калды, үзенең генә кулыннан килмәсә, хастаханәгә озатты…

Балаларын бик яратты Рәшит. Үсмер чагында тач үзенә охшаган аксыл чәчле, зәңгәр күзле улы тәртибе белән тәртәгә типкән чакларда да иң каты итеп әйткән сүзе «блондин» булды.

Төп байлыгын — матур гаиләсен, тыныч тормышын, ныклы терәгенә күз тиюдән уттан курыккандай курыкты. Шуңа күрә ул бу турыда белгертергә яратмады. Ә менә күңеле кырылган, җаны әрнегән чакларны ул берәүдән дә яшереп тормады. Гаделсезлек, тигезсезлек, милләт язмышы аңа тынгы бирмәде, ул аның җанын кимерде. Вакыт-вакыт ул бу көрәштә үзенең көчсезлеген аңлаудан шулхәтле югалып кала, төшенкелеккә бирелә һәм дөньясына, үзе әйтмешли, «нәгаләт» укып йөри башлый иде. Бу халәтен яшерергә кирәксенмәде, бөтен кешенең ишетүен, күрүен, барыбызның да җаны уянуын теләде.

Башка чакларда һәрнәрсәгә юмор белән карады.

Шагыйрьләр еш гашыйк була, дисәләр дә, бу сүз аңа туры килмәде. Ул бары тик гаиләсен, бары тик бер генә кешене яратты. Бер генә кешегә атап шигырь язып булмый, дисәләр дә, мәхәббәт турындагы шигырьләренең барысы да хатыны Луизага багышлангандыр, дип уйлыйм.

Үзе сәер булган шикелле, хатынының да мәхәббәте сәеррәк иде. Рәшите мәңгелеккә күчкәч:

— Без бер-беребезгә «яратам» дип төчеләнеп яшәмәдек, бүтән берәр хатын-кызга гашыйк булып, иләсләнеп тә йөрмәде ичмасам, шагыйрь кеше иде бит ул! — дип өзгәләнгәнен һич оныта алмыйм…

Ил язмышы өчен ут йотып яшәде, ә инде урыс гаскәрләре тыныч кына яшәп ятучы Чечнядагы мөселман кардәшләребезне канга батырып ташлагач:

— Бу кадәрле вәхшилеккә йөрәгем чыдамас, мин үләрмен инде, — дип, эштәге хезмәттәшләре, дуслары белән бүлмәдән-бүлмәгә кереп, бәхилләшеп йөрде. Ә өенә кайткач, йөрәк кенә түгел, ашказаны да авырта дип уйлап, эчен тотып, сыгылып төште. Түзә алмагач, янына энесе Илдусны чакырды. Үләрен сизенсә дә, хушлашу сүзләрен әйтергә өлгермәде. Ашыгыч ярдәм машинасы килгәнче йокымсырады да… китте.

Ирем белән сердәш иде. Гомерләре бер елда өзелде.

Китте…

Җәсәден яргач, йөрәгенең бөтенләй эштән чыкканлыгы билгеле булды. Йөрәген ярырдай сәбәпне белгәннәр белде, белмәгәннәр белмичә калды.

Дөньялыкта җәмәгате Луиза ханым тарафыннан бик хөрмәт ителеп яшәде. Урыс мәктәбендә урысча гына белем алган ханым, иренең шигырьләрен укыр өчен татарча укырга өйрәнде.

Иҗат кешесенең күңеле бик нечкә булуын аңлап, ирләр эшләрдәй тормыш мәшәкатьләрен дә аның өстенә ташламады, бар авырлыкны үз өстенә алды.

Үзенә аптырап караучыларга аның җавабы бер булды:

— Шагыйрь кеше бит ул!

Рәшитнең тылы шундый нык иде.

Вакытында өч ел буена Әлмәт шәһәрен төзешкән ташчы егеттән өйдә кадак та кактырмады Луиза. «Бары тик язсын гына, кадакны аны теләсә кем кага ала, ә шигырь язучылар — штучный товар», — дип, андый эшләрне кулы оста күрше-тирә, дусиштән эшләтте. Чөнки таш йортларны сала белгән Рәшит чынлап та өйдә кадак кага белми иде. Бакчада мунча салыр өчен кияве үзе эшләгән заводтан ниндидер бер корылманы сүткәч җыелган такталарны алып килгәндә, иске кадакларны ничек алырга икән, дип, бик озак аптырап торган иде. Үзенең бу булдыксызлыгыннан көләкөлә эшнең серенә бик озак төшенде.

Рәшит кебек бик күп талантлар хатыннары тарафыннан аяк чалынып, кагылып-сугылып, күтәрелә алмыйча, дөньядан китте. Ә Рәшитнең иҗатын санлап килгән һәр кеше, Луиза ханым әзерләгән тәгамне җыеп, хөрмәт итеп, бу өйдән якты уйлар белән генә китә иде. Өйдә шундый шартлар булмаса, аның иҗаты болай күтәрелер иде микән?

Язучы Аяз Гыйләҗевнең:

— Мин базардан бер чиләк бәрәңге күтәреп кайткан көнне бер юл да яза алмыйм, — дигәне бар.

Тормыш йөген Луиза ханым ире иңнәренә салса, Рәшит тә яза алыр иде микән?

Бакчаларыбыз бергә булгач, еш кына бергә дә кайттык. Саф һавада битләре алланып, йөгерә-йөгерә кайткан Рәшитебез электричкадан төшү белән шәһәрнең төтенле һавасыннан тыны кысылып, көч-хәл белән атлый башлый торган иде. Шуны белгән Луиза иренең кесәсенә генә түгел, минем сумкага да ашыгыч кирәк булса дип, дарулар тыга торган иде.

Бәла-казага очраудан курыкты. Шуңа да кызы Ләйлә машина йөртергә өйрәнгән чагында, аңа утырмыйча, бакча юлы буйлап, оныгы Наиләне күтәреп, тиз-тиз атлап, электричкага бергәләп күп тапкырлар чыктык. Йөрәгем хәлсез дип тормады, шул ук бакчадан хатыны Нурсөя белән кайткан Фәнис Яруллинны әллә ничәнче каттагы фатирына күтәреп менгерә торган иде. Кешеләрне җәлли, гайбәтләргә бик ышанмый иде. Үз яннарындагы йортта фатирда торган чагында Зәки Зәйнуллинга хатыны пешергән камыр ашларын күп ташыды, өенә дә еш чакырды. Яңа ел бәйрәмендә бер тапкыр Фәнис Яруллин белән дә бергәләп утырдык...

Хәзер уйлыйм да шундый нәтиҗәгә киләм — минем бөтен гомерем иҗат кешеләре арасында үтте — эштә дә, яшәгән йортыбызда да, җәйге бакчабызда да... Аларның һәркайсы дөнья бәһасе кеше иде. Мин аларны яраткач, хөрмәт иткәч, алар да миңа шулай җавап кайтардылар.

Рәшит Әхмәтҗанов шуларның берсе иде.

Аның дәвамы булып балалары, өч оныгы яши. Икесе, ул мәңгелеккә киткәч, дөньяга килде. Бабаларын күргәннәре булмаса да, шәт, иншаллаһ, аның кем булуын, иҗатын яхшы белерләр һәм шагыйрь бабаларының рухын рәнҗетмәсләр, милләт җанлы балалары булып үсәрләр.

Шагыйрь хатыннарына бер дә җиңел түгел. Ирләренең кем икәнлеген белеп, аңа рухи таяныч булганнарның гына гаиләсе сакланып калды, иҗатлары югары биеклеккә күтәрелде. Луиза ханым ире исән чагында ук аның иҗатының бәһасен белде, аңарга терәк булырга тырышты. Ул бакыйлыкка күчкәч, минем белүемчә, Рәшит Әхмәтҗановның дүрт тапкыр калын-калын шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Хәзер Татарстан китап

нәшриятында ике томлыгы басылып ята. Йә, тагын кайсы шагыйрь хатыны шуны эшли алды?

Ләйлә белән Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә мәхәббәте турында күп язалар. Алар зур мәхәббәт белән, бер-берсе өчен үләрдәй булып яшәде, дип әйтә алмыйм. Бер-берсенә яратам дип әйттеләр микән әле? Рәшит күп язды, Луиза күп эшләде. Тик Рәшитнең Луизага багышланган бер шигыре барысын да әйтеп бирә:

Бүген елның иң кыска көне —
Кайгыларга салды да ул мине,
Китеп барды үзе, мин калдым,
Әйтерсең лә юлда югалдым.

... Югалмадым, исән-сау идем,
Юлда сине эзләп йөредем.

Хәбәр салдым бөтен дөньяга —
Сине эзләп дөнья ут яга.

Озайтырга синең көннәрне —
Мин утларга ягам төннәрне...

Төннәр янсалар да — төн кара,
Төннәр яна — көлләре кала.

Яктылыкның түгел актыгы —
Чәчләремнең кардай аклыгы.

Мин агарам — һаман агарам —
Күренмидер хәтта күз карам.

Шулай узар минем гомерем.
Бөтен гомеремә бер гөлем
Син генә бит. Димәк иртәгә
Миңа тагын юлга китәргә —
Утка яга-яга төннәрне,
Озайтырга синең көннәрне...

Әйтерсең, ул безнең янда йөри. Әйтерсең, бакыйлыкка күчкәненә егерме ел вакыт узмаган...

Ара ерагайган саен кемне югалтканыбызны ныграк аңлыйбыз.

ҮТКӘННӘН ХАТ

Рәшит Әхмәтҗанов — Мәгъсум Хуҗинга

Сәлам, Мәгъсум абый!

Ялта якларыннан бу көннәрдә кычкырып көлгән тавышлар, авазлар ишетелде. Сез дип уйладык. Ә «Чаян» сез китү белән елый да елый...

Кар яумады әле. Кибеттәге җылы пималарың исәннәр, таушалмый торалар. Төрле төстәге суларның чыганаклары кибеп бетте. Китап акчасы хатын кулына эләгеп... һалак булды. Гәҗит иртәгә җибәрәм, әй, юк, атна башында була инде. Алег хат язган, исән-сау гына зур кеше булырга әзерләнеп ятам, дигән. Минем кызга диңгез кабырчыклары алып кайтырга онытмагыз!!! Чыгачак гәҗиттә хикәягезне укып, бер хата да калдырмыйча төзәтеп җибәрдем. Дом печатинең бөтен тәрәзәләреннән атлар кешнәве, малай-шалайның кычкырулары ишетелеп тора, чөнки бүген хикәягез 100 меңнән дә артык үрчем бирә.

Саимә апа (Ибраһимова) сәлам әйтә. Сез юклык сизелә — акча түгел, фифирус бирүче дә юк үземә.

Бер-ике җыр язам Сезгә:
Сезгә барып ирешерме
Безнең язган хатыбыз:
(Үбешегез, серләшегез) —
Бер повесть, дүрт хикәягә
Ата булып кайтыгыз.
Кушымта:
Эх-ма!..
Тау башында куян ята —
Төлке аны уята.
Дөнья нужалары безне
Җырлата да, елата —
Яшьне сөртеп юата.

Иң изге теләкләр белән —
Рәшит Әхмәтҗанов.
10 декабрь, 1971 ел

(Әлеге хат Мәгъсум Хуҗин гаиләсе архивыннан алынды.)

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ

АНТ

Фатих Кәрим истәлегенә

Әткәм-әнкәм теле! Балаларың
Җир җимертеп эшли – тик ятмыйлар.
Бер-берсеннән уздырышып, хәзер
Мая туплый күпләр, мал саклыйлар.

Керфек какмый мал саклаган чакта
Балаларның «кемдер» телен кискән;
Тукай туганнарын таркаталган
Рухи юлбасарлар һаман исән.

Милли нигилистлар өммәтенә
Берләшкәннәр хәтер караклары, –
Таһирларны суга агызганда
Сандыкларын шулар кадаклады….

Яшәмәүне дәвам итсеннәрме,
Яшәүнеме әллә дәвам итик?!
Телдән төшкән сүзләр, уяныгыз,
Тукай дошманнарын таптап китик.

Телне саткан көмеш тиеннәргә
Алган киемнәргә төренгәнне
Чишендереп, шәрә калдырыйк без,
Үзе булыр – күзгә күренгәне.

Яндыр, телем,
Җаным яктылыгын
Каплап торганнарның күләгәсен!
Имансызлар хәзер ярты сүз дә
Безнең исемнәрдән сөйләмәсен.

Онытканның, телем, төшенә кер,
Хәтәр чорны бергә узыйк, хәтер!
Шулай булса гына, яшәүләрнең
Киләчәккә кеше серен әйтер.

Дошманыңның, телем, канына кер,
Йөрәгенә кадал, йөзенә яз...
«Китмибез»не* кабат укысыннар –
Кемнәр әлифбаңны таный аз-маз.

...Читлекләргә яптырсаң да мине,
Мылтыклардан аттырсаң да мине,
Бүген менә Фатих Кәрим кебек,
Атакага мин күтәрәм сине!

Синең өчен, туган илем өчен,
Балам өчен бүген утка керәм.
Ышан, телем,
                    һәрбер авазыңны
Азат итәчәкбез бирәм-бирәм!

[1]Тукай шигыре

БӘЙРӘМ

Без мәңгегә, без мәңгегә монда.
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары!

Чаба атлар, томырылып чаба,
Кыңгыраулар чыңлый юлларда.
Ил шатлыгы тынмас булгангамы,
Ятлар чыга куллар болгарга.

Чәчте-урды халкым,
Горур булды,
Үз язмышын ятка бирмәде!
Кешеләрнең бүген туган җирдән
Үлемсезлек алган көннәре.

Алар күргән авыр кайгыларны
Онытырмын, димә тиз генә.
...Килгән дошман халкым сөягеннән
һәйкәл куяр өчен үзенә.

Мин туганмын җиргә шул елларда,
Озак яшәремне ил белгән.
Мин туганмын,
Илем дошманнары
Нәкъ мин туган җирдә күмелгән.

Рәхмәт, илем,
Гомер биргәнсең дә,
Йөрәк янган сүнми-югалмый.
Туган җирдә дошман каберләре...
Каберләрдән ирләр үч алмый.

Илен яклап утка кергәннәрне
Илбасарлар җиңәламыни?!
Шундый кешеләрнең нәфрәте
Аны ерак җибәрәмени?!

Без мәңгегә, без мәңгегә монда.
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары! ■

МИНЗӘЛӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ

Әхтәм Зарипов

...Минзәлә театрында эшләү чорым бүген мизгел генә булып тоелса да (8 ай), анда күргән-белгәннәрем, алган тормыш сабакларым иҗади эш белән узган озын-озак гомерем юлында гыйбрәт, чагыштыру маяклары булды. Беренче буразна ничек сызылса, басуың шулай сөрелер, диләр бит.

...Әгәрдә ки күңелемдәгеләрне кәгазьгә төшерергә сүзләрем җитсә, хәтердә уелып калган мизгелләрдә катнашкан фидаилар турында язмакчы булам.

...Сәнгать кешеләре, аерым алганда артистлар турында, аларның теге яки бу спектакльдә рольне ничек башкаруы хакында, ягъни артистның һөнәри камиллегенә бәһа мөһере баскан мәкаләләр күп языла. Алар, кагыйдә буларак, бер калыпта сугыла, «балчыгы» гына үзгә була. Артист урынына рольне машина яки робот башкарса да, шундый ук «кирпечләр» сугылыр иде, ягъни, мәкаләләренең эчтәлеге «ошады»-«ошамады»га кайтып калыр иде. Иҗат әһеленең шәхси сыйфатларына кагылмыйча, аның һөнәри башкару осталыгына гына игътибар һәм бәһа бирү тенденциясе бездә иң киң таралган чир. Кеше һөнәр иясе генә түгел бит, иң элек ул шәхес — кеше!

Шәхес булган кеше өчен язмышындагы теләсә нинди очракта да кешелеген югалтмау мөһим... Һөнәри осталык күзколакка тиз чалына. Күп халыкларны үз сәнгате белән яулап алган талантлары аша беләбез. Алар — җыр, бию осталары, рәссамнар, музыкантлар һәм башка төр һөнәр ияләре. Алар — данлыклылар, дәрәҗәлеләр, исемлеләр... Ә нинди кешеләр? Белмибез.

Әллә шул җырлавын, яисә биюен генә белгәнме? Осталык — яшәүгә җайлашуның бер төре генә ул. Ир икән, ул осталыгына өстәп, хатын алырга, нәселен калдырырга, өй салырга, агач утыртырга, ягъни, кешенең иң табигый бурычларын түләп кенә бу фани дөньядан бакыйлыкка күчәргә тиеш. Ярый әйдә, өй генә түгел — сарайлар салдырсын, агач кына түгел — урман утыртсын, утраулар калдырсын ди. Нәселе калмаса, ул ир — ир түгел, сабын куыгыдай кабартылган, нинди-



Сабир Өметбаев – Бөтенсоюз колхоз-совхоз театрлары фестивалендә бүләк ителгән йөк машинасы – «полуторка» янында. 1939 ел

Хәдичә Сәлимова (сулдан беренче) – хезмәттәшләре белән

дер һөнәргә өйрәтелгән җанлы машина гына булып чыга ул.

Озын гомерле булган кайбер сәнгать әсәрләре сокландырса да, күп чакта бәхәсләр тудыра, кайберләре шиккә дә сала…Чөнки аның иҗатчысында нindидер шик булган, оста булса да, шәхес түгел, кеше булып йөрсә дә, кешелеге шикле…

Язачагым, әйткәнемчә, шиксез чын кешеләр — Минзәлә театрының ике алтын баганасы турында.

…Минзәлә театрының оешуы, яшәве, иҗади хезмәтләре хакында архив материаллары күп. Шушы театрда эшләп киткән драматург Сәет Шәкүров истәлекләре, театр галимәсе Дания Гыймранова хезмәтләре, режиссёр Фәрит Хәбибуллин язмалары, аерым тенденциялелек йогынтылары сизелүгә карамастан, чынбарлык эпизодларына бай статистик-хроникаль чыганаклар.

Мин язачак «мизгелләр» озын-озак иҗади гомеремнең нигезен ягъни, башлангычын тәшкил итә. Һәр нәрсә баштан башлана ич! Купшы сүзләрме? Онытмыйк: иң матур чүлмәк тә гапгади балчыктан ясала, иң озын гомер дә мизгелләр тезмәсеннән тора.

***

…Урта мәктәпне медальгә тәмамлап та, медале миңа тәтемәү сәбәпле, институтка керә алмый калганлыктан, елны бушка уздырмас өчен район агитбригадасында гармунчы-артист булып йөргәндә, Актаныш районының Аеш авылында Минзәлә колхоз-совхоз театры артистлары тарафыннан А.Островскийның «Бирнәсез кыз» әсәре буенча спектакль күрсәтеләчәген белеп алдым… Язмыш бүләге ич бу!

…Безнең бригада ул кич Аештан 10 чакрымнар ераклыктагы Ябалак — Илеш авылы клубында чыгыш ясарга тиеш иде. Нишләргә? Ничек-ничек итәргә? Әгәр мин «Бирнәсез кыз»ны карарга китсәм — үз төркемемә хыянәт итеп, «бирнәсез калам», китмичә, концертта катнашырга калсам — хыялларыма, сугышта үлгән артист абыем васыятьләренә, ниятләремә хыянәт итәм…

Ике хыянәттән беренчесен сайладым — «Бирнәсез кыз»га китәргә булдым.

…1955 нче елның соңгы аеның соңгы атнасы. Алла каргаган буранлы салкын көннәр. Мондый көннәрне безнең әнкәй «урыс өеннән дә чыкмаслык» дия иде.

Аеш авылына җәяү барырлык түгел. Чит колхоздан ат сорап алырлык «рәтем» дә, абруем да юк.

Без концерт куясы клубның мөдире булып эшләүче авылдаш яшьтәшем Радик Сәгадиев (СССРда беренче булып йөрәгенә ясалма клапан куйдырган кеше) ярдәмгә килде: бер «ярты» исәбенә конюхтан ат җиктерүгә иреште. Шулай итеп, минем өчен Радик та тамашачыларына хыянәт итте: концерт буласы кичне клубны (постын!) ташлап китте.

«Тәвәккәл — таш ярган», — диләр. Ярабыз, болай булгач, барабыз! Тик менә спектакльгә өлгерә алырбызмы? Атны кусак та, кумасак та, тизлеген арттыра алмый: юлны буран күмдергән, җиле дә безгә каршы исә.

...Сөн елгасына җиткәндә караңгы да төште; боз өстендә юл югалып, ат хәтеренә генә ышанып ияреpгә калды...

...Күпме барганбыздыр — алда авыл утлары җемелдәде. «Өлгерәбез» дип сөенештек. Тик иртәрәк шатланганбыз — утлар Аешныкы түгел, ә Кәзкәй авылыныкы булып чыкты.

Радикның бу якларда йөргәне юк икән, юлларны да күреп белми. (Атның Кәзкәй аша Актанышка барганы булган).

...Безгә тагы 10 чакрымнар кире якка көрт ерырга насыйп булды...

...«Бирнәсез кыз» яртысына якынлашканда Аеш клубына аяк бастык. Ишек төбендә — контроль (анысы — соңыннан дустыма әвереләчәк рәссам Кәшфи Камалетдинов) «тәнәфестә керерсез» дип бик кәттә-хәтәр торса да, кемлегебезне һәм нигә килүебезне әйткәч, үз яныннан узмый гына карарга рөхсәт итте. Без бәхетле идек.

...Спектакльдән соң миңа инде күптән фатирына кайтып киткән администратор Рәкыйп Шәймөхәммәтовны күрергә һәм Минзәлә театрына эшкә алыну-алынмауны хәл итәргә кирәк иде. Мәсьәләне ничек чишү нечкәлекләренә тукталып тормыйм. Ул чакларда кесә телефоннары юклыкны хәтерләгән кеше күз алдына китерер — Рәкыйп абый әйтүеннән шул аңлашылды: миңа, базага кайтып, Сабир Өметбаевка күренмичә, мәсьәләне чишелгәнгә санап булмый икән...

***

— Ниятең ныклы булса, бер атнадан Минзәләдә булабыз. Квартплатасыз, суточныйсыз, зарплатасыз да эшләргә риза булсаң — керәсең, — диде Сабир агай.

Хәдичә Сәлимова – сәхнәдә

— Ни эшләргә тиеш булам соң мин?

— Нинди эш килеп чыга — шуны...

— Сәхнәдәме?

— Безнең бар эшебез сәхнәдә, энем!

Сәхнәдә эшлисе булгач, ризалашмый кая барыйм?

...Шул Аеш төненнән соң минем өчен маҗаралы яңа тормыш башланды. Кинәт кенә, хыялыма ирешеп, Минзәлә артисты булдым, Аештан соң күрше Илеш районының Исәнбай авылында беренче тукталыш. Аннары — район үзәге Югары Яркәй, Күктау, Исәммәт авыллары... Узган атнада гына шушы авылларда «артистлыгымны» күрсәтеп киткән рядовой солдат кинәт генерал булгандай кабул иттеләр мине. Ишек төбендә «Бирнәсез кыз»га килүчеләрнең билетларын ертып торуымны генерал булуга тиңләүчеләр кемнәр һәм күпме булгадыр, чынбарлыкта солдат булыр өчен дә әле миңа күп тоз ашарга кирәклекне үзем дә күз

алдыма китермәгәнмен. Хәерле булсын... Кирегә юл ябык.

...Колхозларда күпмедер күләмдә шикәр комы бирә башлаганнар иде. Миңа өлеш булмаса да, бүлгәндә исемлеккә кертеп, өлеш чыгаралар.

Сатуда юк нәрсәне табуны администратор Рәкыйп абый Шәймөхәммәтов зур җиңүгә тиңли иде.

Тиңләсен! Шикәрен генә тапсын! Безнең өчен ипине шикәр комына манып чәй эчү — «швед өстәле» инде!

...Башкортстаннан Актаныш районы Байсар авылына күченү өчен олаулар көтәбез. Безне илтергә тиешле олау әйтелгән вакытка түгел — буран туктагач кына килде. Исәммәт белән Байсар арасы 20 чакрым булыр. Ничә олау килергә тиеш булып, ничәсе килүен әйтә алмыйм, әмма безгә әйберләрне генә чанага салып, үзебез җәяү барырга, диделәр. «Үзебез» дигән сүз — яшьләргә генә кагыла булып чыкты. Кыймылдадык. Тау төшкәндә чана артына басарга рөхсәт итәләр... Ә урманда... юлсыз араларда... тәпи-тәпи...

...Театр дөньясында һич кенә дә гафу ителмәс очракларның иң кәттәсе — билгеләнгән спектакльнең өзелүе. Андый «ЧП»лар сирәк булса да, булгалый икән. Әмма театр аркасында түгел — күбрәк транспортка бәйле рәвештә булгалый икән.

...Байсарга авыл өйләрендә утлар сүнгәч кенә барып җителде, спектакль куелмады, план янды, без «сүндек», барыбыз бергә салкын клуб сәхнәсендә кунасыбызны әйттеләр.

Театрларда кабул ителгән тәртип шундый: гастроль бригадалары ирлехатынлы гаиләләрдән төзелә.

Минзәлә театрының иң абруйлы артисткасы Хәдичә апа Сәлимова — театрның баш режиссеры Сабир ага Өметбаевның хатыны. Ә режиссерлар, кагыйдә буларак, гастрольләргә чыкмый, базада икенче бригада белән яңа спектакль әзерләп кала.

...Шунлыктан, күп чакта Хәдичә апа фатирга ялгызы гына төшә. Әбүәп Афзалов-Бәхия Вәлиева, Мөхәррәм Зәйнуллин-Нәзифә Гайнетдинова, Мөхит Кичүбаев-Рабига Шакирова, Шамил Сабиров-Мәбрурә Рәхмәтуллина, Габдулла Шәрифҗанов-Нурия Гыйззәтуллина — аерылмас парлар. (Бу исемлекне яшьрәк парлар белән дә дәвам итәргә булыр иде). Кыскасы, берсе артист булса — икенчесе башка һөнәр иясе булганнар да, театр арбасына җигелеп, йөкне бергә тарта — сәнгатькә хезмәт итә. Әйтик, Рәкыйп абыйның хатыны артистка Җиһан Сәлимова булса, Гомәр Калининнның хатыны — администратор, Әнвәр Фәсхетдиновның җәмәгате, медицина хезмәткәре, һ.б.

Андый гаиләләр бүгенге театрларда да бар һәм бу парлар һәр театрның нигез ниргәләреннән санала.

Югарыда китерелгән парлылар исемлеген язуымның сәбәбе — Байсар клубында куначагыбыз хәл ителгәч, 48 яшьлек Хәдичә апаның: «Әхтәм дигән егетегез минем аркамны җылытып ятса гына клубта кунарга риза», — дип сөрән салуы исемә төшүдән. Аяз көнне күк күкрәдемени!!! Барысы да мине үгетли, «Ризалаш, Хәдичә апа папируз гына тарта, сиңа да «Беломорканал» тарттырыр», — диләр. Көләләрме, шаярталармы, чынлыйлармы — белмим. Аптырыйм, аңламыйм, үртәләм, хурланам, кызарам, бүртенәм, әмма дәшмим.

— Дәшмәү — ризалык билгесе, — ди Әнвәр Фәсхетдинов.

Нәсимә апа Җиһаншинаның «сыңары» Җиһангир ага Җиһаншин, кабынып-кабынмас учакка «кәрәчин» сибеп, сүзне икенчегә бормакчы булды, ахры:

— Хәчтәй, сезнең арканы җылытырга лаек егет түгел ул. Труппага кушылуын юдырмавы сәбәпле, бураннар туктамый, спектаклебез өзелеп, юлыбыз уңмый башлады... Әүвәл өзекне ялгасын, шуннан соң карарбыз... кемнең аркасына нәрсә җитмәвен!.... — диде.

Тәмам буталдым: нинди өзекне, ничек ялгарга?... Шул сорауларга җавап

таба алмый, чи утын тутырылган калай мичне кабызырга маташам: башымны күтәреп карарга хурланам да, куркам да. Бер мәл учагым янып киткәч, әҗәткә акча биреп торучы булса «өзек ялгау» кинаясен гамәлгә ашырырга ризалыгымны белдерергә дип башымны күтәрсәм, барысы да урын хәстәрләп ятканнар, кемгә генә дәшсәм дә уятуым өчен гафу үтенергә кирәк булачак кебек тоелды.

...Яшьлекнең иң авыр үтәлүче гамәле, мөгаен, хатаңны танып, гафу үтенүдер. Аннары уеннан чынны, чыннан уенны аера алмаудыр. Минзәләлеләргә кушылган беренче көннәремдә уеннан чынны аера белмәүдән интегүләрем хәтердә. Байсардан Пучыга күченгәндә дә, Пучыдан Аюга күчкәндә дә, тракторыбыз ватылып, Матвеевка дигән рус авылында кунарга мәҗбүр булуыбызда да мине гаепләделәр. Янәсе, әүлия кебек апайның аркасын җылытудан баш тартканмын да, шуның «кәсәфәтен» күрәбез икән...

Минзәләгә 31 декабрь төнендә кайтып җиттек.

«База» дигәннәре Башкарма комитет урнашкан бинаның аскы катындагы бер бүлмә икән. Фанердан бүленгән почмакта — дирекция.

Декорацияләрне бушатуга, барысы да өйләренә чапты. Сабир абыйны көтеп, Хәдичә апа гына калды.

— Син ни көтәсең, улым? — ди бу миңа.

— Минем барыр урыным юк. Шушында кунам да, иртәгә фатир эзләрмен.

— Монда кундырмаячаклар сине. Үзебезгә алып кайтам. Сабир абыең килсен дә...

...Кәшфи Камалетдинов, рәссам буларак, атып-сатып кына ташлаган декорация детальләрен, реквизит-бутафория нәрсәләрен урнаштырып, җыйнаштырып тоткарланган иде — Хәдичә апа аны чакырып китерде дә:

— Кәшфи, менә бу малайны урнаштырырга кирәк бит, парин... Үзәмә алып кайтырмын дигән идем дә, Сабир абыең һаман килми... Берәр нәрсә булгандыр, мөгаен... Син, бар, илт юньлерәк танышыңа, шәһәр үзеңнеке, тыңларлар.

«Бер кичкә — кер мичкә!» — диләр.

...Кәшфи мине үзләренә алып кайтты, анда пилмән белән сыйладылар. Мунча кертеп, каз мамыклы түшәк җәйгән урында йоклаттылар. Икенче көнне, ягъни яңа 1956 елның 1 гыйнварында мин талонга икмәк сатыла торган «Хлебный магазин» янәшәсендәге фатирга урнаштым.

...Минзәләгә килеп урнашкач та күргән-белгәннәрем күктән җиргә төшереп күзләремне ачса да, күңелемне төшереп, дәртемне сүндерә алмады.

Үземне белә башлаганнан алып, Минзәлә театрының авылыбызга килеп куйган барлык спектакльләрен карап барган, һәр артисткасын фәрештәгә, ир артистларын пәйгамбәрләргә тиңләгән авыл малаеның «Исполком подвалында» (базада) ишеткәннәре фәрештә-пәйгамбәрләрнең дә шатлана, кайгыра, мактана, хурлана, әрләшә, елый, көлә торган җир кешеләре икәнен күрсәтте. Аларга да акча җитми икән, ашау-эчү кирәк икән. Итек-читекләрен яңарту, торыр урыннарын ремонтлау кирәк икән... Барысы да гап-гади кеше омтылышлары, кеше уйлары, кеше теләкләре, кеше өметләре...

Шушы гап-гади кешеләр Гольдони, Шиллер, Мольер, Островский, Гоголь, Камал, Тинчурин, Әминов, Җаффарлы персонажларына әверелеп, авыл халкына могҗизалар күрсәтә, кайгы-хәсрәтләрен оныттыра, бәхетле мизгелләр бүләк итә икән.

Болар турында читтән ишетеп, күреп яисә укып белсәм дә, театрның эченнән карап аны аңлау артист хезмәтенең үтә дә җаваплы иҗат булуына инануда һәм профессиямне сайлауда бик кирәкле шәй булгандыр дип уйлыйм.

...Алда исемнәрен атап киткән кемне генә алып карасак та, алар био-

графияле, тарихлы кешеләр. Заман үлчәүләренә салып караганда, алар, бәлкем, геройда түгелдер. Ләкин аларның һәркайсы — кеше булуына тап төшермичә бу дөньядан ак йөз белән киткән олы шәхесләр. Һәркайсы хакында мавыгып укырлык әсәрләр язарга булыр иде.

Әмма бу язмада Минзәлә театрының Атасы һәм Анасы дип аталырга лаеклы ике шәхескә генә тукталам. Алар: Сабир Өметбаев — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай бүләге лауреаты, икенчесе — Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Хәдичә Сәлимова. Икесе дә театрга нигез салучылар, икесе дә энтузиастлар, чын патриотлар.

Хәдичә апа Сәлимова...

Ул Свердловск өлкәсендәге Лысьва шәһәрендә туып үскән, шунда педагогия техникумында мөгаллимә профессиясен үзләштергән; һөнәре буенча дүрт ел эшләгәч, «театр җене» кагылып, Казанга килгән; тагын дүрт ел театр техникумында укып, Академия театрына алынган «фанатичка».

Нәфига Арапова, Гөлсем Болгарская, Нәгыймә Таждарова, Шакир Шамильский, Кәрим Тинчуриннарның һәркайсы белән үз булып, иярләшеп беткәч кенә Минзәлә колхоз-совхоз театрын оештырырга ире Сабир Өметбаев белән Чистайга китә. Батырлык димәсәк тә, шуңа тиң адым бу. Гаҗәеп очраклылык димме, мистикамы — театр оештыру турындагы әмер 1935 елның 15 нче июлендә чыга. Минем дә туган көнем — 15 июль, 1935 ел.

...Хәдичә апа катнашкан спектакльләрдән миңа «Гаепсездән гаеплеләр» дә Кручининаны, «Мәкер һәм мәхәббәт»тә Леди Микфордны, «Балан куаклыгы»нда Ковшикны, «Язылмаган законнар»да Майлыбикә образларын авыл сәхнәсендә күрү насыйп булды. «Кара бүре»дән өзекне исә кино тасмасына төшердек.

Кем турында гына фикер йөртсәк тә, без аның эшләреннән тыш синең үзеңә мөнәсәбәтеннән — мөгамәләсеннән чыгасың, шуларга таянасың.

Хәдичә апаны театрның һәр артисты, һәр хезмәткәре гадилеге, ихласлылыгы, «эчендәге — тышында» булганы өчен үз итеп, аныңча эшләргә, аны кыен хәлдә калдырмаска тырыша иде...

Минзәлә театрында бик аз ара вакыт эшләсәм дә, Хәдичә апаның киләчәгемне планлаштыруга кагылышлы йогынтысы әһәмиятле роль уйнады: ул миңа бер урынга беркеп «катмаска» кирәклекне төшендерде, укырга китү зарурлыгына ышандырды, Мәскәүдә татар студиясендә уку өчен студентлар җыю буенча конкурс булачагын, шуңа игълан чыгачагын әйтте. Нинди каналлар буенча белгәндер — шул игълан басылган газета ертыгын миңа «Хәдичә ападан бүләк» — дип китереп бирделәр.

Бу безнең бригаданың «Ни чәчсәң — шуны урырсың» дигән пьеса буенча спектакльгә репетицияләр вакытында иде.

Баш рольдә уйнаучы өлкән актриса роленең сүзләрен белми, бутала, башкаларны да бутый, игътибарсыз. Режиссёр Сабир абый да, катнашучы артистлар да минем хатын ролендә уйнаучы бу артистканы түгел, ә сүзләрне яхшы белгән, режиссер кушканча уйнарга тырышкан Әхтәмне «сүгәләр», «бәйләнәләр», юктан хата табалар, хатынны ничек яратырга кирәклеге турында вәгазь укыйлар; кыскасы, мине өйрәтүдән мәзәк чыгаралар. Хурлансам, кимсенсәм дә, үземне яклап сүзката алмыйм. Хатыным ролендә уйнаучы, гаепле булса да, сүз әйтми, мине дә якламый, дәшмичә кызарыпбүртенеп утыра (исемен атамыйм: оныклары бар). Ахырда түземем җитми, «Йә — хатыным ролендә уйнаучыны алыштырыгыз, йә — миннән рольне алып, башкага бирегез. Шулай эшләмәсәгез, артистлыктан чыгарыгыз», — дигән гариза язып бирәм

Рәшит Мәрдеханов, Рәшит Вәлиев һәм Рәкыйп Шәймөхәммәтов тамашачылар арасында

дә, авылыма кайтып китәм», — дидем бер тында. Сабир абый сабыр гына көлде дә:

— Синең әле артистлыкка кабул ителгәнең дә юк, энем. Син сынау шарты белән эшләүче монтажник идең. Бүген сынауны уздым дип бел. Өмет бар. Өметбай сүзе шушы: приказ чыгарып, бүгеннән артист штатына күчерерләр, — диде дә, тәнәфескә тукталдык. Сабир абыйны партҗыелышка дәштеләр…

***

…Шәхес культы фаш ителүгә, беренчеләрдән булып, Сабир абый Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен куйды. 1956 елның язы. Бөтен театр дөньясы тернәкләнгән яңа чор башланачак.

Җәй буе театр шул «Зәңгәр шәл» спектакле белән гастрольләрдә йөрде. Хәдичә апа ишанның беренче хатыны ролендә, мин шәкерт ролен башкардык. Сабир абый тагын өендә ялгызы калды…

Август ахырында мин Мәскәүгә киттем. Шуннан соң Минзәлә театры белән бәйләнешләр өзелде…

***

1967 елда Академия театрының «Әни килде» спектакле белән җәйге гастрольләрдә йөрибез. Авылларда уйныйбыз да, Әлмәткә кайтып кунабыз.

Беркөн көндезен, вакыт табып, мунчага барырга булдык. Иптәшкә Николай Дунаев та иярде бугай.

…Эссе көн. Мунчада бездән башка бер генә кеше утыра. Бер аягын калай таздагы суга тыккан, икенчесен, эскәмиягә куеп, үткен пәке белән аны туный, ягъни, кисә. Кызыксынып, карамакчы булып, үзен-үзе кисүченең янына бардык. Аяк табанында була торган гадәттәге үкчә сөялен генә кисү түгел иде бу — бөтен табанын туный абзый. Безнең аптырап карап торуыбызны күрде дә башын күтәрде карт… Һәм мин шунда, таеп, чак егылмый калдым.

— Нәрсәдән курыктың? — ди абзый.

— Курку түгел бу, Сабир абый,

сезнең белән көрешмәкче булган идем. Исәнмесез, саумысез?..

— Саулыгына чыдарга булыр иде, сөял йөдәтә... вәгаләйкемәссәлам... Күңелдәге сөялдән шулай котылып булса икән... Сезнең гастрольләрдә икәнегезне беләм, спектаклегезне карадым...

— Нигә сәхнә артына кермәдегез?

— Мин хәзер элекке мин түгел шул, күренеп, сүз куертасым килмәде. Кичерерсез дип беләм.

— Хәдичә апа да карадымы спектакльне?

— Хәдичә апагыз Минзәләдә, мин икенче хатын белән... монда...

Сүз бетте, җир упты... Ике як та сүзне ничек дәвам итәргә белми интегә.

— Кунакка чакырыр идем — хатын авырый. Кунакчыл да түгел. Үзем дә... — ди агаем.

— Үзегез гостиницага килегез! Очрашуны билгеләп үтәрбез, узган-күргәннәр турында сөйләшербез — дим.

— Шул узганнар турында гына сөйләшмәсәк, минем киләчәгем дә, хәзерге хәлем дә кеше кызыгырлык түгел.

— Бу очрашу үзе кызык, үзе кадерле!

— Шатлык китергән очрашу гына кадерле була, — дип, ниһаять, ачылып китте Сабир ага, — онытылмаслык булып истә кала. 1944 елның иртә килгән язы иде... Без 1 нче Украина фронты сугышчылары... Кем инициативасы белән булгандыр, татар артистлары концерт куярга килә, диделәр. Тере артистларны күрәсе килүемне сөйләмәсәм дә, аңларсыз... Әмма, кемне очратуымны әйткәч, егылып китмәгез: сәхнәдә баянчы Рокыя Ибраһимова! Ул бит минем белән театр труппасын оештыруда күп көч куйган беренче музыкант! Менә бу инде чын очрашу, бәхетле очрашу, истәлекле очрашу иде... Хәзер мин очрашулардан качам, мунчага да кеше аз вакыттарак килергә тырышам.

Мин түзмәдем, сорарга җөрьәт иттем: — Нигә шулай, ничек шулай булып чыкты соң тормышыгыз?

Бу сораудан соң Сабир абый коенып-юынып килде, озак кына уйланып утырды, безгә дә утырырга кушты.

— «На ногах правды нет», ди урыс. Кама Тамагы районы малае булсам да, мин урыс арасында эшләп, урыс белән дус булып, урыста укып һөнәр үзләштердем. 1934 елда Мәскәүдән Казанга кайткач, Хәдичә белән кушылдык, гаилә кордык, улыбыз туды. Күрелде инде... Бары — бергә, югы — уртак булды. Мин рус классикасыннан Толстойга табынган кеше... Гомерем буе, шушы даһи кебек, гаилә ныклыгы өчен көрәшеп, ныклы гаиләләргә мәдһия җырладым. Спектакльләремдә.

— «Язылмаган законнарны», «Сәвия»не мин дә карадым...

— Барысында да булмаса да, күбесендә гаиләсен таркатуда гаепленең сәбәпләрен күрсәтергә тырыштым... Ә менә үз гаиләмә игътибарым җитмәгән...

— Ягъни?

— Толстой гаиләсен ташлап киткән Король Лирны кабул итә алмый. «Ничек инде шундый титан акыл иясе Лирдан гаилә таркаттыра?» — дип, Шекспирны сүгә. Ә бит гомеренең ахырында даһи Толстой үзе, бар мөлкәтен балаларына бүлгәләп, гаиләсеннән китеп, тимер юл станциясендә үлә... Моны, заочно булса да, Шекспир даһиеның җиңүе, диләр. Минем очракта җиңүче юк. Ә... җиңелүчеләр — һәммәбез...

— Сезнең кебекләр дөньяда бик күп, Сабир абый, үзегезне җиңелгәнгә санамагыз... «Көрәш дәвам итә!» — диегез.

— Ялгышым да, язмышым да шушыдыр. Зинһар, сөйләтмәгез. Хәдичә апагызны очратсагыз, миннән сәлам әйтегез. Егет ул! Егет булып калсын... Бигайбә...

Шуннан артык сүз әйттерә алмадык Сабир абыйдан.

Сүз әйтмәсә дә, Минзәләдән китүен, аерылышуын авыр кичергәнлеге кыяфәтенә чыккан иде...

2012 елның 20 декабрендә Минзәлә шәһәрендә Сабир Өметбаевка бюст – һәйкәл кую тантанасы булды. Һәйкәл Минзәлә районының элеккеге район хакимият башлыгы Рәсим Садыйков һәм театр директоры Роберт Шәймәрдәновның зур тырышлыгы белән эшләнде. Бюст-һәйкәлнең авторы – Халит Миңнегалиев

Мин аны бүтән очратмадым. Әмма абруйлы исеме, иҗади алымнары һәрчак күңелемдә калды.

***

Бүген Минзәлә колхоз-совхоз театры оештыручысы, озак еллар директоры һәм баш режиссеры хөрмәтенә «Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» дип атала. Остаз исемендәге премия булдырылган.

Көчле характерлы, үзенчәлекле рольләр иҗат итеп, шушы театрда бөтен гомере буе эшләгән артисткаларны бүләкләргә Хәдичә Сәлимова премиясе дә булдырылса, нур өстенә нур булыр иде. Ул аңа лаек шәхес.

Бүгенге театр җитәкчеләренең бу изге гамәлгә тәвәккәллеге дә, көчләре дә җитәрлек. Сабир абый әйткәндәй, «өмет бар» Өметбаев театрында!

Аерылышуларына да карамастан, Хәдичә апа да, Сабир абый да шәхси мөгамәләнең эшкә комачаулавына юл куймый... Әйтерсең лә, берни булмаган! Һәрвакыттагыча, дустанә сөйләшү, хәл белешү, киңәшләшү...

— Хәдичә апа Сабир абый турында гайбәткә юл куймаса, Сабир абый исә Хәдичә апага хөрмәтендә һәрчак рыцарь булып калды, — ди Татарстанның халык артисткасы Илүсә Бәдриева. Башкалар хор белән аңа кушыла. Әйе... Аларның бер-берләренә мөнәсәбәте уникаль дә, сокланырлык ихлас та булуы бәхәссез. Әгәр алар тормышыннан үрнәк алып, пьеса язучы булса, аның буенча куелган спектакль, шиксез, театр репертуарында озак сакланыр һәм сокландырыр иде.

Язмамда бу ике фидакарьнең шәхси тормышларында «казынуым» өчен аларның рухлары алдында гафу үтенеп, башымны иям, кичерегез, дим, һәм... Хатирәләрем дога булып ирешсә иде, дим. Бергәлектә дә, аерылышкач та шәхесләреннән түбән төшмәделәр алар, ирешкән биеклекләрендә калдылар һәм шул биеклектә яшиләр, яшәрләр, яшәсеннәр! ■

«ИДЕЛ» БИТ УЛ... «ИДЕЛ» БИТ УЛ!

Идел суы ага торып,
Җилкән көймә бара торып,
Идел кичкән ир-егетләр
Чын дусларын таба торып!..
Гөлшат Зәйнашева

1997 елда Икенче Бөтендөнья Татар конгрессы делегатлары һәм сигезенче Татар яшьләре көннәрендә катнашучы яшьләр, берләшеп, «түгәрәк өстәл» җыенында яшьләрнең дәүләт дәрәҗәсендә эшли торган үз оешмасын булдыру хакында резолюция кабул итә.

Рәсми рәвештә әлеге оешма «Идел» исеме белән 1999 елның 22 июнь көнендә теркәлә. «Идел» яшьләр үзәге ел әйләнәсендә регионара 8 зур чараны тиешле югарылыкта оештырып килә. Алар арасында — оешманың үзеннән дә күпкә олырак булган «Татар яшьләре көннәре» җыены, балалар һәм яшьләр өчен «Дулкыннар» конкурсы, Халыкара «Максат» яшьләр фестивале, «Милләтебез хәзинәләре» профиль сменасы, «Иделем акчарлагы» яшь язучылар бәйгесе, Яшь татар лидеры мәктәбе, Татар балалар лидеры мәктәбе һәм «Тарих эзләреннән» Бөтенроссия рәсемнәр бәйгесе. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы карамагында эшләп килүче «Идел» яшьләр үзәге быел үзенең 15 еллыгын бәйрәм итә.

Искәртеп узуыбызча, «Идел»нең чишмә башы сигезенче Татар яшьләре көннәреннән башланып китә. Сүзне шул еллардан башлыйк.

1990 нчы еллар — татар яшьләренең

милли рух белән сугарылган дәвере, заман вазгыяте таләпләренә җавап итеп бер төркем яшьләр, студентлар татар яшьләре өчен зур җыен, танышу, аралашу, элемтәләр булдыру, хезмәттәшлек, тәҗрибә белән алмашу мәйданын булдыру нияте белән янып йөри башлый һәм аларның әлеге гүзәл хыялы тормышка аша да. *«Университетта узган җыелышларның берсенә кәчтүм-чалбар кигән, галстук таккан Илдар Гыйльметдинов килеп керде. Ул Татарстан өлкә комсомол комитетының икенче секретаре итеп сайланган гына иде... Илдарның иң беренче тәкъдиме үк эшлекле булып чыкты — Татар яшьләре көннәре оештырыла икән, яшьләрне Болгарга алып бару өчен «Метеор» алуда комсомол ярдәм итә алачак, ә инде бу көннәрне Казан янындагы «Волга» лагеренда үткәрергә мөмкин. Шулай итеп, чараны 17-28 июнь көннәрендә үткәрергә тәгаенләп куйдык»,* — дип искә ала «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе директоры **Рим ГЫЙЛЬФАНОВ**.

«Татар яшьләре көннәре чын мәгънәсендә татарларны уятып җибәрде.

Бу көннәр татар яшьләренең генә түгел, бөтен төрки яшьләрнең берләшүенең дә башы иде. Татар яшьләре берлеге «Азатлык», «Төрки яшьләр берлеге» шушыннан соң оешты» — дип сөйли тәрҗемәче, Австралия төрки халыклар ассамблеясы җитәкчесе **Ирек ГАРИПОВ**.

Быел Татар яшьләре көннәре 24 нче тапкыр оештырыла. Әлеге зур җыенны хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татар Федераль милли-мәдәни автономиясе, «Идел» яшьләр үзәге бергә оештыра.

Татар яшьләре көннәре иң актив һәм максатчан татар яшьләрен туплаучы проект. 24 еллык тарихы эчендә әлеге җыен Россия Федерациясенең 45 регионыннан һәм 15 чит илдән җыелган татар яшьләрен бергә бер мәйданга туплый алды. Татар яшьләре көннәренең нәтиҗәле эшчәлеген 20дән артык региональ татар яшьләре оешмалары барлыкка килү дә раслый. Шулай ук Татар яшьләре көннәре 37 яшь татар парының тормышын бергә

Илдар ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ,
Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе, Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы депутаты:

1 нче Татар яшьләре көннәрен оештырып йөргәем әле дә күз алдымда тора. Ул чакта милли рух белән ялкынланып йөрүче татар яшьләре, татар студентлары аеруча күп иде. 1990 елдан башлап 1997 елга кадәр без барыбыз да яшьләрнең дәүләт дәрәҗәсендә эшли торган оешмасын булдыру теләге белән яна идек, һәм, ниһаять, Икенче Бөтендөнья Татар конгрессы делегатлары, 8 нче Татар яшьләре көннәрендә катнашучылар тарафыннан резолюция кабул ителгәч, без әлеге хыялга тагын бер адым якынайдык. Ләкин оешманы дәүләт дәрәҗәсендә теркәү үз кыенлыкларын күрсәтте, бары тик 2 ел узгач кына — 1999 елның 22 июнендә «Идел» яшьләр үзәге Татар иленә аваз салды.

Хөрмәтле «Идел» яшьләр үзәге, бөтен дөньяга сибелгән татар яшьләрен гел шатландырып торыгыз, киләчәктә бергә-бергә яңадан-яңа күркәм чаралар уздырырга язсын безгә. Барлык хезмәткәрләрегезгә саулык-сәламәтлек, сабырлык һәм уңышлар телим.

***Рафис БОРҺАНОВ,** Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры:*

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы карамагындагы оешмалар исемлегендә «Идел» яшьләр үзәге иң продуктив эшләүче үзәкләрнең берсе. Нибары дүрт кешедән торган әлеге коллектив Халыкара, төбәкара чараларны оештыру эшләрен тиешле югарылыкта гамәлгә ашырып килә. Шунысы да шатландыра: «Идел» яшьләр үзәгенең нәтиҗәле эшчәнлеген төбәкләрдәге татар яшьләре оешмалары да югары бәяли.

Хәзерге вакытта «Идел»нең 8 зур проекты эшләп килә, киләчәктә уртак тырышлыгыбыз белән әлеге сан зураер, гамәли офыклар киңәер дигән өметтә калып, яшьләр үзәгенең 15 еллык түгәрәк датасы белән котлыйм, барлык хезмәткәрләренә дә саулык-сәламәтлек, имин көннәр һәм яңадан-яңа идеяләр теләп калам.

бәйләде. 24 ел эчендә Татар яшьләре көннәрендә 10 меңнән артык егет-кыз катнашты.

«Идел»нең чираттагы иң эре һәм Россия регионнарындагы татар балалары арасында иң популяр проекты — «Милләтебез хәзинәләре» профиль сменасы.

«Милләтебез хәзинәләре» сменасының максаты — Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче татар балаларын берләштерү, аларда туган телгә, халкыбызның мәдәниятенә, тарихына, гореф-гадәтләренә мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү.

«Милләтебез хәзинәләре» сменасының программасы гаять кызыклы һәм бай эчтәлекле. Балаларга көн саен татар теле дәресе укытыла. Вокал, бию, тарих, кул эшләре, журналистика, милли көрәш, татар ашлары буенча оештырылган иҗат остаханәләрендә алар яңа һөнәрләргә өйрәнә, шул өлкәдәге сәләтләрен камилләштерә. Смена дәвамында үткәрелгән «Татар гүзәле», «Супер малай», «Танцпол йолдызы», «Моңлы сандугач» кебек конкурсларда балалар үзара көч сынаша, иҗади мөмкинлекләрен чынга ашыра. Лагерь кысаларында үткәрелгән «Сабантуй», «Аулак өй» кебек чараларда яшь милләттәшләребез якыннан халкыбызның милли традицияләре, гореф-гадәтләре белән таныша. Шулай ук алар волейбол, футбол, өстәл теннисы, шахмат кебек спорт ярышларында да катнашырга өлгерә. Моннан тыш башкалабыз Казанның тарихи урыннары буенча экскурсияләр оештыру, музей-театрларга бару, борынгы Болгар шәһәренең истәлекле урыннарына сәяхәт кылу каралган.

«Милләтебез хәзинәләре» сменасына ел саен Россиянең 20дән артык төбәгеннән татар баласы җыела. Моннан тыш төрле елларда Үзбәкстан, Казахстан, Латвия, Литвадан килгән яшь милләттәшләребез үзләренең тарихи Ватаннарында булып китте.

Иделем акчарлагы — яшь язучылар бәйгесе

● «Иделем акчарлагы» яшь язучылар конкурсы 2000 елның беренче сентябреннән бирле уздырыла. Биредә, 14-30 яшьләрдәге татар телендә иҗат итүче яшь язучылар, шагыйрьләр, драматурглар катнаша.

«Иделем акчарлагы» конкурсының максаты — яшь буын арасыннан сәләтле каләм тибрәтүчеләрне эзләү, барлау, аларга киләчәктә үзләрен күрсәтү һәм үсү өчен шартлар тудыру. Конкурсның нәтиҗәсе булып, бәйгедән соң жюри әгъзалары тарафыннан яхшы дип табылган әсәрләр махсус җыентыкта урын ала. Үзенең уздырылу тарихында «Иделем акчарлагы» әдәби мәктәбен 2 меңнән артык яшь каләм тибрәтүче узды.

«Әлеге конкурс — бик кирәкле гамәл. Яшь кеше һәрвакытта да ярдәмгә мохтаҗ. Бу яшь язучыларга да кагыла.

Мин хәзерге яшьләргә карап көнләшәм дә, сокланам да. Алар безгә караганда күпкә гыйлемлерәк. Мин аларны бер-берсенә охшаган дип әйтмим, һәр иҗат кешесе — индивидуаль шәхес. Иҗат кешеләре бергәбер йодрык булып туплангач, бик зур көч тәшкил итә. Әдәбият бит ул шигырь язу, әсәр иҗат итү генә түгел. Тукай әйтмешли, язучы — сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә. Иҗади яшьләрнең бер тирәгә тупла-

***Миләүшә ШАРАПОВА,** Татар федераль милли-мәдәни автономиясенең аппарат җитәкчесе, 1999-2013 елларда «Идел» яшьләр үзәге директоры*

«Идел» яшьләр үзәгенең төп эшчәнлеге булып регионнардагы татар балалары, татар яшьләре белән эшләү тора. Татар яшьләре көннәре, «Милләтебез хәзинәләре» профиль сменасы, «Изге Болгар серләре», Яшь татар лидеры һәм Татар балалар лидеры мәктәпләре шушы эшчәнлекнең нәтиҗәсе.

Читкә сибелгән татар балаларын бергә туплап, аларның хис-кичерешләре белән бергә яшәү — оештыручылар өчен иң шатлыклы халәттер. Чөнки Татар яшьләре көннәренә, лидерлар мәктәбенә, лагерьга җыелган милләттәшләребез кызыксынып татар телен, татар тарихын, милли биюләрне өйрәнә, татар зыялылары белән очраша, республикабызның тарихи-истәлекле урыннарына сәфәр кыла. Смена ахырында аларның күзендә горурлык, татарлык уты балкый. Алар бер-берсеннән аерылып китәргә теләми, болар барысы да башкарылган хезмәтнең нәтиҗәлелеген күрсәтә дә инде.

нуы татарның киләчәккә баруына зур куәт бирәчәк», — ди шагыйрь, Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе **Разил ВӘЛИЕВ**.

● 2006 елдан башлап Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, «Идел» яшьләр үзәге Республикакүләм «Дулкыннар» конкурсын оештыра.

Аның төп максаты: балалар һәм үсмерләрдә Ватанга карата мәхәббәт, күренекле шәхесләрнең тормышы һәм иҗаты үрнәгендә милли үзаң тәрбияләү.

Бу чара Татарстан Республикасында яшәүче талантлы яшьләребезне барлау, һәм аларга ярдәм итү, иҗат итү өчен шартлар тудыру, иҗади һәм һөнәри элемтәләр урнаштыру, милли мәдәниятебезне популярлаштыру, яшь талантларның иҗатын пропагандалауны да күздә тота.

Узган елларда бәйге Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Гөлшат Зәйнашева, Фәнис Яруллин, Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Мансур Мозаффаров, Фәрит Яруллин кебек татарның асыл шәхесләренә багышлап, аларның түгәрәк даталарына туры китереп, шулай ук Татарстан Республикасында игълан ителгән тарихи-мәдәни мирас елына багышлап үткәрелде. Әлеге конкурс турындагы тәэсирләрен, мәрхүм **Фәнис ЯРУЛЛИН** үзенең көндәлегенә түбәндәгечә теркәп калдырган: *«Филармония залына барып, 4 сәгатькә якын утырып кайттым. Анда минем иҗат конкурсының финал концерты булды. Бу «Дулкыннар» конкурсын «Идел» яшьләр үзәге әзерли. Концерт вакытында мин шаккатып утырдым. Талантлы балалар бик күп икән! Балаларны өч төркемгә бүлгәннәр: иң кечкенәләр, аннан берәз зурраклар һәм өлкән класс укучылары. Мин 70 яшьлек юбилейдан да мондый зур канәгатьлек алмаган идем».*

Миңгол ГАЛИЕВ, Татарстанның халык артисты, «Дулкыннар» конкурсының жюри әгъзасы: *«Күп чараларны, конкурсларны күргәнем бар. Әмма кайберсе, җиренә җиткереп эшләнә кебек тоелса да, җансыз була. Бу конкурс — «тере». «Идел» яшьләр үзәге бик кирәкле, бик зур рухи тәрбия эшләре алып бара».*

● Халыкара «Максат» яшьләр фестивале җиде ел уздырылган Мөселман яшьләре фестиваленең дәвамы булып тора. Чараны оештыручылар фестивальнең масштабын һәм географиясен киңәйтеп, аңа дөньяви һәм фәнни төсмер өстәп, ватандашларны традицион дини-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләргә тарту максатын куйды.

Шунысын да искәртеп әйтү кирәк, I Мөселман яшьләре фестивале XVII Татар яшьләре көннәре кысаларында узды. 2008 елдан башлап, ул мөстәкыйль рәвештә үткәрелә башлады. 2014 елдан фестивальгә рәсми рәвештә «Максат» дигән исем бирелде.

● «Яшь татар лидеры» мәктәбенең максаты — чит төбәкләрдәге татар яшьләре оешмаларының лидерларын барлау, аларның профессиональ осталыгын тагын да камилләштерү, белемнәрен үстерү. Әлеге мәктәп Татар яшьләре көннәре делегатларының инициативасы белән булдырыла.

«Яшь татар лидеры» мәктәбенең программасында: лекция һәм семинарлар; түгәрәк өстәлләр, диспутлар; РФ төбәкләре, чит илләрдәге татар яшьләр оешмаларына медодик һәм гамәли булышлык күрсәтү.

«Яшь татар лидеры» мәктәбенең бурычлары: яшь лидерларны төрле юнәлешләр буенча укыту базасы булдыру; татар яшьләр оешмаларының казанышлары белән танышу, уңышлы эшчәнлек тәҗрибәсен җәелдерү; татар яшьләр оешмалары җитәкчеләре һәм лидерларының актив эшчәнлеген стимуллаштыру; регионнардан килгән яшь лидерларга тәҗрибә уртаклашу өчен шартлар булдыру.

Беренче тапкыр «Яшь татар ли-

Ләйсән САФИНА,
«Идел» яшьләр үзәге директоры

Халыкара һәм республикакүләм чараларны бер көндә генә әзерләп бетереп булмый, бу зур тырышлык һәм озак вакыт таләп итә торган процесс. Һәрхәлдә, бер проектка 2-3 ай алдан әзерләнә башлыйбыз. Әлбәттә, «Идел»дә эшләмәгән кеше оештыру эшчәнлегенең бөтен нечкәлекләренә кадәр аңлап та бетерә алмас.

1999 елдан, ягъни «Идел» яшьләр үзәге оешудан башлап, без Татар яшьләре көннәренең дә рәсми оештыручылары булып торабыз, әлеге мәртәбәле җыен быел 24 нче тапкыр узачак. Быел «Тарих эзләреннән» Бөтенроссия рәсемнәр бәйгесе икенче тапкыр оештырыла. Оешмабызның нәтиҗәле эшчәнлеге — Россия төбәкләрендә соңгы елларда барлыкка килүче татар яшьләре оешмаларының артуы. Төбәкләрдә хәзерге вакытта ике дистәгә якын татар яшьләре оешмасы эшли, мисал өчен — Удмуртия республикасының «Иман», Новосибирск өлкәсенең «Алтын йолдыз», Владимир өлкәсенең «Бәхет», Самараның «Дуслык», Саратов өлкәсенең «Сарытау» оешмалары. Ә иң шатландырганы — әлеге оешмаларның күпчелеген безнең «Милләтебез хәзинәләре» профиль сменасыннан, Татар яшьләре көннәреннән, Лидер мәктәпләреннән үсеп чыккан яшьләребез җитәкли. Россиянең милләттәшләребез яши торган төбәкләрендә татар яшьләре оешмалары җиң сызганып эшкә чумды: «Татар мәдәнияте көннәре», «Татар чәе», «Татар музыкасы», «Татар киносы» кичәләре, «Чәк-чәк party», «Татар кызы», «Татар егете», «Фотойөгереш», «Татар party» дискотекасы — эшчәнлекнең горурланырлык нәтиҗәсе.

Милли үзаң формалаштыруда «Идел» яшьләр үзәге зур бер этәргеч, көчле, үз сүзен әйтә белә торган актив буынны тәрбияләүдә лаеклы урынын алып тора.

деры» мәктәбе 2009 елда үткәрелде һәм анда татар яшьләре оешмалары җитәкчеләре җыелды. 2010 елда — «PR (Public relations). Җәмәгатьчелек белән элемтә», 2011 елда — «Волонтёрлык һәм балалар белән эшләү», 2012 елда — «Эшмәкәрлек», 2013 елда — «Яшьләр белән эшләүдә инновацион технологияләр» юнәлеше буенча яшь лидерлар очрашты.

***

Татар яшьләре оешмалары белән тыгыз элемтәдә булган актив татар балаларын барлау, аларга методик булышлык күрсәтү, белемнәрен үстерү, татар милли-мәдәни автономияләр каршында татар балалары белән эшләү буенча аерым юнәлеш булдыру максатында һәр елның ноябрь аенда «Татар балалар лидеры» мәктәбе уздырыла.

«Татар балалар лидеры» мәктәбендә лекция һәм семинарлар, түгәрәк өстәлләр, диспутлар, уен-дискуссияләр, төрле викториналар, татар теле һәм тарихы буенча дәресләр, татар зыялылары белән очрашулар уздыру күздә тотыла.

«Идел» яшьләр үзәге лидер балалар өчен уку-укыту базасын формалаштыру, казанышларны карау, уңышлы эш тәҗрибәсен тарату, милли кыйммәтләрне саклау юлында лидер балаларның актив башлангычларын стимуллаштыру, төрле төбәкләрдән килгән лидер балаларга мәгълүмат һәм тәҗрибә уртаклашу өчен шартлар булдыру, укытучылар составы белән тәэмин итүне үз алларына бурыч итеп куя.

«Татар балалар лидеры» мәктәбенә 8-11 сыйныфларда укучы һәм үзләре яшәгән төбәкнең иҗтимагый, мәдәни тормышында актив катнашкан балалар килә. Шулай ук бирегә «Милләтебез хәзинәләре» профиль сменасында активлык күрсәткән балалар да чакырыла.

***

«Тарих эзләреннән» дип аталучы Бөтенроссия рәсемнәр бәйгесе «Идел» яшьләр үзәгенең иң яшь проекты, ул әлегә ике тапкыр гына уздырылды. Әлеге чараның төп максаты — Россия тарихы контекстында татар халкы тарихын өйрәнү дәрәҗәсен арттыру, үсеп килүче буында милли үзаң тәрбияләү, балаларны иҗатка якынайту.

Әлеге бәйге үз эченә түбәндәге бурычларны куя: Россия Федерациясе регионнарындагы талантлы балаларны ачыклау һәм аларның иҗади сәнгатен үстерүгә ярдәм итү; балаларның һәм үсмерләрнең игътибарын татар халкы тарихына юнәлтү; иҗатта үз-үзләрен күрсәтү өчен шартлар тудыру; милли мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне популярлаштыру һәм пропагандалау.

Ике ел дәвамында бәйгегә 400гә якын эш кабул ителгән. «Идел» яшьләр үзәге директоры Ләйсән Сафина искәртеп узганча, бәйгегә Росиянең 16 регионыннан 227 эш кабул ителгән, шуларның 100дән артыгы Пенза өлкәсеннән килгән. Конкурста татар балалары гына түгел, ә казах һәм азәрбайҗан балалары ясаган рәсемнәр дә катнашкан.

Татарстан Республикасының рәссамнар берлеге рәисе, конкурсның жюри әгъзасы **Зөфәр ГЫЙМАЕВ** бәйге турында түбәндәге фикерләрен җиткерде: *«Балалар ясаган рәсемнәрне бәяләү берүк вакытта җиңел дә, авыр да. Әлеге эшнең авырлыгы шунда ки, бер баланы да үпкәләтәсе килми, һәркайсына урын бирәсе килә. Ә җиңеллеге шунда, рәсемгә карап аның кайда бала үзе ясаганлыгы, ә кайда аңа олылар ярдәм иткәнлеге ачык сизелә. Без балаларның тулысынча үзе ясаган картиналарына өстенлек бирдек. Кайбер яшь рәссамнар рәсем ясауның җиңел юлын сайлаган, алар әзер картиналарның күчермәләрен ясаган, мондый эшләр 20дән артык иде һәм алар бәяләнмәде».*

Ел әйләнәсендә шушы сигез проект, бер уйлаганда бу әллә ни зур эш тә түгел кебек, ләкин «Идел» яшьләр үзәгенең 4 кешедән генә торуын исәпкә алсак, бу башка сыймаслык, көн-төн янып йөрү һәм тырышлык таләп итүче хезмәт икәнен аңлыйбыз. Әле шушы проектлар өстенә «Идел» яшьләр үзәге соңгы елларда тәҗрибә бүлешү максаты белән регионнарга да юл тота башлады. Владимир шәһәрендә оештырылган Татар мәдәнияте көннәре, Татар теле, әдәбият һәм татар тарихы буенча курслар, Ижау шәһәрендә оештырылган Татар кызы бәйгесе, Пермь крае мөселманнары белән түгәрәк өстәл, Пенза өлкәсендә уздырылган фәнни конференция, Самара шәһәренең Матурлык бәйгесе һәм тагы бик күп чаралар хезмәттәшлекнең ачык мисалы булып тора.

Шулай ук «Идел» яшьләр үзәге Казан шәһәрендә күп кенә конкурс-бәйгеләрне оештыруда да үз өлешен кертә, әлеге исемлектә: «Ягымлы яз», «Яз гүзәле», «Дөнья матур булсын өчен җырлыйм», Миңгол Галиев исемендәге татар җыр һәм фольклор фестивале, Татар шигъри слэмы, «Бумажный слон» Казан шәһәренең яшь язучылар конкурсы.

Җәмгыять һәрвакыт хәрәкәттә, ул бер урында гына тормый, инновацион проектларны тормышка ашырырга тырыша, яңа үсеш юлларына чыга. «Идел» яшьләр үзәге дә бу гамәлләрдән калышмый. Яшь буынны берләштерү өчен яңа юллар эзләү, татар яшьләрен мәдәниятебезне, телне һәм гореф-гадәтләрне популярлаштыру эшчәнлегенә тарту, кызыксындыру — «Идел» яшьләр үзәгенең төп вазыйфасы булып тора.

Булат Ибраһимов,
КФУ аспиранты

ӘТКӘМ-ӘНКӘМ, БАЛАМ-ОНЫГЫМ ТЕЛЕ...

Рөстәм Акъегет

«Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.
Телеңне сакла, дәүләтле булырсың», — дигән безнең халык.

Туган тел! Нинди тылсымлы һәм сихри сүз! Туган телебезнең күркәмлегенә, нәфислегенә кемнәр генә сокланмаган, кемнәр генә шул хакта күңел түреннән чыккан иң изге сүзен әйтмәгән!

Олуг галимнәрнең фикеренчә, нинди дә булса телне уйлап чыгару, барлыкка китерү кеше акылының гына көченнән килми, тел, фикер һәм хисне белдерергә мөмкинлек бирүче камил система буларак, безгә Аллаһы Тәгаләнең Үзеннән иңдерелгән олуг нигъмәт ул. Ул аралашу, мәгълүмат алмашу чарасы гына булып калмыйча, халыкның эчке куәтен, рухи көчен күрсәтүче үзенә күрә бер билге дә. Анда халыкның рухы да, табигате дә һәм тормыш-көнкүреше, мәдәниятлелек дәрәҗәсе дә чагылыш таба. Борынгылар матди һәм рухи байлыклар белән бергә бөек һәм алыштыргысыз тел хәзинәсен дә безгә мирас итеп калдырган. Һәр буын ул мираска үз өлешен өсти торган, күп сынаулар һәм хәвеф-хәтәрләрдән саклап, гасырлар буенча шомартып, камилләштереп безгә китереп җиткергән. Тел ул — күп гасырларның һәм заманаларның уртак җәүһәре. Шуңа да халыкның алдынгы уллары, аеруча язучы-әдипләр, туган телгә карата игътибарлы һәм сак мөнәсәбәттә булган, һәрчак аның сафлыгын, җегәр-куәтен саклап калу һәм арттыру турында уйланган. Моны без инде Татарстан радиосы дулкыннарында 40 елга якын алып барылган «Тел күрке — сүз» тапшыру мисалында да ачык күрәбез. Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Нурихан Фәттах, Хәсән Сарьян, Әбрар Кәримуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Равил Фәйзуллин, Рабит Батулла кебек күренекле каләм осталарыбыз ул тапшыруларда даими катнаша килде, дистәләгән, йөзләгән чыгышлар ясады, радиотыңлаучыларыбызда туган телебезгә карата ихлас ярату хисләре уятты, аны камил итеп үзләштерергә, киләчәк язмышын кайгыртып яшәргә өндәде. Аларның бу чыгышлары матбугат битләрендә, китап сәхифәләрендә урын алганчы иң әүвәл безнең эфирдан яңгырады. Әлеге «Тел күрке — сүз» тапшыруларына фатиха биргән, соңрак аларны җөмһүрият күләмендә «Татар теле дәресләре» мәктәбе, — дип атаган Сибгат ага Хәкимнең «Тел ил белән икән» дигән чыгышы да (1977 ел азагында язып алынган) шундыйлардан иде.



ТЕЛ ИЛ БЕЛӘН ИКӘН

Сибгат Хәким
(1911-1986)

Сагыну... Өйләнгән кеше булсаң, хатыныңны, балаларыңны сагынасың фронтта, туганнарыңны. Яшәгән йортың, баскычы төбеннән коега сузылган сукмак. Шул кое белән йорт арасында тукталып басып торган әнкәң. Яшьлек, шау-шулы туйлар, кичәләр.

Авыл читендәге ялгыз мәктәп. Бала чак. Сугышта озаграк йөргән саен, сугыш көчәйгән саен сагыну хисе дә нечкәргәннән нечкәрә, сагыш йөрәкне талый башлый. Болардан тыш тагын? Сагыну өчен болары да бик җиткән. Ләкин тагын икенче бер сагыну бар икән әле дөньяда. Мин аны телне, туган телне сагыну дип атар идем. Телне дә сагынып була икән, дигән уй сугышка чаклы минем күңелемә килмәгән иде. Юк, килмәгән иде.

Башта ук, дип әйтмим. Башта әле гомумән сагыну хисе яши иде. Тыныч тормыш белән бәйле истәлекләр сагындырды башта. Тел соңрак. Нигәдер таң алдыннан, җәйге таң алдыннан сагындырды. Җәйге таң яңа беленеп килгәндә. Авылда көтү куалардыр. Гадәттә, бу вакытта авыл хатыннары капка төбендә сөйләшеп торырга яраталар. Сер уртаклашалар. Сүзләре агач яфракларының лепердәве кебек кенә. Тыйнак, оялчан, тартынучан. Аннан алар кое янына килеп басалар. Сүзләре бетми, күрәсең. Минем шуларны тыңлыйсым килә. Бу сагышны көчәйткән тагын икенче нәрсә бар. Таң алдыннан алгы сызыкта немец солдатларының сөйләшкәне аермачык ишетелеп тора, бигрәк тә май, июнь аенда. Һәр аваз, һәр тавыш бөтен сафлыгы белән аерымачык яңгырый. Мин немец телен дә хөрмәт итәм. Тәрҗемәләре аша булса да Гёте, Һейне, Шиллерларны укып үстем, немец халкының бай культурасына ихтирамым зур. Икенче халык телен әз генә дә кимсетергә теләмим, телләрне бер-берсенә каршы куярга җыенмыйм. Шулай да үз телем якынрак миңа. Менә шушындый вакытларда, илнең язмышы кыл өстендә торган чакларда тел дә ил белән икән, үз илеңнән аерым түгел икән. Тел, ил, халык төшенчәләре белән бергә йөри икән. Телнең зурлыгын сугышта аңладым. Дугада барган авыр сугышларда тел минем иң көчле сагышыма әйләнде. Шуңа күрә минем кайбер кешеләрдән: «Телне сагынганыгыз бармы сезнең?» — дип сорыйсым килә.

Сагыну мине балачакка кайтарды. Авылда атнага бер базар. Зур базар. Кышкы салкында чана табаны тавышы әллә каян колакка ярып керә. Төнлә йокы аралаш килеп керә. Чана ыңгыраша, зарлана. Беләм, бүрәнә салып марилар төннән үк базарга киләләр. Әти китап ярата. Булса, үзебезнең базарда сатып ала. Бездә булмаса, Әтнә базарыннан сатып алып кайта. Чана башында атка салам, печән. Салам эчендә капчык. Ипи кисәге һәм китап… Атна арасында бураннарга да карамастан, кечкенә чана тартып, китап сатучы килеп чыга. Өстендә кайры тун, аякта чуар киез итек. Керә, китапларын сәкегә җәеп сала. Үз китапларына үзе сокланып, бер читтән карап тора. Безнең күзләр шул китапларда. Әни чәй куя. Бәйрәм бит, бәйрәм. Бездән күрше йортка, безнең авылдан күрше авылга китә. Яңадан бураннар эченә

кереп югала. Буранда, салкында ак тунлы кеше берүзе генә йөри кебек...

Эштән соң, кичке аштан соң күршеләр безгә җыелалар. Кайсы мич буена сузылып ята. Кайсы ишек төбендә чүгәләп утыра. Без — сәкедә. Ишек төбендә коедан кичтән алып кереп куйган бер чиләк су. Өстендә чүмеч. Әти кычкырып укый. Укыган китаплары «Йосыф вә Зөләйха», «Бүз егет», гарәп әкиятләре. Тыңлыйлар, бәхәсләшәләр, торып чүмеч белән бозлы су эчәләр, тагын урыннарына барып яталар. Төн уртасына чаклы шулай. Әти дә, әни дә, без дә шат. Тыңлап утыручылар өйләренә бәйрәмдәге кебек тараладар. Кечкенә, юка китап ипи белән бер шүрлектә, кадерле урында.

Тел стихиясе кебек серле, хикмәтле, тирән башка бер стихия юктыр дөньяда. Әкиятчеләр, әкият дөньясы. Үзем үскән тыкрык турында мин күп яздым.

Шунда кайтам, мин —
шул тыкрыктан.
Кайтам, чатта торам туктальп.
Безнең тыкрык, якты уртада,
Әйтерсең лә узган туп ярып...

Шул бер кечкенә генә тыкрыкта ничә әкиятче. Шәйхи карт. Озын буйлы, таза, бераз бөкрәеп, сөрлегеп йөри. Йорты су буенда, кырый йорт. Аның безгә китап тыңларга кергәнен бер дә хәтерләмим. Ул үзе атаклы әкиятче. Аның үз кешеләре бар, үз дөньясы бар. Тавышы яңгыравык, үзенә буйсындыра торган ниндидер серле мәкам. Үзен тотышында зурлык, олылык. Түбән карап йөри, сәлам биргән чагында гына күтәрелеп карый. Әкиятчеләргә басынкылык хас. Аларның үзләрен тотышыннан кайдадыр тирәндә берәр могҗиза яшеренгән төсле тоела иде. Әкият дөньясында яшиләр.

Шәйхи карт бер әкиятне бүленәбүленә өчәр көн рәттән сөйли. Су буенда карт таллар, өянкеләр. Алар кинәт сергә күмелә. Әкиятченең тавышы сине калын кара урманнарга илтеп ташлый. Якында мари урманнары, мари зиратлары, кирәмәтләр... Бар да җанлана, бар да терелә. Мин аның тавышына, мәкаменә соклана идем.

Икенче әкиятче — күрше авылдан. Безнең базарга килеп йөри. Әхмәтҗан исемле карт. Монысы тагын да серлерәк. Ак сакал, ак алъяпкыч, ак тула оек. Җәяү килә, арыш арасыннан, зират яннарыннан. Олы, хөрмәтле карт, янында һәрвакыт кеше. Нихәл, дисәң, быел арыш басуында йөрим әле, ди. Димәк, быел арыш ипие ашап яши. Икенче бер очраганда бодай басуында йөрим, дип җавап бирер. Димәк, бодай икмәге ашап яши, хәле әйбәт.



Бернәрсәне дә туры мәгънәсендә атамас. Өендә һәр әйбернең үз исеме бар. Мәсәлән, чәйнек аның телендә күгәрчен. Бу кешеләр сөйләгәндә колакка ят, әдәпсез сүзләр кыстырып шаккаттырмыйлар. Телләре саф, бай. Сүзләрне алар сайлап та газапланмыйлар, алар сүзнең рәхәтен тоеп яшиләр. Алар хезмәт кешеләре, балта осталары, иген игүчеләр. Эшләгәндә: «Пычкы сиңа да булсын, миңа да булсын, дип тарта», — дип сөйләшергә яратучы кешеләр. Сугышта мин шул кешеләрне берәм-берәм, исемнәре белән, яу тынган араларда, блиндаж читенә утырып, һәркайсын үзенчә күз алдына китереп сагындым. Тапкыр сүз, табышмак, мәкальләрне, иң моңлы җырларны, әкиятләрне шул кешеләр иҗат иткән. Алар да шагыйрьләр, күңелдәген безнең күк бары кәгазьгә генә төшермәгәннәр, чәчкәннәр, сипкәннәр, капка төпләрендә, базарларда, тегермән чиратын көтеп уздырган озын төннәрдә. Мин шул кешеләрнең телләренә кызыгып яшәдем.

Безнең якта марилар саф татарча сөйләшә. Мин бигрәк тә мари карчыгының татарча сөйләү формасын яратам. Гомумән, тел хатын-кыз сөйләшендә матур. Мари карчыгының сөйләвендә татар теле тагын да ягымлырак булып ишетелә, чит телдән нәрсәдер кушыла. Ягымлылыкмы ул, хөрмәтме ул, йомшаклыгына, шигърилегенә, сыгылмалыгына, телнең борылышларына сокланасың. Икенче халык үз теленең нечкәлекләрен синең телеңә куша. Тыңлыйсың, сөенәсең, шатланасың. Телләр аралаша, сүзләр күчә, берберсен бизиләр. Татар белән мари очрашканда татарның «сабырым үнҗе», дип эндәшүе дә ошый миңа. Сабыр ит. Сабыры татарныкы, үнҗесе мариныкы. Татарда күкрәгенә сугып мактанып йөрүче кешене «мин кем булам», диләр. Марида шул ук сүзләр: «мики улан». Татар андый кешегә: «Әнә, мики улан килә», — ди. Минем дәфтәрдә мондый дүрт юл шигырь дә бар.

Ике якта ике урам,
Уртасында уйный буран.
Берсе әйтә: мин кем булам?
Икенчесе: мики улан?

Хәтта аерым сүзләр кешенең характерын, рухын, рухи халәтен ачып бирәләр. «Алмасар» сүзе минем шигырьләргә күптән кергән. Яшьлек, мәхәббәт белән бергә кергән.

...Алмасар булма, җанашым,
Насыйп түгел яр өчен, — дип җырлыйлар безнең якта. Мәгънәсенә соңрак төшендем, шигырьләр яза башлагач. «Алмасар» сүзе яшь кызларга карый. Фәкать яшь кызларга. Аларның да унҗиде, унсигез яшьлекләренә. Күңелнең утырмаган, иләс-миләс чагы. Кемнедер сайлый, кемне? Күңел кемгә тукталыр? Яки берсенә дә туктала алмый газапланырмы? Авыр чак, газаплы чак, куркыныч чак. Ә җыр кисәтә. Бер сүз, бары бер сүз. Ничаклы психологик кичерешне үз эченә алган! Күңел сүзләрне шулай берәмләп чүпли, халыктан берәмләп җыя. Туганнан бирле, балачактан, туктаусыз, гомер буе. Шуңа күрә язганда кирәкле сүз табылса, үз урынына ятса, сөенеп куясың.

Ятса күңелдә чымырдап,
Оеп изгелек.
Табыла үзеннән-үзе
Кирәк сүз элек...

Тел ил белән икән, аерым түгел икән. Ил язмышы — тел язмышы. Сугышта мин шушы хакыйкатькә ныграк ышандым. Менә бу шигырьдәге хисләр, сугышның иң авыр чакларында күңелдә туган хисләр:

Язмышым, рәхмәттән башка
Бер сүзем юк бу җиргә,
Мин риза, бәхил, колак сал
Минем соңгы гозергә.
Мин башка гозерләр белән
Сине бүтән йөдәтмәм,
Язмышым, үзең аердың,
Юк әткәм һәм юк әнкәм,
Юк җирдә башка шатлыгым,
Әйтче, мин кемнән, йә, ким?
Әнкәмнән мәхрүм итсәң дә,
Телемнән итмә ятим. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АЙГЫР ЙОЛДЫЗ, АРГЫР ЙОЛДЫЗ. Мәгънәсе – *Ата йолдыз.* Иң якты йолдызларның берсе — *Сириусны* шулай атаганнар. Башкача: *Ачык йолдыз.* Коръәндә — *Шигъра.* Бу йолдызның гарәпчә башка исеме — *Сүрия.*

Тагын кара: ***Сириус.***

АЙЗУАК БИЙ (XVI гасыр урталары) — Башкортларның гайнә кабиләсе башлыгы. «Башкортостан (Краткая энциклопедия)» башкортларның Казан ханлыгына каршы көрәшен Айзуак бийнең җитәкләве турында хәбәр итә. 1554 елда уран һәм гайнә кабиләләре исеменнән Казанга Явыз Иванның наместнигы хозурына килеп, гайнә кабиләсенең Рус дәүләтенә үзе теләп кушылуы турында ярлык (грамота) китергән.

АЙЯ-СУФИЯ — Истанбулдагы атаклы мәчет. Византия архитектурасының тарихи ядкяре, 532-537 елларда салынган, соңыннан мәчеткә әйләндерелгән: михраб эшләнгән, аның уң ягына мөнбәр урнаштырылган, төрек каллиграфы Бичакизадә Мостафа Чәләби колонналарга гаять зур герблар төшереп, аларга Пәйгамбәр урынына калган хәлифәләрнең исемнәрен язган. Хәзерге вакытта анда тарихи музей урнаша.

Фатих Кәрими тагын *Кечек Айя-Суфия* җамигъ мәчетне дә телгә ала (1904).

Айя-Суфия

АК ДИҢГЕЗ тар. — иске әдәбиятта *Урта диңгез* шулай атап йөртелә, башкача – *Бәхре сәфид. / / Русия, теләсә кызыл төсдә, ак төсдә, берләшкән зур бер дәүләт булып калганда, тугрыдан-тугры Ак диңгезгә чыгар өчен бугазларны, Истанбулны алыр өчен омтылачакдыр.* Г.Исхакый.

Хәзерге география терминологиясендә *Ак диңгез* — Белое море (Төньяк Боз океанының бер өлеше).

АК ҖИРЛӘР, АК УРЫННАР тар. — Казанда бистәдәге йомышлы татарларның бүлеп алынган ихатасы, ишегалды һәм бакча урыны. XVI-XVII гасырларда Русиядә мондый җирләр (мәс., чиркәү җирләре) өчен салым түләнмәгән. Тарихи әдәбиятта (русчадан тәрҗемәләрдә) *агурынлылар* (русча – «беломестцы») термины да очрый. Кайчагында аларны «ак бистәләр» дип

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

атаганнар. 1649 елда ак бистәләр, элекке җиңеллекләрдән мәхрүм ителеп, гадәти бистә кешеләре кебек үк салым түли һәм башка йөкләмәләрне үти башлаганнар.

АК КИЕК — кыйммәт тиреле җәнлек, рустагы *пушной зверь*; пушнина. Электә болгарларда ак киек сәүдәсе зур урын тоткан. Тагы шунысы игътибарны җәлеп итә: «Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә «кыйммәтле җәнлек тиреләре» мәгънәсендә «йынмал» сүзе теркәлгән (Нократ ягы сөйләшеннән).

Аккиек дип язу да очрый.

АК РУС — Белорус. //*Ак рус иле* – Беларусь («Ак рус» атамасы элекке мәдрәсәләрдә укыту программасында очрый). Даль үзенең сүзлегендә *Белая Русь* дип Могилёв, Витебск һәм Минск губерналарын, *Чёрная Русь* дип Гродно һәм Ковен якларын һәм *Червонная Русь* дип Волынь һәм Подолье төбәген атап күрсәтә. Моңа охшашлы бүленеш, мәсәлән, Фра-Мауро картасында очрый. Латин телендә *Белая Русь* – Albaruthenia.

АК ТАТАР тар. — Кытай тарихчысы Мынгун (XIII гасырның беренче яртысы) төркиләрне, монголлардан *(кара татарлар)* һәм манҗурлардан *(су татарлары)* аерып, ак татарлар дип атый.

АК ЯК тар. — Татарда төбәкләрне ак һәм кара якларга бүлеп караганнар. Мәс., «Алат юлы — Ак як» дигән сүз бар. Язучы Мөхәммәт Мәһдиев Азнакай, Мөслим, Актаныш төбәкләрен «ак як»ка кертә. //*Минем әсәрләремне ак якта күбрәк укыйлар.* М.Мәһдиев.

Бу сүз *ак рус* һәм *кара рус* кебек бүленешне искә төшерә.

Тагын кара: ***Ак җаклар.***

АКАЙ — 1735-1740 еллардагы татар-башкорт кузгалышы җитәкчеләренең берсе старшина *Акай Күсүмов*. 1681-1684 еллардагы башкорт хәрәкәтен җитәкләгән Түләкәйнең оныгы, Күсүм Түләкәйнең улы. Халык теленә *«Акай батыр»* булып кереп калган. 1735 елда патша гаскәрләре башлыгы генерал А.И.Румянцев тарафыннан сөйләшүләр өчен Минзәлә шәһәренә чакыртылган һәм аны шунда сак астына алганнар. 1738 елда С.-Петербург төрмәсенә күчерелгән, шуннан соңгы язмышы билгесез.

Акай Күсүмнең улы Габдулла да шушы ук чорда баш күтәргән башкортларның җитәкчеләреннән берсе булган. Чыганакларда Акайның Гәрәйләр нәселеннән булуы искәртелә.

АКБҮЗАТ — Кече Җидегәннең бер йолдызы, Тимерказык белән янәшә күренә. Шушы ук йолдызлыкта *Күкбүзат* йолдызы да бар. Төрки халыкларда Акбүзат белән Күкбүзат Тимерказыкка бәйләп куелганнар һәм аның тирәсендә әйләнеп йөриләр дигән күзаллау булган. «Урал батыр» эпосында Акбүзатның күктән төшкәнлеге әйтелә.

АККЕРМАН тар. — Украинада Одесса өлкәсендәге Белгород-Днестровский шәһәренең төрекләр биргән исеме – *Аккирмән.* Яңа эрага кадәр V гасырда Геродот аны Оксия дип телгә ала, X гасыр чыганакларында *Аспрон* исемен йөрткән, ләкин Генуя карталарында ул *Маврокастрон* — Кара ныгытма дип капма-каршы мәгънәдәге исем белән аталган.

Чаг.: ***Каракирмән.***

АКМӘЧЕТ, АКМӘСҖИД тар. — 1. Хәзерге Симферополь (Кырым) шәһәренең төркичә аталышы. 2. Алтын Урда дәүләтендәге шәһәр атамасы. Хәзерге Украинада Көньяк Буг елгасы буенда урнашкан булган. Археологик калдыклары Николаев шәһәре янындагы Ак мәчет авылы янәшәсендә.

АКТАШ УПКЫНЫ — Татарстанда Әлмәт районының Кәләй тимер юл станциясеннән көнчыгыштагы карст упкыны. 1939 елның 7 августында убылып, тракторчысы белән тракторны суырып алган (халык телендә «җир йоту» күренеше). Анда җир асты сулары белән туена торган күл хасил булган *(Акташ күле)*. Башта диаметры 4-5 м гына булып, хәзер 50 м га җиткән. Уртача тирәнлеге 17 м, иң тирән җирдә – 28 м дан артык. Суы яшькелт-зәңгәр төстә.

Аккерман

Акташ күле Татарстан республикасының табигать истәлеге булып санала. Ул декоратив металл киртә белән әйләндереп алынган, яр буена агачлар утыртылган.

АКЫЛ — Гарәпчә «гакл» сүзеннән гомумтөрки алынма. Бу сүз чуаш телендә дә бар *(хакәл)*, мари һәм удмурт телләренә дә кергән. Гакыл сүзе телдә күбрәк русча разум мәгънәсендә кулланыла шикелле. *//Иң бәхетле кеше булыр идем, /Гыйлемнәрнең үтеп барысын, /Туплый алсам бары меңнән берен /Бер чәчкәгә киткән акылның.* Илдус Әмирхан. *Акыл тернәге — гыйлем.* Мәкаль. *Акыл тубалы* — аяклы энциклопедия, белем капчыгы, беләмән. *Акыл теше* — соң гына (акыл кергәч) чыга торган урт тешләр. *Акыл иясе* — акылдар (русча — *мудрец*). *Кеше алтыга кадәр телен ача, алтмышка кадәр — акылын.* Мәкаль. *Дөядәй алтының булганчы, төймәдәй акылың булсын.* Мәкаль. *Акылым кара, дип кайгырма, булса күңелең ак вә пакь.*

Башкорт телендә *яртакыл* сүзе — русча *полоумный* мәгънәсен бирә. *//Яртакылга юл такыр* — полоумному дорога торная (русча).

Пермь якларында *акылга такыл* — акылга җиңел, алты-биш.

АЛАТЫРЬ — Чуаштанда Сура елгасы буенда урнашкан шәһәр. XVI гасырдан билгеле. Шәһәр атамасының Тубыл елгасына Исәт кушылган җирдә урнашкан борынгы татар шәһәре *Йала Тор* исеме белән охшаш яңгырашы игътибарны җәлеп итә.

Рус легендаларындагы *Алатырь-таш* Буян утравында ята һәм Рус җиренең бөтен көче шунда тупланган имеш. Бик ихтимал, бу легенда руслашкан кечерәк халыкныкы булгандыр.

Тагын кара: ***Алат.***

Алдамиян тар. — Көбә киемнең кулга киелә торган кабы, «бияләе».

АЛДАНУ — Термези җыентыгындагы бер хәдистә: *«Мөэмин кеше — алданучы кәримдер»,* — диелә. Ягъни мөэмин барлык кешеләрне тугры сүзле вә намуслы дип белүе сәбәпле, җиңел алдана. Ә тиз алданмаучылык берәүгә дә ышанмыйча, һәркемнән шикләнеп вә сакланып торудан килә. Очраган бер кешегә хөсне зан кылу вә кем туры килсә, шуңардан алдану яхшы эш булмаган кебек, һәркемгә сүэ зан кылу да яхшы эш түгеллеген Ризаэддин бине Фәхреддин бик ачык әйтә. *«Мөселман кеше ошбу икенең уртасында булырга тиешле,* — ди ул. — *Мөселман кеше күбрәк алданыр, әмма һәркемнән дә алданмас, алданган вакытында җиңел алданыр».* Икенче бер хәдистәге *«Мөэмин кеше бер тишектә булган еланнан үзен ике мәртәбә чактырмас»* дигән сүзләрне дә шушы мөнәсәбәттә аңларга кирәк. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның июнь ае

Бишбалтада[1]

Бишбалтада Мәскәүски урамда[2] Дудров йортында чәйханә тотучы Кадыйр Халидовның чәйнеккә сыра салып сатканы полициягә беленгән. Тикшергәннән соң чәйханәдә сатарга хәзерләгән 17 шешә сыра табылган. Чәйханәче бу гаебе өчен, яшерен эчерткеч сатуда гаепләнеп, җавапка тартыла.

1914. — №427. — 2 июнь.

Мөселманнар үтенече

Шәһәрнең 5 нче часть мөселманнары[3] шәһәр идарәсенең Козья бистәсендә врачебный пункт ачарга карар бирүен тәбрик иткәннән соң, шәһәр идарәсеннән 5 нче частьтагы хәзерге думский врач[4] Семённы шушы Козья бистәсендәге шифаханәгә күчерүен, әмма 5 нче частька думский врачлыкка доктор Госмановны билгеләүләрен үтенгәннәр.

1914. — №428. — 3 июнь.

Атлардан түләү

Шәһәр управасы, шәһәр файдасына атлардан түләү алу хакындагы карарда каберчеләр атларыннан, постоялый дворлардагы ямщикләр атларыннан, казённый һәм почта атларыннан түләү алыргамы, юкмылыгы хакында тәрәддедкә [икеләнүгә] калгач, гадлия [юстиция] комиссиясе тикшереп, һәммә атлардан бертигез түләү алырга тиешлеген карар бирде.

Гариза

Шәһәрнең Казаков мәхәлләсе халкы губернаторга түбәндәге мәзмунда [эчтәлектә] гариза биргәннәр: «Моннан ничә еллар әллә ничә мәртәбә җыелышып, шәһәр главасына безнең тирәгә төннәрдә караңгы вакытларда атлы полиция җибәрергә сорап гаризалар биргән булсак та, әлегә кадәр һичбер җавап алганыбыз юк. Евангелистовская[5] урамының һәр ике ягыннан шакшы түгү кәрваны атларын чаптырып йөртеп, мичкәләреннән юри пычрак түгәләр, урамны тәмам шакшылатып бетерәләр. Мондый вакыйгалар һава бозык көннәрдә, караңгы вакытларда бигрәк тә еш тәкрар ителә [кабатлана]. Полиция юк. Каравылчыларны тыңламыйлар. Җәнҗал чыккан вакытларда

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Бишбалта — Казанның хәзерге Киров районындагы Адмираллык (Адмиралтейская) бистәсе.

[2] Мәскәүски урам — 1932 елдан Клара Цеткин урамы.

[3] 5 нче часть мөселманнары — Иске һәм Яңа Татар бистәләрендә яшәүчеләр.

[4] Думский врач — революциягә кадәр ярлы шәһәр халкына медицина ярдәме күрсәтер өчен шәһәр үзидарәсе (шәһәр думасы) тарафыннан тәгаенләнгән табиб.

[5] Евангелистовская урамы — хәзерге Татарстан урамы.

полицейский эзләп 2 нче частьныкылар[6] Печән базарына, 5 нче частька караганнар күл янына кадәр барырга мәҗбүр булалар.

Сез җәнаплардан, 1 нче — Казаков мәсҗиде[7] янына, 2 нче — Юныс Рәхимбаев йорты янына, 3 нче — шакшычылар күп вакытта мичкәләрен түгеп китә торган вә еш-еш «Каравыл!» тавышлары ишетелә торган җиргә — күпер янына электр фонаре куйдыру хакында шәһәр идарәсенә тәклифләрдә булынуларыгызны [әмер итүегезне] үтенәбез.

1914. — №431. — 6 июнь.

Кабан күлен шакшылау

Шәһәр комиссиясе, шәһәр управасына гариза биреп, Крестовников заводының[8] мәэмүрияте [идарәсе] Кабан күленә истигъмальдан [файдаланудан] чыккан су җибәргәнлекләрен, шул сәбәпле Кабан күленнән сасылык килгәнен белдерә. Әллә ничә кат тәнбиһ [кисәтү] кылганнан соң гына, заводта истигъмаль кылынган суны Кабан күленә җибәрүне вакытлы гына туктатып торганнан соң, хәзерге көндә янәдән җибәрә башлаганнар. Кабан күленнән сасы ис тарала башлаган, ди.

Шунлыктан, шәһәр управасына, Кабан күленең якын-тирәдә торучыларга болай да тәэсир итәрлек авырулар оясы булуын игътибарга алып, югарыда мәзкүр [телгә алынган] эшне туктату юлында бик тиз вә бик җитди тәшәббесләрдә булынырга [эшкә керешерә] тугры киләдер.

Җеназа мәйданы

Соңгы вакытларда Юнысовлар мәйданындагы җеназа укыла торган ихата эчендәге мәйданга зур ихтирамсызлыклар кылынганнан мөселман җәмәгасеннән байтаклар зарланалар. Җеназа укуга тәхсыйс ителеп [билгеләнеп], гыйбадәт кылу урыны буларак кабул ителгән бу урынга ихтирамсызлыкка, мөселманнар, күңелләре рәнҗегәнлекне белдерәләр. Мәйдан эченә кичләрдә казлар ябып куючылар булганлык сәбәпле, намаз укыганда басарга тиешле урынның пакь булуына шөбһәләнәләр. Шулай ук төрле мөнәсәбәт белән кылынган тантана вакытларында, музыка уйнаучы солдатларның мәгъбәдкә [гыйбадәт кылу урынына] кертелүенә вә аларга иярүче бала-чаганың ихтирамсызлыкларына да пошыналар.

Гыйбадәт урынына ихтирамы булган кешеләргә мондый игътибарсызлыкларның агыр тәэсир итәчәге табигый. Шунлыктан кешеләр моңа дикъкать итәргә тиештер.

Татарча театр

Җомга көн 6да Панаев бакчасының ябык театрында[9] «любительләр» тарафыннан татарча спектакль куелды. «Чамадан тыш» дигән русчадан

[6] 2 нче частьныкылар — Сул як Болак урамыннан Идел елгасына кадәрге мәйданда яшәүче халык. Үзәге — Печән базары.
[7] Казаков мәчете — 1878 елда сәүдәгәр М.Н.Казаков акчасына Яңа Татар бистәсенә керә торган урында, хәзерге Татарстан һәм К.Тинчурин урамнары тирәсендә кирпечтән төзелгән беркатлы, ике залды мәчет. 1975 елда сүтелә.
[8] Крестовников заводы — Кабан күленең көнбатыш ярында Крестовниковларның шәмстеарин, сабын кайнату, гөлсирин җитештерү химиясе заводы.
[9] Панаев театры — Лядская урамында, Панаевлар утары янындагы бакчада (хәзерге М.Горький урамы, «Динамо» стадионы урынында) урнашкан җәйге театр.

тәрҗемә көлке уйналды. Уйнаучылардан Сабира ролен уйнаган Мортазина Иманская[10] ханым, Мөхтәр ролен башкаручы Мөхетдинов гүзәл уйнадылар. Калганнары да, сценага аз мәртәбә чыгуларын игътибарга алганда, чибәр генә чыгардылар. Миһманнар [кунаклар], көннең яңгырлы булуына карамыйча, байтак кына күп иде.

Тотылганнар

Мөселман каберлекләре янынннан шәһәр комнарын 7 йөк угрылаган татарлар тотылганнар.

1914. — № 432. — 8 июнь.

Офицерны хурлаган өчен

Өченче көн военный окружной судта 5 нче гусарский Александрийский полкның (Самара) гусары 22 яшьлек Нургали Тимергалиев эше каралды. Офицерны хурлау вакыйгасы Самарада 4 нче майда булган. Иттиһамнамә[11] игълан итү һәм шаһидләрдән сорашу ябык залда булды. Суд, Тимергалиевне гаепле табып, 12 елга каторгага хөкем иткән карарны чыгарды.

Казан мәсҗедләре

Иттифакый [очраклы рәвештә] Зәңгәр мәсҗедкә[12] керергә тугры килде. Ислам шәригатенең иң әһәмият биргәне нәзафәт [пакьлек] хакындагы тәгълиматны ирештерү урыны вә гыйбадәт урыны булган бу мәсҗеднең эчендәге тәмизсезлек [пычраклык] чиктән ашкан. Мәсҗед себерелмәгән, почмаклары идәненнән түшәмгә чаклы үрмәкүч оясы белән тулы. Хәер, 3 имамы, 2 мөәзине булган бу мәсҗеднең бу хәлдә булуы, бәлки хошуг [түбәнчелек], хозугъка [буйсынуга] ярдәм итсен өчен, бәлки тарихи вакыйгаларны искә төшерер өчендер. Тузанның себерелмәве — җәмәгать намазына ашыгып килгәннәргә тимим, дип, үрмәкүч оялары рәсүлулланың гардә [мәгарәдә] чагында мөшрикләр күзен каплар өчен ясалган үрмәкүч оясын хәтергә төшереп торсын өчен, ихтирамга саклана торгандыр. Һәрхәлдә, барлыгы биш кешедән гыйбарәт руханисы булган бу мәсҗеднең бу хәлдә булуы, рухани бер әсаскә [нигезгә] бинаән кылынмаган түгелдер.

1914. — №433. — 10 июнь.

Шәһәр болыннарын карау

Өченче көн шәһәр управасы әгъзасы Шакир Апанаев шәһәр лесничийсы белән шәһәр болыннарын карап йөргән. Караудан шәһәр өчен күңелле хатирә гарыз иткән: үләннәр бик яхшы үсә, шәһәр печәннәренең бу елда яхшы булачагы көтелә.

1914. — №435. — 12 июнь.

---

[10] Иманская (Хәйруллина) Мәрфуга (1928 елда вафат) — артистка, сәхнә эшчәнлеген 1910 елда «Сәяр»дә башлый, 1915 елдан — «Ширкәт» труппасында.
[11] Иттиһаднамә — кылган җинаять, гаеп турында мәгълүмат.
[12] Зәңгәр мәчет — 1815-1819 елларда сәүдәгәр Әхмәт Исхаков төзеткән дүртенче җамигъ мәчет. (Ф.Кәрим һәм С.Садыйкова урамнары чатындагы 19/8 йорт.)

Татар извозчиклары

Татар извозчиклары управага мөрәҗәгать итеп, өчпочмаклы бүрек кию шәригатькә сыймый, шунлыктан, аны кияргә мәҗбүр итү бетерелсен иде, дип сораганнар. Шәһәр управасы бу үтенечкә игътибар итеп, извозчикларга гаскәри бүрек төсле бүрек кияргә ихтияр биргән.

1914. — №437. — 15 июнь.

Иделдәге янгынга каршы

Волжский пароходының Казан пристаненнән алынган мәгълүматка караганда, Мариинский посад янында янган «Царица» пароходына Казаннан ике йөз кеше утырып киткән булган. Пароход хезмәтчеләре барысы кырык кеше икән. Пароходта Казаннан киткәндә 13690 пот товар һәм 1500 пот нефть булган.

Янган пароходтан котылып кайткан кешеләрнең хәбәренә караганда, янгын төнге 12 сәгатьләрдә башланган[13]. Янгын сизелгәч тә, командир сүндерергә һәм йоклаган халыкны һәммәсен уятырга кушкан. Халыкны уятучының тавышына уянган бар кеше шашып киткән. Пароход мәэмүрияте тынычлыкка дәгъват итсә дә, саклану әсбабын истигъмаль итәргә өйрәтсә дә, батудан котылу юлларына хәзерләнүгә тиешле юллар күрсәтсә дә, халык шашуында дәвам иткән. Янгынны сүндерү мөмкин түгеллеге беленгәч, пароход читкә таба юнәлдерелгән һәм бөтен куәтенә барып комга утырган. Пароходтан суга ыргытыла торган халык, электән төшерелгән көймәләргә җыела торган. Якынтирәдә булган пароходлар һәм күрше яктан көймәләр, янучы пароходның әче сызгырган тавышын ишетеп, ялкынны күреп килеп җиткәннәр. Яна торган пароходның машинасы[14] туктатыла алмаган. Шунлыктан, көпчәк әйләнүдән чыккан дулкын суга ыргытылганнарга зур зарар иткән. Пароход командасы суга егылучыларны саклауга зур иҗтиһад кылган. Читтән килеп өлгергән өч пароход һәм икенче яктан килеп җиткән утызлап көймәләр коткарырга хезмәт итсәләр дә 18ләп кеше югалган, диләр. Кичке сәгать уннарга кадәр 6 кеше гәүдәсе судан табылган. Боларның дүртесе юлчыларныкы булып, калган икесе пароход хезмәткәрләренең 12 һәм 13 яшьлек балалары икән[15].

Янгын урынына Казаннан казённый пароход губернатор наибе [урынбасары], юллар идарәсе башлыгы һәм бүтән бик күп кешеләр барганнар.

Янган пароходның капитаны, пароходның һәммә җиренә ут кабып беткәч, чыдар хәл калмагач кына күлмәкчән суга сикереп төшкән һәм көймә белән килүчеләр тарафыннан тотылып, батудан коткарылган.

Янган пароход ширкәтенең Нижнийдан[16] киләторган пароходы килеп туктап, Идел читенә тезелгән, таркалган котылучыларга азыклар, киемлек вә азыклык акчалар өләшкән. Кайтырга теләгәннәрен Казанга алып кайткан.

1914. — №438. — 16 июнь.

[13] Газетаның 15 июнь санында (№437) «Идел өстен янгын» исемле хәбәрдә: «14енә каршы төндә, сәгать бердә Казаннан Нижнийга бара торган Волжское обществоның «Царица» дигән пароходында ут чыккан», — дип хәбәр ителә.

[14] Машинасы — пар двигателе.

[15] Газетаның 18 июнь санындагы (№440) «Янган пароход» дигән мәкаләдә янгын сәбәбе: «4 класста төялгән чыпта өстендә йоклап баручыларның тәмәке күмере төшүеннән ут чыккан дип уйланыла», — дип языла һәм батып үлүчеләрнең унбере табылу турында әйтелә.

[16] Нижнийдан — Түбән Новгород каласыннан.

Бишбалтада

Яңа бистәдә үз йортында торучы дворянка Әминә Хәсән кызы Ягъкупова, Бишбалта якынындагы кечкенә күл[17] янында торганда, урта буйлы мыексыз яшь егет килеп, 7 сум тора торган шәлемне җиргә куйган төштән алды да: «Кычкырма, кычкырсаң, суям!» — дип куркытып, качып китте, дип полициягә хәбәр иткән. Егет эзләнмәктә.

1914. — №441. — 19 июнь.

Шәһәр файдасына

Шәһәр җирләрендә таркалып йөри торган хайваннарны, бигрәк тә кәҗәләрне җыеп саклар өчен махсус урын хәзерләнгән. Шәһәр тарафыннан бу эшкә махсус кешеләр куелган. Мондый хайваннар ияләренә махсус түләү белән кайтарылалар. Бу түләүләрдән шәһәргә 400 сум җыелган инде.

1914. — №443. — 22 июнь.

Шәһәр болыннары

Шәһәр болыннарының бер кыйсеме [өлеше] печәнен чабып алу өчен хосусый кешеләргә иҗарәгә [вакытлыча файдалануга] бирелде һәм печәннәр чабыла да башланды инде. Кайбер кыйсемнәрен шәһәр идарәсе үзе чаптырып алырга, моннан хасыйл булган печәнне янгынчылар атларына, тыйбби ярдәм каретасы атларына вә башка шәһәр эшләре кирәк-ярагына тотарга карар биргән.

1914. — №447. — 27 июнь.

Панаев бакчасындагы театр. 1900 еллар



Панаев бакчасындагы ресторан. 1895 ел тирәсе

Татарча театр

Җомга көн кич, 27 июньдә Панаев бакчасында «Сәяр» труппасы тарафыннан, төрекләр тормышыннан алынган «Саран» вә «Безнең шәһәрнең серләре» тамашага куелды. Уен чибәр, халык байтак. Сбор дүрт йөз сум булды.

1914. — №448. — 29 июнь.

[17] Бишбалта якынындагы кечкенә күл — Бишбалта бистәсенең көньягында иң мәшһүр күлләрнең берсе — Чиста күл (Чистое озеро). 1955-1957 елларда, Куйбышев сусаклагычы төзелгәч, бу күл сусаклагыч астында кала. Хәзер бу күлдән истәлек булып, Чистоозёрская урамы гына калды.

[18] «Саран» — француз драматургы Ж.-Б.Мольерның комедиясе. Бу әсәрне төрекчәгә Т.Касап тәрҗемә кыла, ә төрекчәдән Г.Камал тәрҗемә итә.

[19] «Безнең шәһәрнең серләре» — Г.Камалның 5 пәрдәлек комедиясе.

Мәзәкләр

«Шура» журналы, 1909 ел

Зирәк карт

Һәр көн урманнан җилкәсенә утын күтәреп ташучы бер карт, көннәрдән берендә ифрат дәрәҗә ардыгы сәбәпле, хәсрәт чигеп йөген таш өстенә куймыш вә: «Туйдым дөньядан, и, Әҗәл, син нә җирдә?!» — димеш. Сүзе бетәр-бетмәстә күз уңына бер инсан сурәте заһир улып: «Ишетәм, бән — Әҗәлең, бәндә, нә хаҗәтең вар?» — дидекендә, карт: «Ошбу утынны күтәреп, җилкәмә куйсана, башка йомышым юк!» — димеш.

Алай икән – болай булыр...

Нә кеби хатын алырга тиешлеге хакында мәшвәрәт [киңәш] итәргә варучы бер егеткә күрәзәче: «Гүзәл улса — сәдакате [тугрылык] улмас, ямьсез улса — яратмассың, фәкыйрь улса — җитештерә алмассың, бай булса — итагать итмәс [буйсынмас], ошбуларның арасыннан берен үзең интихаб ит [сайлап ал]!» — дия җавап вирмеш.

Бу туннан ни файда?!

Төлке туны киеп, горурланып варучы бер адәмгә философлардан бере: «Иптәш! Бу тире төлке өстендә ничә сәнәләр йөреп тә, хайванлыктан котылдыра алмады, инде сине хайванлыктан коткарачакмы, буннан нә көтәрсең?» — димеш.

Алтын таяк кыйссасы

Бер байның алтын илә зиннәтләнмеш таягына кызыгып ике угры бер кач [берничә] көннәр күзәтеп йөрсәләр дә, кулларына төшерергә муафыйк ула белмәмешләр. Ниһаять, беркөн бере, өстенә теләнче киеме улдыгы хәлдә, чатанлап байга каршы чыгып сәдака сорамыш. Байның артыннан гүзәл киенеп килүче икенчесе, байга карап: «Сәдака вирмә! Бу бер хәйләкәр адәмдер, яланнан чатан улып күрелер, бир әле таягыңны», — дия, бай кулыннан таякны алып кизендегендә, теләнче бар көче илә йөгерергә башламыш, бунысы да аның артыннан куа киттегендә, бай башта гаҗәп итеп көлеп торса да, икесе дә күздән гаиб улдыгы соң, таягына: «Әл-видаг! [сау бул]» — димеш.

Сакаулыктан котылгач

«Р» хәрефен әйтә алмый торган бер балага үзенең туганнары «карга» сүзен сөйләтергә вә буның васитасы илә «р» хәрефен әйтергә иҗтиһад итмешләр, ахирел әмер [ахыр чиктә], бала да «карга» сүзен әйтергә өйрәнмеш. Шул сәгатьтә өйгә кермеш кунак янына чыгып, үзенең һөнәрен күрсәтмәк нияте илә кунакка карап: «Карга! Карга!» — дия кычкырмыш.

Шура. — 1909. — №18. — Б.574-575.

Күп торсаң...

Урманнан баручы бер исерек бер тәрәзәгә корылмыш кәгазьне ертып, башын эчкәре тыгып өйдә йөрүче хатыннан: «Абыстай, сәгать ничә?» — дия сорады. Абыстай да пумала алып килеп, сабы илә исерекнең башына шак итеп суктыгы соңыннан: «Хәзер берне сукты, күп торсаң, икене сугар!» — диде.

Шура. — 1909. — №19. — Б.607. ■

«ТЫНГЫСЫЗ КАЛӘМ» БИТЛӘРЕННӘН...

....

Ризван Хәмид

СИҢА ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР...

Драма
(Ике пәрдәдә)

Катнашалар:
Х а җ и ә х м ә т
М а р а т

Б е р е н ч е п ә р д ә

Хаҗиәхмәт тәрәзә аша кем беләндер сөйләшә. Ишектән Марат йөгереп керә.

М а р а т. Хаҗиәхмәт абзый!

Х а җ и ә х м ә т. Нәрсә тагын? Күрмисеңмени, кеше белән сөйләшәм!

М а р а т. Гафу ит, Хаҗиәхмәт абзый *(каушый)*. Мотоциклыңны биреп тормассың микән, дип кергән идем. Энекәшем самолётка соңга кала.

Х а җ и ә х м ә т *(башын тәрәзәдән алып)*. Нинди халык бу, ә! Исәнләштем, хәл-әхвәл сораштым юк. Тоталар да кычкыра башлыйлар *(тагын тәрәзәгә борыла)*. Элек заманда болай түгел идек бит без. Олыны — олы, кечене кече итә белә идек. Әгәр дә олы кеше кем беләндер сөйләшсә, сабыр гына әңгәмәнең ахырын көтеп торыр идек. Ә болар синең колак төбеңә киләләр дә кычкыралар. Кайда олыларга хөрмәт, кайда сабырлык? *(Маратка борыла.)* Кайда дип сорыйм мин синнән? Юк ул синдә, юк! Ә, бәлкем, минем кайгы-хәсрәтем бардыр? Ә, бәлкем, чирлимдер мин? Туктале, тукта, ашыкма син, олылар сүзен тыңла. *(Марат китәргә тели.)* Иң элек син әйбәт кенә килеп исәнләш. Хәлемне сораш, гаиләм, мал-туарым белән кызыксын. Менә инде шуннан соң йомышыңны әйтсәң дә ярый. *(Марат чигенә-чигенә ишектән чыгып йөгерә.)*. Әй, туктале, кая ашыгасың, тыңлап бетер олылар сүзен... Тфү...

И к е н ч е п ә р д ә

Ишектән Марат керә.

М а р а т. Исән генә торасыңмы, Хаҗиәхмәт абзый?

Х а җ и ә х м ә т. Ә-ә, син икәнсең әле. Исән, улым, бик исән, Ходага шөкер.

М а р а т. Сәламәтлегең ничек, Хаҗиәхмәт абзый?

Х а җ и ә х м ә т. Рәхмәт, улым. Йөрим әле беркөе, утыр син, утыр, оялма, утырып сөйләш.

М а р а т. Әсмабикә әбинең сәла-

мәтлеге ничек, Хаҗиәхмәт абзый? Чирләмиме?

Х а җ и ә х м ә т. Рәхмәт, улым. Аның да сәламәтлеге зарланырлык түгел әлегә.

М а р а т. Балалар исән-саулармы, Хаҗиәхмәт абзый?

Х а ж и ә х м ә т. Алар да, Аллага шөкер, дөбердәтеп йөриләр.

М а р а т. Агай-энеләр, кардәш-ырулар ничек?

Х а ж и ә х м ә т. Әйбәт, улым, рәхмәт.

М а р а т. Мал-туарлар, кош-кортлар?

Х а ж и ә х м ә т. Барысы да сау-сәламәт, улым. Рәхмәт. Һәрвакыт шулай кече күңелле булырга тырыш. Нәрсә? Миңа берәр йомышың бармы? Булса, әйт, оялма.

М а р а т. Йомышым дип инде, Хаҗиәхмәт абзый.... Әле яныгыздан үтеп барам да шулай... Туктале, мин әйтәм, кереп әйтеп чыгыйм...

Х а ж и ә х м ә т. Хуш, улым! Нәрсә әйтмәкче идең инде син миңа?

М а р а т. Сезнең мунчагыз яна, Хаҗиәхмәт абзый...

Пәрдә.

(«Тынгысыз каләм», 1977)

Рәдиф Гаташ



Рәниф Шәрипов

....

Рәдиф Гатауллин (Рәдиф Гаташ)

ҮЗ-ҮЗЕМӘ

— Фигародан да картраксың,
үзең
кермәкчесең
Керубино роленә.
Тигез җирдә абынып йөрисең,
ник
ябышасың
лихач-шофёр руленә? —
дидем, башка берәүгә түгел, тик
үз-үземә,
әрсез күңелемә!

(«Тынгысыз каләм», 1982)

....

Рәниф Шәрипов

ШАГЫЙРЬ ИРТӘСЕ

(Пародия)

Сөңгеләрдән тамчы тама, —
Каян килгән диген
бозга... Хис!

Акъегет. «Апрель иртәсе».

Төн... кухняда тамчы тама...
Йоклап кына китеп
булмый һич.

Каян килгән диген тимер кранга
бу кадәрле кире,
явыз хис!

Юрганымны атып бәрдем —
нишлисең бит, кирәк
торырга.
Онытамын көн саен шуның
хисен ныграк уңга
борырга.

(«Тынгысыз каләм», 1982)

....

Сабирҗан атасы
(Фаил Шәфигуллин)

ХИКМӘТЛЕ КИТАП

Нур Гайсинның «Яңа өйгә күчкәч» дигән китабын алып кайттым. Зерә дә хикмәтле китап икән, әй. Ни генә юк анда! Мисалга «Тайгада очрашу» бүлеген алыйк. Себер табигатенең тулы картинасы килә дә баса күз алдына: *«Алда ике тау утыра яшеллеккә күмелеп... бу тауларның арасында бар бер тирән тарлавык, бу бормалы чокыр буйлап ага көчле шарлавык... аның төбен таш каплаган, ике як яры кыя; шушы шарлавыкка тагын чишмәләр суын коя...»* Менә бит ул поэзия көче! Безнең яктагы малайлар төшләрендә дә күрмиләр мондый пейзажны. Ә Себер малайлары рәхәтләнеп йөриләр *«коеп үлән чыкларын»*. Шул ук «Походта» дигән шигырьдә малайлар *«үләннән чыкны коеп»* та узалар. Әлбәттә, болай инверсия ясап кабатлау әсәрнең тәэсир көчен арттыра. Чык тамчыларының ялтыравын да күргәндәй, салкынын да тойгандай буласың.

«Аучы улы» дигән әсәрдә урманда адашып калган Сабирҗан атлы малай образына нанай улы Мукчука образы капма-каршы куела. Сабирҗан елак, ә Мукчука *«курыкмый киектән дә... күтәрелә киек төсле текә таш тауга да....»*

Таудан күренә кораблар,
Диңгез пароходлары.
Яр буенда төтен бөрки
Консерв заводлары...

Әнә шундый гүзәл индустриаль пейзаж фонында чак кына фаҗига булмый кала. *«...Шомлы тавыш... Тукта, бу ни, аю түгелме анда?»* Мукчука *«борчылып тыңлап тора... ашыгып мылтыгын кора...»* һәм *«куаклыктан Сабирҗан килеп чыга...»* Шигырь моның белән генә тәмамланмый әле. Укучыны алда тагын да зуррак сөенеч көтә:

Нанай улы Сабирҗанны
Үз колхозына илтте,
Сабирҗан анасы аны
Яхшылап кунак итте...

«Очрашу» шигыре эчтәлеге белән борынгы легендаларга тартым. Әсәрдә яшь аучы Киленең юлбарыс белән көрәшүе сурәтләнә. Киле үзенә куркыныч янаса да: *«Юлбарысны тере килеш алырга кирәк — чөнки ул безнең тайгада очрый хәзер бик сирәк»,* — дип фикер йөртә. Ләкин шунда ук бу уенннан кире кайта. Үлем белән яшәү темасына үз-үзе белән бәхәскә керә: *«Ни эшләргә? Үләргәме? Юк, юк, ярамый...»* — ди ул югары пафос белән. Ә менә бу юлларны укыгач, ирексездән, маңгаена салкын тир бәреп чыга:

Юлбарыс торып Килегә
Кинәт тагын ташлана...

Ах! Ни була инде хәзер? Яшьлек һәм кыюлык җиңә:

Ләкин үсмер бик тиз генә
Атып өлгерә аңа...

География һәм табигать белеме» дәреслекләренә кертерлек шигырьләр дә байтак бу китапта. Алыйк «Диңгездә» шигырен. Төнлә ут яндырып балык тоту турында бай шигъри белешмә бирә ав-

тор: *«Диңгез төбенә катердай ятьмәләр төшерелә, алар төрле тирәнлеккә, кирәксә, күчерелә... Ятьмәләргә лампочкалар беркетелеп куела...»*

«Кайнар чишмә» шигыре тагын да тулырак, тагын да белешмәгә бай һәм бу шигырьнең образлары да үзенчәлекле, рифмалары, чагыштырулары искиткеч кызык. Яңа.

...Ул чишмәнең суы эссе —
Кайнаган күк казанда.
Паровоз сулаган сыман
Пар бөркелә янда...

Тиеннең *«үр куяны шикелле»* чабуы яисә *«мәче башлы бер ябалакның сай урында, тар ермакта»* балык тоту фактлары да бик кызык. Автор *«Урал тавына охшамаган сопка»* яисә *«ак комны» ерып килгән зур башлы балык»* турында да дулкынландыргыч итеп сөйли.

Музыканың кешеләр күңеленә илһам, дәрт бирүе белән бергә ерткычҗанварлар күңеленә шом, курку салуын әйтеп, шагыйрь үзен новаторлар рәтенә күтәрә.

Музыка тавышы яңгырый
Яңа шәһәр ягында.
Моңлы тавышны ишетеп,
Аю курка тагын да...

Кыскасы, әнә шундый хикмәтле китап ул «Яңа өйгә күчкәч».

(«Тынгысыз каләм», 1973)

....

Тмин (Туфан Миңнуллин)

БӨРКЕТ ҺӘМ КОЛИБРИ
(Мәсәл)

— Өркетмә!
Әйтәсен барыбер әйтермен
  Бөркеткә, —
Диде Колибри, —
Шулай ярыймыни?

Туфан Миңнуллин

Җыеп бирдек берүзенә
              бөтен данны,
Тәхет иттердек аңарга кыя-тауны,
Чөябез күкләргә
Үрнәк итеп күпләргә.
Кайда бездә ыскырумнос?
Күпме шулай кычкырырбыз?
Подумаешь, нинди талант.
Бездә дә бар кайбер
              талант, китсәң санап.
Бездә дә бар ике аяк, ике канат.
Аңарда, имеш, кәкре томшык бар.
Бездә юкмы томшыклар?
Без дә кошлар нәселеннән...

***

Мин шундый мораль чыгардым
  мәсәлемнән:
Туфан шагыйрь!
 Сибгат шагыйрь! — дибез дә...
Юк, иптәшләр,
  исемлектә бар без дә.

(«Тынгысыз каләм», 1987) ■

Зөлфәт Хәйруллин шаржлары

«ТАТМЕДИА» ААҖе, «Безнең мирас» журналы редакциясе, КФУның Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге 21 февральдә Азнакай, 26 мартта Актаныш, 17 апрельдә Кукмара һәм 25 апрельдә Теләче районнарында мәгариф бүлекләре белән берлектә оештырган «Туган ягым – яшел бишек» төбәкара фәнни-гамәли укытучылар конференциясеннән кайбер мизгелләр.

Актаныш

Актаныш

Кукмара

Теләче

Теләче

Төләче

Кукмара

Азнакай

ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ БИНАСЫ

Ризаэддин бине Фәхреддин

Ислам бинасы шушы нәрсәләрдән корыладыр:
Иман китерү . Намаз уку. Рамазан аенда ураза тоту. Дәүләте бар кешеләргә зәкят бирү. Хаҗ кылу.

НАМАЗ

Тәүлектә билгеле вакытларда биш мәртәбә, биш төрле намаз вә җомга көнендә өйлә намазы урынына җомга намазы уку фарыз була.

РАМАЗАН РУЗАСЫ

Рамазан аенда ният белән һәр көнне, таң вакытыннан башлап, кояш батканчы, ашау-эчүдән вә яшерен эштән тыелып тору фарыз — тиеш буладыр.

ЗӘКЯТ

Байлыгы булган кешенең дөньяда көн үткәреп торуы өчен беренче дәрәҗәдә зарур булган нәрсәләреннән арткан малының кырык өлешеннән берен һәр камәри елда, ягъни ай елында бер мәртәбә мөселман фәкыйрьләргә вә юксылларга бирүедер.

ХАҖ

Хаҗ гамәле. Җитәрлек дәүләте булган кешенең Мәккә шәһәренә барып, мәгълүм урыннарны зиярәт итүе вә махсус мәрасимнәрне, ягъни йолаларны гамәлгә куюыдыр.

Хаҗ гамәле, кешенең гомерендә бер генә мәртәбә фарыз кылынган булып, гамәлләрнең зурларыдыр. Зөлхиҗҗә аеның әүвәлге ун көннәренең күбрәгендә үтәлә. Бер мәртәбәдән арткан хаҗ-нәфел, ягъни яхшы ният белән кылынган хаҗ хисапланадыр.

....

Борынгылар сүзе

АТА-АНА МИРАСЫ...

Ата белән ана кызларына мирас итеп бер казан белән палас калдырдылар. Кыз казанны учакка аса, паласны идәнгә җәя дә көн итә башлый. Күршеләре моңа әйтәләр:

— Нигә казаныңны бер дә юмыйсың, нигә паласыңны себермисең? — диләр.

Кыз аларга:

— Казанымны кырсам — тишелер, паласымны себерсәм — бүселер... — дип җавап биргән.

Гомер узу белән казан тишелгән, паласы тузып беткән.

— Элек башлап җибәргән идем, хәзер ташлап җибәрим, — дип, кыз мирас әйберләрен чыгарып ташлаган.

— Кайда ата-анаң мирасы? — дип сорагач:

— Ата-ана мирасы — тиреслектә барысы, — дип җавап биргән ди ул. ■

Мирасворд

... юлны якын итеп

Көрәшчеләр билендә

Борынгы Идел

Җангали, Сафа Гәрәй

Чуашларның Сабантуйга охшаган бәйрәме

... тартышу

Төрекләрнең милли баш киеме

Күн акча янчыгы (иск.)

XIX йөз венгр композиторы

...Коржавин (рус шагыйре)

Йомшак шома өсле тыгыз тукыма

1915-17 елларда Оренбургта чыккан сатирик журнал

Кыяфәт, төс, ямь (иск.)

Җылы ат абзары

Фикер

Данлы исем, яхшы ат

Нәсел, токым

Һуннар юлбашчысы

Арыслан кыяфәтендәге кеше башлы сын

Амударьяның борынгы исеме

Борынгы әрмән каласы

Борынгы сугыш киеме

Санта...

Монголия акчасы

Зәһәр химик матдә

...кебек атылу

Эз, тамга, сыр

Гарәп артикле

2011 елда федераль сабантуй узган шәһәр

Сабан туйда күзне бәйләп ваталар

...Абзгильдин

Кириллица хәрефе

... Аббасов

Гравюра төре

Ауга өйрәтелгән бөркет баласы

Агачны чокып ясаган көймә

Ганимәт, трофей (иск.)

Ашлык, он саклый торган бина

Сугышта батырлык күрсәтүчегә бирелгән бүләк

Каеш прәшкәсе

Удмурт (иск.)

Конфуций ватаны

Батыр сугышчы, рыцарь (иск.)

«Җырлыйк ...» тапшыруы

Фатих Кәрим туган авылы

Инглиз диңгез сәяхәтчесе

...Капур (һинд сынчысы)

Рәис Габдулла төзеде.

5 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары

Сулдан уңга: мәхбүс, си, гаскәр, сау, Әзәл, матлуп, чех, Луара, тревога, Нант, «Суворовчы», окоп, Саар, Ладога, Чанышев, имана, батыр, Тито, ур, Усман, рота.

Өстән аска: Әхтәмов, би, Марс, әче, солдат, Лев, Упа, акын, әсас, Хо, ар, Хисам, ороч, Куала, га, ту, оран, Сыртланова, ыштыр, ура, чауш, пан, ыс, тут, «Аврора»

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / ИЮНЬ

940 ел элек (1074)

● Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» әсәре («Төрки телләр сүзлеге») язылып бетә.

130 ел элек (1904)

● 14 июньдә шагыйрь Миргазиз Укмаси дөньяга килә.

95 ел элек (1919)

● Шагыйрь Шәехзадә Бабич (1895-1919) фетнәчеләр тарафыннан үтерелә.

90 ел элек (1924)

● «Кызыл шәрык яшьләре» урынына Казанда «Октябрь яшьләре» журналы чыга башлый.

● Казанда Шамил Усманов җитәкчелегендә урам театрларының тамашалары уздырыла.

● 25 июньдә Казанда «Заря» кондитер фабрикасы ачыла.

85 ел элек (1929)

● 20 июньдә Көнчыгыш педагогия институтының идарә утырышында Габдрахман Сәгъдине татар теле һәм әдәбияты кафедрасы профессоры итеп билгеләү турында карар кабул ителә.

75 ел элек (1939)

● 7 июньдә рәссам, сынчы һәм монументаль бизәлеш остасы, агачка уеп рәсем ясаучы, Татарстанның халык рәссамы, атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әхсән Фәтхетдинов (1939-2012) дөньяга килә.

● 17 июньдә Казанда Татар дәүләт академия опера һәм балет театры ачыла.

70 ел элек (1944)

● «Ватан намусы өчен» газетасында «Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларыннан татар халкына җавап хаты» игълан ителә.

55 ел элек (1959)

● 11 июньдә Казанда язучылар һәм журналистлар Бөек Ватан сугышы елларында Бухенвальд концлагеренда хәрби әсирләр арасында яшерен оешма төзүдә актив катнашучыларның берсе, лагерьдагы яшерен хәрби бригада командиры Бакый Назиров белән очраша.

БУЛАТ ГЫЙЛЬВАНОВ

«Канат җилпегәндә». 2013.
Киндер, майлы буяу

Булат Әлфир улы Гыйльванов 1972 елда Алабуга шәһәрендә туа. И.И.Шишкин исемендәге Алабуга сәнгать мәктәбен (1987), Чаллы сәнгать училищесын (1991), И.Е.Репин исемендәге Санкт-Петербург рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура институтының графика факультетын (1997) тәмамлый. 2002 елдан — Россиянең Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстанның Муса Җәлил исемендәге һәм Бакый Урманче исемендәге премияләре лауреаты.

Булат Гыйльванов тарихи реализм стилендә иҗат итүче рәссам. Аның әсәрләре АКШ, Англия, Япония, Германия һәм Төркиянең, шулай ук Россиянең шәхси вә дәүләти тупланмаларында бар. Аның Төркия, Россия, Франция һәм Англия калаларында 10га якын күргәзмәсе оештырылды.



«Иртә». 2003.
Киндер, майлы буяу

«1236 ел көзенең яфраклары». 2012.
Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САННАРДА:

Әзһәр Мөхәммәдиев. «Курганнарда табылган алтын-көмеш савытлардагы, балдаклардагы һәм тәңкәләрдәге антик чор һәм яңа дәвер язмалары»

Лилия Байбулатова. «Ризаэддин Фәхреддин һәм мөфтилек тарихы»

Раиф Мәрданов. «Шанхайдагы татар җәмгыяте»

Фәрит Баттал. «Кем ул – Абдулла Баттал?»

Гаяз Исхакый. «Мәдрәсә җимеше»

Марсель Галиев. «Булат Сөләйманов – Күчем хан оныгы?!»

Индекс:
Татарстанда – 54132
Чит төбәкләрдә – 70275

Икенче ртыеллыкка язылу бәясе – 420 сум
Редакциядә язылу бәясе – 319 сум

4 612750 670172